1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН  2015 МАЙ № 5

Сөембикә

«ТӨН ПӘРИЛӘРЕ!»
күктә – татар кызлары

ЧӘКЧӘК ҖЫЕНЫ
һәр төбәкнең үз сере

ГҮЗӘЛ УРАЗОВА СЫЙЛЫЙ
ананас эчендә – тавык

Альбина Әбсәләмова:

«Һәр эшкә җан җылынны кушу кирәк»





70

1945–2015

Сугыш язган хатлар

Минем өчен Бөек Ватан сугышы 1941 елның 1 сентябрендә башланды. Бу көнне безнең әти фронтка китте. Беренче сыйныфка укырга кергән елым иде. Мәктәпкә кадәр әти белән килдем. Булачак укытучыма ул: «Җиһан, малайны кеше булырлык итеп укыт. Фамилиягә тап төшермәсен», — диде. Әтинең безгә язган 12 хаты сакланган. Соңгысын 1942 елның 4 декабрендә салган. Ә 23 се көнне «батырларча һәлак булды» дигән кара кәгазь килде... Җиңү көне дә истә. Без сеңлем белән бакчада тирес тарата идек. Күрше малайлары: «Сугыш бетте!» — дип урам буенча йөгерә, сеңлем дә аларга иярде. Ә мин кинәт туктап калдым: аларның әтиләре исән, кайтачак, ә без гомергә ятим калдык... Буыла-буыла елап, печәнлеккә менеп яттым.

«Сез ки гыйззәтле үлеп торучы хәләл җефетем Банатка, без ки чит җирләрдә ялгыз башым җөрүче иң якын иптәшегез Салихтан бик сагынып, бер күреп сөйләшергә әллә ниләр бирердәй булып, бик саргаеп, бик күп сәламнәр җибәреп калам. Янә дә күз нурларым Нәүфәл белән Равия кызыма бик сагынып, бик күрәсем килеп, күптән-күп сәламнәремне җибәрәм. Үзем исәнлектә сезнең янга исән-сау әйләнеп кайтып, сезнең белән бергә яшәүне теләп калам. Банат, бер җирдә туктап торган җирдән 200 километр эчкә җәяү кердек, шунысы бик читен булды. Көн саен 50 километр җир бардык. Хәзер үзем числоның 12 сеннән бирле сугышта инде. Немесләр белән ике арабыз 100 метр гына. Әлегәсен исән-сау. Немесләргә һаман ракета атабыз. Менә, Банат, бар читенлек шунысы. Үзем белән бергә бер татарлар юк. Үзбәкләр дә юк. Инде, Банат, Аллага тапшырдык, бик бәхетем булса гына исән кайтырмын. Банат, хат салмый дип әйтмә, хәзер монда хат язарга вакыт та бик юк. Хатка барын язып булмый, сорасаң, фронттан кайткан кешеләр әйтерләр ничек икәнен. Банат, җаным, инде Ходай Тәгалә гомерләр биреп, сезнең белән күрешергә язса ярар иде. Банат, җаным, монда төрлесен уйлата: яшь вакытлар булган икән, кадерен белмәгәнбез. Исән кайтсам, тора белер идек инде.



Ярый, Банат, без монда минут саен үлем көтеп җөрибез. Сау булыгыз, бәхил булыгыз, хушыгыз. Банат, тагын бер мәртәбә язам, белеп булмый, әллә актык хатым булыр. Хәбәрем килми торса, хат салмый торгандыр дип рәнҗемә. Үлсәм, хәер-догадан ташламагыз. Язылды 15 нче июльдә.»

«...Банат, монда иптәшләргә посылка килә башлады. Үзем дә посылка алдым, Мәскәү эшчеләре җибәргән иде. Шунда яхшы хезмәт итүче 7 армеецка бирделәр, миңа да бер посылка булды. Мин дә бер рәхәтләнеп ашап-эчтем. Посылкада нәрсәләр бар дип сорасаң: ак булкидан катырган сохари, бер кечкенә аракы, колбаса, ике пачка яхшы папирос, бияләй бер кием, бер кулъяулык, тәмәке янчыгы бар иде. Язылды 20. XI.

Монысын Нәүфәлгә язам: Нәүфәл улым, бик тырышып укы. Исән-сау кайтсам, гармун алып бирермен. Анаңның сүзен тыңла, өйне яхшы кара, аннары миңа хат яз, ярыймы, улым.»

«...Үземнең бер дә күңел курыкмый, бернәрсә дә булыр күк тими. Син дә, Банат, бик кайгырма, насыйп булса, әйләнермен дә кайтырмын әле.
Машинада барган чакта,
Тула күңелләребез.
Үкенечкә булмаса иде,
Узган гомерләребез. Бу хат язылды 3. VII. 42 ел».

(Салих солдатның хатлары улы Нәүфәл РӘХИМОВ (1975–1988 елларда Татарстан мех берләшмәсенең генераль директоры) гаиләсендә саклана. Хатларны кыскартып, үзгәртмичә тәкъдим итәбез.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте





Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова



Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Альбина Әбсәләмова
Фото: Газинур Хафизов

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы: 73002

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академия урамы, 2

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 30.04.2015 ел.
Заказ О-1268.
Тираж 7922.

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«ТАТМЕДИА» АҖ, филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сатуда бәясе ирекле.

9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

Солдатлар

Озатып вокзаллар каршында,
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.

Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга.

«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында...»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син, ана,
Айларны, елларны санап бар.
Күңелдә һаман яшь, гел бала –
Кайтмаган солдатлар, солдатлар.

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында.



Фото: Газинур Хафизов

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Ышаныгыз безгә, ветераннар

*Рәнҗемәгез безгә, ветераннар,
Гамьсез, мәнсез, кыйбласызлар, диеп.
Замананың саксыз җилләренә
Иңрисездер, чал башыгыз иеп.*

*Борчыласыз һаман, ветераннар –
Яуда калган дуслар ни әйтер?!
Сугыш кичкән күңел үрсәләнә,
Көч табалмый нидер үзгәртер.*


*Уйланасыз, ахры, ветераннар,
Тынычлыктан дөнья туйдымы?
Ата – улны, ана кызны белмәс
Таш бәгырьле буын тудымы?*


*Кичерегез безне, ветераннар,
Өзмәгез тик өмет дөньядан.
Җир йөзендә хәтер яшәгәндә,
Ваз кичмәбез әле кыйбладан!*

*Ышаныгыз безгә, ветераннар,
Хакыйкатьтән көчсез ялганнар!
Тарих шаһит: сез бит – кешелекне
Һәлакәттән йолып калганнар!*

*Соңга калмыйк, Сезгә – ветераннар,
Күрсәтергә кадер-хөрмәтне.
Еллар узган саен арта бара
Сез яулаган Җиңү кыйммәте!*







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



24

ҖЫЛЫ БОЛЫТ КОЧАГЫНДА

Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

ПАРЛАМЕНТ КӨН ТӘРТИБЕНДӘ...


М. Авзалова



18

ЙОЛДЫЗ СҮНГӘН, НУРЫ ЮЛДА ӘЛЕ

А. Юнысова



14

ДИНА ГАЗАЛИЕВАДАН ЭФИР ДРАЙВЫ

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





28

ЧӘКЧӘК ҖЫЕНЫ

Л. Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



КАРА САВЫТЫННАН... ХИКӘЯ — 34
Э. Закирова

ЯШӘЕШ 



46 «КӘЛӘШ» ЯКИ БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ
Р. Камалетдинова



VIVAT, КУБА! — 52
Г. Сафиуллина

ШУЛАЙ УК: 



38 ДӘҮ-ДӘҮ ӘНИ
Р. Зәйдулла

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 БЕЛӘЗЕГЕМ, ЙӨЗЕГЕМ...

ҺӘР САНЫБЫЗДА: 

БЕЗНЕҢ ПОЧТА — 6
ДӨНЬЯ ГАМЕ — 17
ШИГЪРИЯТ — 32
БЕР ҖЫР ТАРИХЫ — 44
РӘССАМ СӘХИФӘСЕ — 64



2

3

1

Кеше олыгая башлагач, үткән тормышы турында күбрәк уйлана башлый икән. Гомер барган саен, үзем дә үткәннәргә ешрак борылып карыйм.

Балачагым Аксубай районы Иске Кармәт авылында узды. Шул елларның бер хатирәсе бер дә онытылмый. Күршебез Нурҗиһан әби әти янына йомыш белән керсә: «Минхәер абзыкаем, ярдәм ит әле», – дип әйтер иде. Әти аңа бервакытта да булышмый калмады. Нурҗиһан әбидән: «Син бит Минхәердән олырак яшьтә. Ник соң аңа абзый дип дәшәсең?» – дип сорыйлар, ул аларга: «Аның хакы олы», – дип җавап бирә торган иде. Бу сүзләрнең мәгънәсенә күп еллар үткәч кенә төшендем. Хакы олы дип, миһербанлы, сабыр, тыйнак, ярдәмчел кешегә карата әйтәләр икән.

Әтием шушы авылда туып-үскән. Бөек Ватан сугышы башлануның беренче көненнән үк фронтка китә ул. Сугышта гарипләнеп, Фрунзе шәһәрендә госпитальдә дәвалана. Әмма инде башкача сугышка ярарлык булмый. Аны, инвалид белешмәсе биреп, авылга кайтарып җибәрәләр. Бераз дәвалангач, әтием күмәк хуҗалыкта бригадир булып эшли башлый. Тамагы ач, йончыган хатын-кызларга коры сөяккә калган сыерларын җигеп, эшкә чыгарга әйтергә кирәк. «Ничекләр генә итеп эшкә әйтим», – дип, капка төпләрендә кыенсынып басып тора торган була әтием. Сугыш бетеп, илдә тынычлык урнашкач, әти ат караучы булып эшләде. Атларга рацион буенча тиешле салам, печән, фуражын бик төгәл итеп бүлә, алар хакына керми иде ул. «Хайван хакына керергә ярамый, рәнҗүе бар», – ди иде.

«Сугыштан исән кайта алсам, урамга кое казып, күршеләргә су алдырыр идем, – дигән була әтием фронтта чакта. Шушы нәзерен үтәп, урамга кое казытты. Күршеләр күп еллар буе, рәхмәт әйтә-әйтә, шушы коедан су алдылар. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр чәй өчен генә дип су ала торган чишмәне дә чистартып, кыш көне боздан әрчеп, чиләк куеп торды ул.

Намуслы, тыйнак гомер кичерде әти. Акчага кызыкмады. Булганына шөкер итеп яшәде.

Җитмешенче еллар тирәсендә Ватан сугышында катнашучыларга инвалидлык бирү башланды. Мин авыл советында эшли идем. Ул вакытта пенсияләрне собеска барып билгеләтәләр, мин дә шунда киттем. Әтинең документларын алып килергә кушып җибәрделәр. Шунда әти ярты юлда туктатып: «Мәшәкатьләнмә. Аллага мең шөкер, мин әле исән. Пенсиям дә ярыйсы (аңа «Почетлы колхозчы» исеме бирелгән, авылдашлар 12 сум алганда, ул 38 сум пенсия ала иде). Күпләр анда сугыштан да кайта алмады әле», – диде.

Марсель Галиевнең «Моңаю» дигән шигыре бар:

Нәфестән узып шөкер әйт
Ходайның биргәненә.
Килә дә китә дулкыннар,
Килә дә китә генә...

Бу нәкъ минем әтием әйткәнчә. Ул шулай Ходайның биргәненә шөкер итеп, әнием белән бик тату гомер итте. 48 ел бергә яшәп, дөньяга алты бала тудырып-үстерделәр. Инде икесе дә бу дөньяда юклар.

Авыр сугыш елларын үтеп, аннан калган яраларны төзәтә-төзәтә, 70 ел тыныч тормышта яшибез. Киләчәктә дә тормышларыбыз матур, тыныч булсын иде. Якташ язучым Нәбирә Гыйматдинова әйтмешли, ике тумыйбыз, ике үлмибез. Иртән гел: «Бүген бәйрәм!» – диеп уян. Без дә шулай дип яшик.

Гөлшат ШИҺАПОВА.
Чистай.

Бөек Җиңү көнен һәр елны елыи-елый каршы алам. Сугыш башланганда миңа 3 яшь иде. Кечкенә булсам да, шул чор авырлыклары хәтеремә бик нык сеңеп калган.

Ул еллар минем күңелемдә авыр эш булып түгел, ачлык булып калка. Кырдан салам алып кайтканда аягын өшеткән әтием урын өстендә ята. Чери башлаган ул аягын кисканнәр. Биш малай һәм бер кыз үстергән әбием дә урын өстендә. Әнинең берүзенә ике

авыру һәм биш бала. Ул пешергән кычыткан ашын ашарга дип, барыбыз да җыелышып утырабыз. Миңа инде ул чакта дүрт яшь. Әнкәй аш бүлгәндә, тәлинкә кырыена кашык белән сугып, үземә иң күп өлешне дәгъвалыйм. Әни: «Кызым, апаларың эштән кайтып та моның кадәр күп ашамый. Әле бит сиңа әбиең дә үзенекен бирә», – дип, мине оялтмакчы була. «Тәмле булса, әби үзе ашап бетерә, тәмсезен генә миңа яларга бирә», – дим, үҗәтләнеп. Яшәү өчен шулай көрәшкәнбез инде. Олы апам укытучы булып эшли, аңа бераз он бирәләр иде. Шул онны кычыткан шулпасына кушып җибәрсәң, бик тәмле була торган иде. Безнең аш пешкән чакка гына турылап, күрше Әхмәтҗан абый керә. Әти аңа: «Кызыңны укытмадың бит шунда. Укыган булса, аңа да он бирерләр иде», – дип, Әхмәтҗан абыйга да аш бүлдерттерә.

Ач үлемнән безне әниемнең тегә белүе дә коткарды. Ун яшендә бабай аңа «Зингер» тегү машинасы бүләк иткән. Бабай хәлле тормышлы кеше булган. Әнкәйне мулла кызлары белән бергә мәдрәсәгә укырга биргән. Аны тәмамлагач, әнкәй үзе дә Буденный районы (хәзерге Чүпрәле районы) Шәйморза мәдрәсәсендә балалар укыткан. Бик күп Коръән аятьләрен яттан сөйли иде ул.

Оста тегүче дә иде әнкәй. Бөтен Бакырчы халкы тегү тегәсе яки кием төзәттерәсе булса, аңа килде. Тик сукыр лампа яктысында тегү тегеп, әнкәй 50 яшендә сукырайды. Шулай дөм сукыр килеш 32 ел яшәде ул. Шул хәлендә дә түшенкелеккә бирелмәде. Аны Коръән ашларына чакыралар, дога кылуын сорыйлар иде. Әнкәй бик матур итеп мөнәҗәтләр әйтә, үтемле итеп вәгазьләр сөйли торган иде. Кыш чыгар өчен әнкәйне Казанга алып киләм, ул килгәнне белүгә, туганнар, күрше-тирәләр аны Коръән мәҗлесләренә дәшә иделәр. Әнкәй сукыр килеш тә безгә һәм оныкларына оекбашлар бәйләде. 80 гә җитсә дә, хәтере искиткеч булды. Балалар шигырь ятлый башласа, ике кат укып чыгу белән үк исендә калдыра. Бүген-иртәгә сулышы өзелергә торганда да, шигырь ятлап ятты әле ул. Фәнис Яруллинның «Азат хатын» журналында басылып чыккан «Сагышларым бирдем җилләргә» дигән шигыре иде ул.

Синнән башка беркем
Күтәрә алмый, диеп,
Сагышларым кайтты үземә...

Кадрия ЗАҺИРОВА.
Казан.

Без ирем Миннегаян Маһияров белән яшь чагыбызда Башкортстанның Чакмагыш районы Иске Сөрмәт мәктәбендә эшләдек.

Ирем Миннегаян бик гаярь, батыр йөрәкле кеше иде. 17 яшеннән Бөек Ватан сугышында катнашкан. Кызыл Йолдыз ордены һәм күпсанлы медальләр иясе. Сугыш җәрәхәтләре, тормыш авырлыклары аны арабыздан иртә алып китте, озак яши алмады. Үз-үзен аямаган, сүз кодрәтенә ия, һәръяклап талантлы ир-ат иде ул. Гадел дә, таләпчән дә. Ул бер сүзне ике тапкыр кабатламас иде. Бер әйттеме – үтисең.

Әтиебез гаиләдә дә лидер булды. Хәтеремдә, балалар йокыда әле, ә ул мәктәпкә эшкә чыгып китәр алдыннан миңа, «бригадирга» һәр бала өчен эш кушып калдыра. Мин башта аларны урамга авыл балалары белән уйнарга чыгарам, аннары «Әтиегез тыкрыктан менеп килә» сигналына барысы да йөгереп кайтып кушкан эшен башкара. Ә миңа аш өстәле түрендә утырган әтиебезгә балаларының никадәр тырыш булулары турында мактанырга гына кала. Шундый терәгең булмаса, сигез баланы үстереп, кеше итеп кара! Барысы да югары белемле, полковник, галим, укытучы, инженерлар алар. Ә иң мөһиме – яхшы кеше булып үстеләр.

Әтиебез искиткеч тырыш укытучы да, оештыручы да булгангадыр инде, клубта бергәләп концерт-спектакльләр дә куя идек, политдәресләр уздыру да аңа йөкләнде. Халыкка үтемле, мәгънәле итеп газета-журналлардагы язмаларны сөйли иде. Сугыштан соңгы авыр елларда әллә никадәр газета-журналларга язылабыз, аларны күмәкләшеп укыйбыз.

Зирәк фикерле, тапкыр телле әтиебезгә уен-көлке дә бик килешеп тора. Күрше кызлары йомыш белән керсә: «Әнә «Азат хатын»да, Сания, синең хакта җыр чыгарганнар, ышанмасаң, үзең укып кара, синең генә көянтәң алмалы ич», – дип журналны аңа сузар иде. Бу аның тәрбияви алымы инде, яшьләр укысыннар, күрсеннәр, белсеннәр, янәсе. Алар алдагы көндә бала анасы булачак кешеләр бит. Кызларым да «Азат хатын» журналын укып үсте.

Былтыр җәй, инәем Хәтирә абыстай әйтмешли, «җиләк җыйган чорда» 90 яшемне уздырдым. Шушы яшемдә дә һаман «Сөембикә» журналы белән яшим. Күңелебезгә якын журнал ул. Хәзер газета-журналларның бәясе көннән-көн артып тора, язылу читенләште. Казандагы кызым аларны миңа почта аша җибәреп тора. Журнал хәзер дә без белмәгән яклары белән ачылып, тагын да кадерлерәк була бара.

Ерак Башкортстаннан сезне, хөрмәтле «Сөембикә» журналистлары, Бөек җиңүнең 70 еллык бәйрәме белән котлыйбыз, саулыксәламәтлек, уңышлар теләп калабыз. Әтием Галиәхмәт мулла әйтмешли, Ходай кодрәт бирсен сезгә!

Рәйханә ХАҖИӘХМӘТОВА.
Башкортстан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

Римма Атлас кызы РАТНИКОВА Татарстан Дәүләт Советына 2004 елгы сайлаудан соң килде. Парламент ишеген ачып кергән ул көннән соң унбер еллап вакыт узып киткән. Нинди иде дә, нинди булды ул?! Әллә ни үзгәрмәде дә шикелле. Гозер белән килүчегә булдыра алганча ярдәм итәргә тырышкан, елмаеп җибәрсә, шундый якын, шундый кадерле кешеңә әйләнә белә торган һаман да шул Римма Ратникова инде ул. Һәм бүген ул зур сәясәтче дә. Тормыш кыйммәтләре турында аның белән әңгәмә кору – үзенә бер рәхәт. Әмма андый минутлар бик сирәк эләгә. Ник дисәң, аның эш көне, сәгатьләп димим, минутлап, бер атнага алдан язылып куелган. Менә әле дә безгә: «Иртән – чит ил делегациясе белән Президент янында, аннары – Комитет утырышында, аннары – «Бердәм Россия» җыелышында...» – дип тезеп китәләр. Аңладык, аңламаган кая. Бер сүз белән әйткәндә, очрашу күпмедер вакытка кичектерелә. Килешәбез: чыннан да, вакыты юк. Татарстан Президентын һәм муниципаль, җирле үзидарә органнарына сайлауга әзерлек эшләренең кызган чагы. Парламент Рәисе урынбасары, «Бердәм Россия» партиясенең политсовет секретаре урынбасары Римма Ратникова шул уңайдан журналистлар белән матбугат конференциясе дә уздырды. Салмак-үтемле итеп сөйли башлауга ук, үзенә каратып куйды. Ул алда җитдидән-җитди эшләр торуы, партия эчендә алдан тавыш бирүнең (праймериз) бары «Бердәм Россия» партиясе тарафыннан гына кертелгән яңалык булуы, аның авыл җирлекләрендә беренче мәртәбә уздырылачагы хакында сөйли. Уйласаң, уйланырлык нәрсәләр бар монда. Исегезгә төшерәбез: 2005 елдан Россия регионнары җитәкчеләренә вәкаләтне Россия Президенты бүлеп бирә башлаган иде. Әмма Президентны турыдан-туры сайлау нормасы Татарстан Конституциясеннән алынмады, ә бәлки, вакытлыча туктатылды. Хәзер без яңадан Президентыбызны турыдан-туры сайлауларга әйләнеп кайттык. Без тагын мөһим чаралар алдында. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең гамәлләре белән ил-дөнья күләмендә танылган республикабызның киләчәге шул сайлауларга бәйле. Шөкер, без тынычлыкта һәм муллыкта яши торган халык. Бу юлы да сынатмабыз дип уйлыйм. Кызыксындырган бөтен сорауларга да җаваплар алынды шикелле. Вице-спикер китәргә ашыга. Аны эшлекле очрашулар көтә. Ә мин исә үземчә нәтиҗә ясыйм: быелның 13 сентябрендә узачак сайлау республикабызны янә бер баскычка күтәреп куяр. Без – Россия дигән зур ил эчендә үз хокукларыбызны үзебез билгеләп яшәрлек мөмкинлекләр таба алган уйлы-гамьле халык. Болай дигәндә, моннан чирек гасыр элек булган вакыйгалар искә төшә дә янә бер дулкынлану, республика өчен горурлану хисе кузгалып куя. Татарстан Югары Советы эшли башлаган беренче көннәрдән парламент хәбәрчесе, ул вакыйгаларның шаһиты булып йөргән кешегә, хәер, бер миңа гына түгел, барыбызга да ул вакытларда дөнья үзгәргән, күктәге кара болытлар мәңгегә таралган кебек тоелган иде.





ПАРЛАМЕНТ КӨН ТӘРТИБЕНДӘ...



Мәдинә АВЗАЛОВА

УТЫРЫШКА КУЕЛГАН ҺӘР МӘСЬӘЛӘ, КАБУЛ ИТЕЛГӘН ҺӘР ЗАКОН ПРОЕКТЫ ТАТАРСТАННЫ ДӨНЬЯДА ТАНЫТУГА, ХАЛЫККА МУЛ ҺӘМ ТАТУ ЯШӘҮ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ШАРТЛАР ТУДЫРУГА ЮНӘЛТЕЛГӘН.

«Татарстанга мәхәббәтне – гимн аша...»

– Татарстан тарихында яңа бер дәверне, җитди үзгәрешләр чорын башлаган ул вакытлар, ул вакыйгалар, республиканың йөзен ачып җибәргән – аны тугралы, гимнлы иткән көннәр... Шуннан бирле егерме ел вакыт узган. Гимн итеп композитор Рөстәм Яхинның музыкасы сайланды. Халык яраткан, күңелләрне айкап ала торган бөек, шәп музыка иде ул. Ә шәп музыкага шундый ук шәп сүзләр кирәк иде. Белүемчә, Сез җитәкләгән комиссия гимнның тексты өчен конкурс игълан итте, сүзләре йөзләгән проектлар арасыннан сайланды. Сез тарихка нәкъ менә шушы эшләрегез белән кереп калдыгыз да...

– Без ул чагында татар кешесе, гомумән, Татарстанда яшәүче халык өчен гимнга сүзләр сайлауның ни дәрәҗәдә җитди, җаваплы эш булуына тагын бер кат инандык.

Конкурсны үткәрү комиссиясенә килгән текстларны җентекләп өйрәндек. Тәкъдим ителгән җырларның һәркайсын Россиянең һәм Татарстанның халык җырчысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Зилә Сөнгатуллина белән бергәләшеп җырлап карадык. Әзер музыкага сүзләр язу авыр эш икән ул. Без «Батыр» дигән исем астында җибәрелгән сүзләргә тукталырга булдык. Беренче конвертта – шигырьнең сүзләре. Икенчесендә – аны җибәргән кеше турында белешмә. Ул фронтовик шагыйрь Рамазан Байтимеровның кызы Гөлшат булып чыкты. (Узган гасырның 70 нче елларында Рөстәм Яхин әлеге әсәрен дусты – фронтовик шагыйрь Рамазан Байтимеров белән килешеп иҗат иткән. Шигырьне шагыйрь 1972 елда, ТАССРның 50 еллыгына багышлап язган булган. «Туган ягым» дигән шул җырны шагыйрьнең кызы Гөлшат, Гәрәй Рәхим белән берлектә, яңадан эшкәртеп, тирәнрәк мәгънә салып тәкъдим итте.) Без аны иң яхшы проект дип таптык. Әмма безгә текстның русчасы да кирәк иде. Гимн ике телдә – татар һәм рус телләрендә башкарылырга тиеш. Аны татары да, рус кешесе дә җырларга тиеш. Рус текстына берничә вариант тәкъдим ителде. Нәтиҗәдә, арадан яшь шагыйрь Филипп Пираевның тәрҗемәсе сайлап алынды. Безнең гимн «Татарстан Республикасында дәүләт символлары турында»гы закон белән ныгытылган. Аны закон саклый. Аңа берәүнең дә тел-теш тидерергә хакы юк. Дәүләт символларына без хөрмәт белән карарга тиеш!

– Сүз дә юк, Татарстан парламенты тарихындагы җаваплы эшләрнең берсе булган ул. Инде узганнан бүгенгегә кайтыйк. Без яңартылган дәүләтчелектә яши башлаган 25 ел эчендә бик күп нәрсәгә ирештек. Әмма, тәҗрибәдән күренгәнчә, регионнардан кергән закон проектларының бик азы гына Федераль Җыенда хуплау таба. Субъект хокукларын кысу түгелме бу?

Федераль законны үзгәртү – озакка сузылган катлаулы эш ул.

– Дөрестән дә, мәгълүматларга караганда, регионнардан кергән тәкъдим-инициативаларның нибары ике проценты гына закон буларак кабул ителә. Әйтик, Дәүләт Советы Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы белән мөрәҗәгать итте, ди. Аны башта Дәүләт Думасы Советы карый, аннан соң закон проекты профиль буенча караучы җаваплы комитет кулына күчә. Әлеге инициатива шуннан соң гына төбәкләргә җибәрелә. Регионның фикере исәпкә алынсын өчен, әлеге проектны президент, йә губернатор һәм регионнардагы парламент йә хупларга, йә кире кагарга тиеш. Сүз дә юк, дәвамлы һәм бик четерекле эш. Ләкин субъектларның

күпчелеге кайсыдыр бер субъектның инициативасын хуплау турында карар кабул иткән очракта да, соңгы – хәлиткеч сүзне Дәүләт Думасы әйтә, ул кабул итә законны. Дума хәтта күпчелек субъектлар хуплаган йомгаклауны да кире кагарга мөмкин.

Парламент Рәисе Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшин бу мәсьәләне югары дәрәҗәдә бер генә мәртәбә күтәрмәде инде. Ләкин сәяси чынбарлык шундый. Бу катлаулы механизм илне бердәм хокукый кысаларга кую ихтыяҗы чыккан елларда кертелде. Хәзер бурыч үтәлде, тик ирешкәнне сакларга кирәк әле. Әйтергә кирәк, субъектларның закон чыгару инициативасы еш кына гамәлдәге федераль законның концепциясенә каршы килә. Региональ парламентлар күп вакыт капма-каршы идеяләр белән чыга. Ә моны бер федераль законда гына исәпкә алып бетерү мөмкин түгел. Бердәм хокукый кысаларда яшибез бит.

Гамәлгә ашмастай вәгъдәләр биреп, юкка өметләндермәгәндә генә халык депутатларга ышаначак.

Безнең кайбер конкрет инициативаларыбыз Думада икенче укылыштагы төзәтмәләрне кабул иткәндә исәпкә алына алынуын. Әмма төзәтмәләрне янә Дәүләт Думасы депутатлары кертә. Башкача әйткәндә, без «авторлык хокукы»бызны югалтабыз. Хәер, төзәтмәнең кем тарафыннан кертелүе бу очракта ул кадәр үк мөһим түгел. Закон эшләсен генә... Бер сүз белән: урыннарда закон проектын кабул итү статистикасы безнең файдага түгел, дияр идем. Кайчак проект нибары килештерелмәү сәбәпле генә, Дәүләт Думасыннан закон булып чыгып җитә алмый. Биредә хәтта документны редакцияләгәндә киткән хата да яисә юридик техниканы бозу да закон проектының язмышын хәл итәргә мөмкин. Хәзер без бу киртәләрне әйләнеп үтәргә өйрәндек. Шунысы да бар, еш кына проектлар Россия хөкүмәтенең тискәре фикере аркасында, бигрәк тә ул акчага бәйле булганда, зур финанс чыгымнары таләп иткәндә гамәлгә ашмый кала. Бюджет аша җыйганны гына бүләргә була. Өстенлекле юнәлешләргә урын бирелүен истән чыгармыйк. Хөкүмәт белән идеяләреңне алдан ук тәгаенләп куярга кирәк. Шундый бер очрак булды: Дәүләт Советы безнең Эчке эшләр министрлыгы тәкъдиме белән закон проекты эшләде. Ул тиешле процедураларны үтеп, Дәүләт Думасы Комитетына барып җитте. Россия Эчке эшләр министрлыгы вәкиле әлеге тәкъдимгә каршы чыкты. Безнең коллегалар мәсьәләне алар катнашында тикшермәгән, фикер алышмаган. Шулай итеп, проектны кире кайтардылар. Җитлеккән илләрдә бу лоббизм – парламент карарларын кабул итү барышына басым ясау дип атала. Ул илләрдә хәтта лоббизм турында закон да бар. Ә бездә юк.

Буш вәгъдәләр бирмәскә!

– Халыкны гел кризис белән куркытып торалар. Безнең республика да кыенлыклар кичерә. Мондый хәлдә Парламентның яклауга мохтаҗ гаиләләрне, инвалидларны кайгыртырга тиешле Социаль сәясәт комитеты һәм «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе халыкка нинди игелекле эшләр күрсәтергә җыена? Шушы уңайдан редакциягә килгән бер хаттан өзек китерим әле: «Сессия утырышларының берсендә, – дип яза автор, – яшь ярымнан өч яшькәчә кадәрге баласы белән өйдә утырырга мәҗбүр аналарга пособие түләү мәсьәләсе күтәрелде. Ә безнең Светлана Захарова (комитет рәисе, – *авт.*) трибунага чыкты да, акча булмау сәбәпле, әлеге мәсьәләне кире кагарга тәкъдим итәм, дип, мине телсез калдырды. Ә бит баласын бакчага урнаштыра алмыйча, бер әти кешенең хезмәт хакына – очын-очка ялгап яшәүче гаиләләр бик күп!» Хат авторына ни диярсез? Электрон чиратларга ышаныч чамалы. Бәлкем, бу хәлләрне көйләү өчен махсус карармы, законмы кирәктер...

– Быел хәлләр, чыннан да, бик авыр. Күреп торасыз ич, бер-бер артлы явып торган санкцияләр ил һәм республика икътисадына нинди зыян салды. Нефтькә бәяләрне генә карагыз әнә. Өстәвенә, акча, доллар белән нинди хәл килеп чыкты... Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлы башкаручы Рөстәм Миңнеханов матди кыенлык кичерүчеләр алдындагы бурычның, социаль программаларның һәм йөкләмәләрнең үтәлеп барылуы турында гел әйтә килә. Ә халык тормышның көннән-көн алга баруын, яхшыруын көтә. Ул шулай булырга тиеш тә.

Мондый хәлдә безнең үзебезгә дә сайлаучыларны кабул итү җиңел түгел. Әле күптән түгел генә миңа өлкән яшьтәге бер апа килде. Үзе гомер буе балалар бакчасында эшләгән, бернинди уңайлыклары булмаган кечкенә генә бер фатирда яши. «Фатирымны алыштырыр өчен миңа 500 мең сум акча бирегез», – ди. Кызганычка каршы, хәзер бушлай фатир бирү дә, торак сатып алуга акча бүлеп бирү өчен закон да юк. Кеше аңламый: ул әле һаман социализм чоры идеяләре белән яши.

Депутат Захарованың чыгышына килгәндә... Утырышларда төрле социаль проектлар тәкъдим ителә. Без ул тәкъдимнәр өчен җан тырмашабыз, комитетларда җитди сөйләшүләр алып барабыз. Хөкүмәткә, авыр яшәүче халыкның хәлен яхшырту максатында, акча эзләргә-табарга кирәклеген аңлатырга, шуны төшендерергә тырышабыз. Әмма акча, чыннан да, юк. Мөнбәрдән тикмәгә сүз куертуның мәгънәсе бармы? Анда чыгып, эш кыргандай кылану – безнең алым түгел. Күңелгә тигән андый сүзләрне депутат Захарова түгел, ә бәлки, хөкүмәт әгъзаларының берәрсе әйтергә тиеш булгандыр.

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН:

– Ир – баш, хатын – муен дигәнгә ничек карыйсыз?
– Безнең гаиләдә – тигезлек.
– Сез – дәүләт кешесе, ирегез өйдәге эшләргә булышамы?
– Булыша, әйтсәң, шундук ипигә дә чыгып йөгерә, әйтергә генә кирәк. *(Ул көлеп җибәрә.)*
– Нәрсәне кичерә алмыйсыз?
– Җавапсызлыкны...
– Бик рәнҗетсәләр дә гафу итә аласызмы?
– Мин тиз кайтып төшә торган кеше, гафу итә алам.
– Сезне нәрсә бик куандыра, бәхетле итә?
– Барына да куанам: яңа таң атканга, аның хәере белән килгәненә, гаиләмдә тынычлык-исәнлек булганга, эштән кайтуыма «әни» дип каршыма улым йөгереп килгәнгә... барына, барына...
– Тәмле әйберләр пешерергә вакытыгыз каламы?
– Юк, калмый. Ә болай... әни өчпочмак пешерергә дә, бәлеш салырга да өйрәтте. Бик теләсәм, вакытым булганда, тәмле итеп пешерә дә алам.
– Сез тагын нинди һөнәр сайлар идегез?
...Ул уйлана кала, журналист та, олы сәясәтче дә булган кеше тагын нинди һөнәр турында хыяллансын инде?! Тормышта ул барына да ирешкән ич!



Тик моннан ни үзгәрә?! Барыбер акча юк бит. Кайвакыт кискен-кискен сүзләр дә әйтергә туры килә шул. Депутатның, булмаган вәгъдәләр биреп, халык хисләре белән уйнарга хакы юк!

Баласы белән өйдә утырырга мәҗбүр әниләргә пособие мәсьәләсе дигәннән... Республиканың бу өлкәдәге сәясәте – балалар бакчалары төзү. Тиздән өч яшьтән җиде яшькәчә бала-чаганың барысы да балалар бакчалары белән тәэмин ителәчәк. Иң бәләкәчләр өчен ясленләр төзүгә дә чират килеп җитәр. Әгәр дә әти-әниләргә акча өләшә башласаң, бакчалар төзергә акча калмый. Йә төзибез, йә шул акчаны ашап бетерәбез. Керемнәре аз булган әниләргә бишәр мең акча бирү нормасы керткән регионнар хәзер ни эшләргә белми. Әниләр акчаны ала, баланы бакчага йөртми. Нәтиҗәдә, балалар бакчалары буш тора. Безнең коллегалар бу адымны ялгыш булган дип исәпли. Минемчә, иң яхшысы, азрак сабыр итәргә. Аның каруы, барлык балаларны да мәктәпкәчә учреждениеләр белән тәэмин итү мөмкинлеге булачак. Халык күңеленә шом-коткы салучы депутатлар популистлар алар. Кем инде үз халкына каршы эшләсен? Йә, әйтегез: президентмы, министрмы, депутатмы? Минемчә, юк... Без халыкка бары игелек кенә телибез! Кызганыч, сәясәт ул – мөмкин кадәренчә дөрес гамәл кылу сәнгате.

Балаң белән бергә үсәсең...

– Сез үзегез дә әни кеше. Һәрьяклап тискәре мәгълүмат агылган бүгенге катлаулы дөньяда сабыйны золым-җәберләүләрдән, рәхимсезлек күренешләреннән ничек саклап калырга? Дәүләт эшлеклесенең бу вазгыятькә карата фикере нинди? Соңгы вакытта тәрбиягә алган ятимнәрне кире кайтару очраклары күбәя башлады. Бәлкем, мондый әниләрне җаваплылыкка тартырга кирәктер. Алганчы ныклап уйласыннар. Уйнады да ташлады булмасын!

– Әлбәттә, мин ятимнәрне кире кайтаруга каршы. Бу – дөрес эш түгел. Бу – миһербансызлык. Алар бит инде бер кичергәннәр бу фаҗигане, аларны бит инде бер ташлаганнар. Ләкин шулай да һәр очрак аерым каралырга тиеш. Ни өчен, гаиләдә ниләр булган?! Йөз төрле сәбәпләр булырга мөмкин. Шуңа күрә биредә кистереп кенә, кискен генә әйтергә ярамый.

Килешәм, бүгенге чор балаларына җиңел түгел. Әйе, алар бихисап мәгълүмат диңгезендә ничек тели, шулай йөзә. Ләкин алар янында без – әти-әниләр бар. Балага киңәш-ярдәм кирәк икән, дөрес юнәлеш бирү өчен без кулдан килгәннең барын эшләргә тырышабыз. Мисал эзләп ерак китмим. Үземнән чыгып кына әйтәм: ни гаҗәп, балам миңа гаилә бәхете генә китерми, ә бәлки, дәүләт эшлеклесе буларак, күп кенә белем дә бирә. Читтә торган, миңа кагылмаган шикелле тоелган проблемалар да бер заманны үземнекенә әйләнә. Чөнки мин инде битараф кала алмыйм.

> *Иң куркыныч: гаиләләрдә мәхәббәт дигән төшенчә югала. Билгеле, бу мине нык борчый.*

Минем дә улым үсеп килә. Тиздән аңа 10 яшь тула. Әйләнеп карыйм да, хәйран калып торам: егет булып килә икән бит инде ул, аны әнә хәзер кызлар кызыксындыра, сүзләре дә кайчак төртмәчәнечкеле чыга – үзсүзле, кыскасы. Әгәр дә улым булмаса, яшүсмерлек чоры 13–15 яшьтә башлана дип йөрер идем. Хәзер мин яшүсмерлек чоры психологиясе турында китаплар укыйм. Алда безне аның белән җенси аерма турында җитди сөй-

ләшү көтә. Табиблар белән киңәшләшәм. Балалар хәзер иртә өлгерәди алар.

Менә карагыз инде, моннан ике-өч ел элек мәктәпләрдә кыз һәм малайларга авырга ничек узмаска, нинди саклану чаралары кулланырга, нинди гормональ препаратлардан файдаланырга кирәклеген сөйләп йөдәтәләр иде. Әйтерсең, җенси тәрбия мәсьәләсе инде күптән хәл ителгән. Хәзер хәлләр әкренләп уңай якка үзгәрә башлады. Иртә җенси мөнәсәбәтләргә керүне безгә Көнбатыш тага. Шул рәвешле гаилә традицияләрен, идеалларны юкка чыгарырга азаплана. Яшьләр никахлашмыйча, язылышмыйча гына яши бирә. Ир кешегә уңай бит: бер-бер хәл булды исә, ташлый да чыгып китә, хатын белән бала алдында җавап тотасы юк. Аны моңа беркем йөкли алмый.

Безнең Җиңүне юкка чыгарырга телиләр. Тарихны сызып ташлап булмый, ул фактларга нигезләнгән.

«Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар төркеме уздырган утырышларда мин бу мәсьәләне даими күтәрә киләм. Мәктәпләргә гаиләне өйрәнү дәресләре кертү кирәклегенә иманым камил. Шунсыз булмый. Шунсыз бала гаиләдәге гореф-гадәтләр, гаилә кыйммәтләре турында берни белмәячәк.

Бер уйласаң, күпме бала гаиләдә, формаль булмаган төркемнәрдә җәберләнә?! Бусы тагын да бер чаң сугарлык проблема. Тикшерү органнары да борчыла: баланы кыерсыту фактлары хакында алар соңга калып беләләр. Чөнки «табиб сере» дигән нәрсә бар. Һәм ул серләрне табибның берәүгә дә ачарга хакы юк. Проблеманы тирәннән өйрәнергә кирәк. Ник дигәндә, барысы да күзгә ташланып тормый. Әйтик, прокуратура закон буенча, дип, җәберләнгән балаларны үзенә чакырта башласа, аларга тагын да ныграк, тагын да тирәнрәк җәрәхәт ясалуы бар. Ә инде җинаять эше ачмасак, җинаятьче рәхәтләнеп иректә йөриячәк һәм кабахәтлек эшләвен дәвам итәчәк. Хәзер бу мәсьәләләрне без җентекләп өйрәнәбез. Якын арада шушы мәсьәләгә багышлап «түгәрәк өстәл» уткәрергә уйлыйбыз. Ләкин бер закон кабул итеп кенә, йә булмаса, аны үзгәртеп кенә проблеманы хәл итә алмавыбыз көн кебек ачык. Чит кыйммәтләрне якын китермәскә, бөтен дөнья белән шуңа каршы торырга өйрәнергә кирәк безгә! Дәүләт органнары структурасында төрле ведомстволарга таралган гаилә сәясәте эшләрен бер йодрыкка туплый торган җаваплылык үзеге булырга тиеш дип саныйм. Без озак еллар гаилә төзү, никахлашу, җенси мөнәсәбәтләргә керүне һәркемнең үз эше дип уйлый килдек. Юк, дәүләт бу мәсьәләдән читтә калырга тиеш түгел. Шәхси тәҗрибәм миңа бу проблемага якынаерга кирәклеген күрсәтә.

– Кызының шундый зур урыннарда утыруына, күренекле дәүләт эшлеклесе булуына әниегез горурланадыр?

– Горурланганын күргәнем юк. Ә менә: «Син хөкүмәт кешесе, син булышырга тиеш», – дигәнен еш ишетәм. Без гаиләдә өч бала, мин – иң олысы. Әти (гомер буена җаваплы эшләрдә эшләде, соңгы елларында Кукмара районы партия комитетының беренче секретаре булды. – *Авт.*) мәрхүм булганнан соң, Булатовлар гаиләсе өчен бөтен җаваплылык минем өскә төште. Мин аны шулай булырга тиеш дип кабул иттем. Әни укытучы безнең, белгечлеге буенча – тарихчы. Мәктәптә эшләгәндә нинди булгандыр, әйтә алмыйм. Ә менә өйдә ул безне коры тотты. «Әтиегез белән мактанып йөрмәгез. Үзегезне башкалардан өстен куймагыз», – дип гел кисәтеп торды. Безгә башкалардан артык киенергә дә ярамады. Әнием – данлыклы, күренекле Ризаэтдин Фәхретдин нәселеннән. Бабайны бик мул тормышлы булган дип сөйлиләр. 114 яшенә җитеп үлгән әбиемнең әбисе сәнәкчеләрнең өйләреннән әллә 17, әллә 19 төргәк әйбер алып чыгулары турында сөйли торган иде. Сабирҗан бабай 1937 елда гарәп китапларын мичкә яккан. Мичкә ягылган тарих, диярсең. Бабай Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк сугышка алына. Аның: «Без Смоленск янында...» дигән бердәнбер хаты килә. Һәм шуннан соң хәбәрсез югала.

Үткәнне онытканның – киләчәге юк

– Инде сугыш турында сөйли башлаганбыз икән, дәвам итик. Совет халкының Бөек Җиңүен, безнең солдатларның күп илләрне, күп җирләрне фашист илбасарларыннан азат итүче буларак тарихка кереп калуын Көнбатыш илләре «онытырга» маташа. Имеш, ул Бөек Ватан сугышы түгел, ә бәлки, Икенче Бөтендөнья сугышы булган.

Ә безнең ул сугышта 27 миллионга якын кеше югалтуыбызны оныткан булса кирәк алар... Тарихны бозып, ялганлап күрсәтү бара...

– Дөньяда нинди хәлләр барганын күреп торабыз. Ул бүген Украина мисалында бик яхшы чагыла. Бу хакта сүз куертмыйча гына шуны әйтәсе килә: үз тарихын белмәгән кешене бик тиз тезләндерергә була. Чөнки ул үткәнен белми. Ә үткәнен белмәгән кешенең нинди киләчәге булсын? Без моңа кайбер илләр, ничек кенә тырышмасын, ялган мәгълүмат таратмасын, юл куймабыз. Гәрчә безнең республикада да күңелне тетрәндерердәй андый мисаллар булгалап ала.

Бер очрашу искә төшә. Бу – 1990 нчы еллар иде. Минем яшьләр газетасында эшләгән чагым. Яныма сугыш ветераны килеп: «Урамга Җиңү көнендә медальләремне тагып чыгарга куркып торам хәзер», – дип әрнеп сөйләгәнен хәтерлим. Тарих китаплары киредән языла башлады, юк-юк та сугыш каһарманнарының батырлыгын инкарь итеп, ялганлап күрсәтү күренгәләп китә. Мәктәпләрдә хәтта дәреслекләрне үзгәр-

тергә керешкән вакытлар да бар иде. Исегездәдер, нәкъ шул вакытларда без Казаныбызга мең ел тулу мәшәкатьләрен башлап җибәрдек. Игътибарны, кичекмәстән, файдалы, патриотик рух үсти торган чараларга юнәлтергә кирәк иде.

Алай дисәң, безгә АКШ тарафыннан һөҗүм һаман дәвам итә. Мәгълүмати һөҗүм диюем. Әмма без бу шау-шудан күпкә өстен. Шушы көннәрдә генә Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үттек. Безнең ил өчен ул – изге бәйрәм. Сугыштан соң Советлар Союзы дөньяда иң көчле державаларның берсенә әверелде. Бу җиңүнең бәһасе дә, без түләгән бәя дә әйтеп бетергесез зур. Сугыш безгә бик күп югалтулар китерде, халык хуҗалыгына коточкыч зыян салды. Кызыл армиянең, Совет армиясенең нинди дошманга каршы көрәшүен аңларга, балаларыбызга аңлатырга кирәк безгә! Фашистлар илебезне, аның табигый байлыкларын яулап алырга гына килмәде. Алар безнең халыкны бетерергә, җир йөзеннән юк итәргә дип килде. Бүгенге буын шуны аңласын иде: ул сугышның асылы – ария расасын барлык халыклардан өстен куеп, калганнарны – төрекләр, славяннар, угро-финнарны икенче, өченче сортлы кеше калдыклары дип, кыру... концлагерьларда яндыру, ату, асу, колларга әйләндерү өчен төрле тәҗрибәләр үткәрү! Шундый иде бит аларның максаты. Безнең туганнар, бабаларыбыз үтерүгә дучар ителгән булыр иде. Без – сугыштан соңгы чор буыны туарга, якты дөньяны күрергә дә тиеш булмаганбыз. Әмма Советлар Союзы бу дөньякүләм вәхшилекне туктата алган! Үз халкының бәхете, иминлеге исәбенә булса да. Кайберәүләр шикелле, ничек итеп Гитлер белән Сталинны бер яссылыкка куеп була шуннан соң?! Әйе, аның да ярамаган эшләре, хаталары күп булды, әмма безнең илдә беркайчан да бер генә расага да өстенлек бирелмәде.

Безнең халык – зур тарихлы халык. Һәм безгә үткәнебезне берничек тә онытырга ярамый.









ҮТКӘННӘРДӘН

■ 1990 елның 30 августы. Татарстанның яңа сайланган Югары Советы Дәүләт Суверенитеты турында Декларация кабул итте.

■ 1991 елда кайбер депутатлар, шул исәптән Югары Советның 14 даими комиссиясе рәисләре закон чыгару эшләрен даими нигездә алып бара башладылар. «Народовластие», «Суверенитет», «Татарстан», «Согласие» төркемнәре һәм фракцияләре барлыкка килде.

■ 1992 елның мартында Референдум булды. Ул Татарстан Республикасының, халыкара хокук субъекты буларак, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрне тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә кора алуын таныды. Татарстан бу авыр сынауны зирәк, акыллы җитәкчеләре ярдәме белән уңышлы үтә алды.

■ 1992 елның 6 ноябрендә уникенче чакырылыш Югары Советы Татарстанның яңа Конституциясен кабул итте. Республиканың яңа дәүләт символлары расланды, 120 дән артык закон кабул ителде.

■ 1998 елның маенда Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, вазыйфасына керешүгә үк, Берлинда уздырылган 5 нче Европа форумында республиканың парламент практикасын камилләштерү буенча Европа программаларында катнашырга әзер булуын белдерә. Республика мәнфәгатьләрен федераль законнарга яраклаштыру өчен бәхәсләр дә шактый кыю барды. Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип бәяләнгән законнар өйрәнелә һәм килештерелә. Һәм, ниһаять, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы закон мөһим вакыйгаларның берсенә әверелә.

■ 1995–1999 елларны халыкка йөз белән борылу чоры дияргә дә мөмкин. Татарстан Дәүләт Советы Россия Федерациясе белән Килешү төзегәннән соң, республика язмышын хәл итәрдәй күп кенә законнар кабул ителә. Ул чагында халык күңелен кузгатырдай бик күп эшләр эшләнә: җимерек йортлар бетерелә, нефть тармагы кризистан чыга, авыл хуҗалыгы кискен үсеп китә. Әлбәттә, бу уңышларда депутатларның да өлеше әйтеп бетергесез. Законнар эшләүдә алар хәтта Россия депутатларын да уздырып җибәрә.

■ Инде 1999–2003 елларда эшләгән депутатларны алыйк. Иң кыенын алар күрә: эшләнгән законнарны федераль законнар белән яраклаштыру башлана.

■ 2004 елгы сайлауларда кертелгән иң зур яңалыкларның берсе – халык илчеләрен партия исемлеге буенча сайлый башлау. Бу – Парламент составын кискен үзгәртте.

Май – Татарстан журналистикасы өчен аеруча үзгә ай: республика матбугатының туган көне. 19 майда Татарстан журналистикасының 110 еллыгын бәйрәм итәбез быел. Юл башы Санкт-Петербургта беренче татар газетасы «Нур»дан чыга башлаган. Һәм шушы дәвердә Татарстан журналистикасы нинди генә киңлекләр яуламады да, нинди генә яңа медиаресурслар барлыкка килмәде!
«Татарстан–Яңа гасыр»ның Мәскәүдәге филиалы өчен исә ул икеләтә бәйрәм! Башкалада республикабызның беренче медиа ресурсы, ДТРК корпункты оешуга 15 ел тулды. Соңрак аны «Татарстан–Яңа гасыр» (ТЯГ–ТНВ) Телерадиокомпаниясе филиалы итеп үзгәрттеләр. Аның «йөзе» һәм җитәкчесе итеп Дина Газалиева билгеләнде. ТНВ Мәскәү төбәгендә яшәүче миллион ярым татарны тарихи ватаннары белән бәйләүче күпергә әйләнде. Социаль бурычлар, рәсми чаралар, Татарстан җитәкчелегенең Мәскәүдәге эшчәнлеге... Болар һәркайсы телевидениенең көн тәртибендә урын алды. Ә узган елдан башкаладагы ТНВның функцияләре рәсми рәвештә «Татмедиа» Республика Агентлыгы Вәкиллеге дәрәҗәсендә киңәйтелде. Филиал яңа бурычларны хәл итәрлек итеп тулыландырылды, анда яңа студия барлыкка килде. Башкаланы яулар өчен журналист нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Татарстан–Яңа гасыр»ның Мәскәүдәге филиалы үз эшен оештырганда нинди бурыч-максатлар куя?
Дина ГАЗАЛИЕВА шулар хакында сөйли.



ЭФИР ДРАЙВЫ

Башкала безне кочак җәеп көтмәде...

Атна буена ниләр эшләп йөргәнеңне йөз меңләгән кеше көне-сәгате белән телевизор аша белеп тора икән, онлайн режимыннан бер дә ким түгел. Кайларга баргансың, кемнәр белән күрешкәнсең... Кайчак ел буена да күрмәгән танышыңны очратып, хәл-әхвәл алышырга да өлгермисең – ул шундук сорауларга күмеп ташлый: «Кичәге концерт ничек, ошадымы?» Яисә: «Премьер-министрдагы киңәшмә ничек булып бетте?» Тагын әллә ниләр... Тамашачыдан бернәрсәне яшереп булмый! (ТНВның спутник телеканалы икәнен, аны илнең барлык төбәкләрендә һәм чит илләрдә дә карауларын искәртсәк – бу миллионлаган кеше дигән сүз.) Әлбәттә, җаваплылык та зур: Татарстанны Мәскәүдә танытабыз бит! Үз-үзебезне тотышыбызга, профессионализм дәрәҗәсенә карап, республикабыз матбугатына бәя бирәләр. Журналистикада ун еллык тәҗрибәм, рәсми тематикадагы эшләрем бар иде инде, әмма беренче көннәрдә башкалада үземне бер чебеш кебек хис иттем! Баштагы вакытта күбрәк бүтәннәрне тыңларга, кешеләрне, «уен кагыйдәләрен» өйрәнергә туры килде. Татарстанда – үзебездә күпләрне беләм, миңа да үз кеше итеп карыйлар иде. Ә биредә, дуслардан һәм МГИМОда бергә укыган группадашлардан кала, беркемне белмим. Әкренләп танышларымны арттыра, Мәскәү телевидениесендәге коллегаларның эшләү алымнарын күзәтә башла-

дым. Ике югары белемем, аралашу күнекмәләрем, барыннан да бигрәк, холкым яңа эшемдә ярап куйды. Яшерен-батырын түгел, Мәскәүдә төбәк телеканалына ишекләрне киереп ачарга берәү дә атлыгып тормады. Ә без, Татарстан телевидениесендә чыныккан холкыбызны чарлап, ишекләрне ачтырдык! Канадага, Ванкуверга командировканы искә төшерәсе килә. Кышкы олимпиада уза иде анда. Безнең спортчылар өчен уңышсызрак бара ярышлар... Россия җыелма командасының җанатарлары булып, без аларга көч биреп утырабыз! Безнең, татарстанлыларның тагын бер зур эше бар иде әле – Универсиада дирекциясендәге коллегалар белән Җәйге уеннарга презентация уздырасы бар. Самолеттан төшүгә үк эшкә керештек. Мәскәү вакыты белән аерма – 10 сәгать! Барыбызның да күзләр кызарган – ярты тәүлек буе очтык бит... Шуңа да карамастан, елмаерга, аралашырга, сюжетлар төшерергә кирәк. Төнлә Россия белән телефоннан сөйләшәбез (анда эш көне), ә көндез Канадада кызу эш көне башлана (Мәскәүдә төн) – без тагын вакыйгалар үзәгендә... Күнегелгән гадәти тормыш графигы баштанаяк үзгәрә. Барысына да җитешергә, эмоциональ киеренкелектә үзеңне сынарга кирәк була. Анысы тагын үзгә бер кызык халәт.

Бирешмәс холык

Холык турында сүз чыкса, телевидение өчен үзем әзерләгән иң беренче тапшыру искә төшә. Ул криминаль хроникага багышланган сюжет иде. «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә беренче курс студенты өчен чын мәгънәсендә имтихан булды ул! Үзеңне кулда тота алуга да, оперативлыкка да, тирә-юньдәгеләр белән аралаша белүгә дә... Куркыныч, үзәк өзгеч моментлар булса да, мин бу имтиханны уздым – аңынчы «Татарстан» телеканалында яктыртылмаган криминаль тематиканы алып баруны миңа тапшырдылар. Яшермим, бу четерекле өлкәгә һич күнегеп бетә алмадым. Ләкин мондый хәбәрләр каналның рейтингын да күтәрә шул! Шунда туплаган тәҗрибәм аркасында никадәр кызыклы кешеләр белән таныштым, күп нәрсәгә төшендем, теләсә нинди, хәтта уңайсыз шартларда да эшләргә өйрәндем.

Шулай да үзем өчен иң кызыклы интервью Бөек Ватан сугышы ветераны, генерал Алмас Мәхмүт улы Әдһәмов белән булды! Ул Ржев янында сугышкан. 90 яшьтә социаль челтәрләрне үзләштергән, иҗтимагый тормышта кайный, бүген дә төз гәүдәле чын офицер ул! Андый кешеләр белән очрашу мине һәр яңа туган көнгә шатланып карарга өйрәтте.

Мәскәү тәвәккәллеккә ышана

Гадәттә, күпләр журналист эшенең ничек бәяләнүе турында уйлап та карамый. Кемгәдер ул эш бик җайлы тоела – килдең, күрдең, сораштырдың һәм китеп тә бардың. Тик алай гына түгел шул әле. Алдан ныклап әзерләнергә, бөтенесен белергә, өйрәнергә, ахыр килеп, кирәкле чарага, очрашуга эләгергә! Ә кешене сөйләштерү? Үзеңә җәлеп итү? Һәр журналист өчен таныш кагыйдә бу. Ләкин телевидениедә әңгәмәдәшеңнең эмоцияләре дә кадрда күренергә тиеш әле! Кул хәрәкәтләре, елмаю, уйланып тору, гаҗәпләнүләр, ялыктырмый торган сөйләм, битараф булмаган йөз... Әңгәмәдәшең үзен иркен тотсын, якты утка, микрофонга ияләшсен. Күпләр «ябыла», кыенсына башлый бит. Телевидение журналистикасының сүз һәм видеодан торуы берәүгә дә сер түгел. Кадр артындагы текст материалга фикер юнәлеше бирә, әмма видеорәтләрсез интервью радиорепортажга әйләнә! Һәм иң мөһиме, әлбәттә, командада эшли белү. Бер-береңне ярты сүздән аңлау бик кирәк шул! Редактор, техник хезмәткәрләр, тавыш куючылар... Ашыгыч материалны төшереп кайтып, эфирга әзерләү шунсыз барып чыкмаячак. Интервью, стенд-ап, текст, тавыш яздыруларны берьюлы башкарып, бөтенесен «тәгәрмәчтә» килеш җибәреп, эфирга чыгара алсаң – драйв әзер!

> *Юк, «каналның йөзе» дип исәпләмим үземне, ә менә «эш аты» дисәләр – килешәм.*

Драйв та, баш авыртуы да ул. Үзебез белән булган бер хәлне сөйлим әле. Күмәк җитезлек белән генә ерып чыктык без аны. Мәскәү татарлары өчен бик дәрәҗәле концертны төшерергә киттек. Ләкин җомга кич юлдагы «бөке»ләр турында нишләп уйлап бетермәгәнбездер? Ун чакрым араны 4 сәгать (!) уздык. Билгеле инде, соңга калдык. Сәхнәдәге күренешләрне генә телекамерага эләктердек, тамашачыларны һәм залдагы кунакларны төшерә алмадык. Нәрсә эшләргә? Күрсәтми генә сөйләп булмый бит инде. Бу бит телевидение! Залдан чыгып килүчеләргә үтенеч белән мөрәҗәгать иттек: «Таралышмый торыгыз, кабат үз урыннарыгызга кереп утырыгыз. Кул чабыгыз, елмаегыз!» – дибез. Кереп утырдылар. Күмәкләп җырладык та, кул да чаптык, рәхәтләнеп көлдек тә... Импровизацияле флеш-моб килеп чыкты ул. Ә тапшыру тулы итеп эфирда күрсәтелде!.. Телевидениедәге уңыш, минемчә, үз һөнәреңә тугрылыкны саклап кала белү. Экранда «балкып чыгу» ул әле син башкалардан аерылып торасың дигән сүз түгел. Зур җитәкчеләр, атаклы кешеләр, танылган шәхесләр белән аралашу да сиңа даһилык өстәми. Аек фикерле булып калырга кирәк. Уңышның сере очракка да бәйле була ала, әлбәттә. Ләкин үзебезнең чынбарлыкны без үзебез үк корабыз бит. Кылган гамәлләребездә, кешеләргә мөнәсәбәтебездә, туплаган тәҗрибәбездә чагыла ул. Мин характерга ышанам! Башкала күз яшьләренә ышанмый диюләре хак икән. Ә менә тырышларга, тәвәккәлләргә, белемлеләргә ышана.

Владимир Путинга – Татарстан йөрәге

Коллегаларым еш кына: «Илкүләм матбугат конференцияләрендә кем сиңа булыша, кем беренче рәтләргә утырта, нинди сорауны бирергә кирәген кем

әйтә?» – дип сорыйлар. Беркем булышмый, беркем әйтми! Мине танылткан сорауга килсәк, Республикадан беренче тапкыр РФ Президентының матбугат конференциясенә барган идем (ә бу төрле илләрдән һәм төбәкләрдән килгән йөзләгән журналист, иртәдән үк башланган ыгы-зыгы, этеш-төртеш...) Нишләргә? Зур йөрәк ясалган табличкамны югары күтәрдем. Владимир Владимировичка федерализм турындагы соравымны әнә шулай ирештердем. Кайбер сәясәтчеләрнең төбәкләрне эреләндерү кирәклеге турында сүз алып барган заман иде бу. Берничә көн үткәч кенә төбәкләр өчен никадәр мөһим сорау биргәнемне аңладым. Россия төбәкләренең матбугат чаралары, ТНВга, миңа, Татарстанга нигезләнеп, әлеге сорауга кабат әйләнеп кайттылар. Президент ул чакта бөтен халык катнашында үткәрелгән референдумнан башка бернинди эреләндерү турында сүз булуы мөмкин түгел дип җавап биргән иде.

Телевидениенең яңалыклар программасында эшләр өчен утта янмас, суда батмас холыклы булу кирәк.

Мәскәү–Казан–Кырым

Узган ел безнең өчен күпмедер дәрәҗәдә борылыш елы булды. «Татарстан–Яңа гасыр» филиалының Мәскәүдәге эшчәнлеге киңәйде, моңарчы булган медиабазасы структурасында «Татмедиа» Республика Агентлыгы Вәкиллеге барлыкка килде. Кырымның информацион палитрасын яктырту да безгә тапшырылды. Анда бит бик күп татарлар яши, һәм бер ел инде «ТНВ–Планета» трансляциялнә! Хәзер ай саен ярымутрауга очабыз.

15 ел эшләү дәверендә Мәскәүдә беренче тапкыр ТНВның үз студия зонасы оештырылды. Республикабыз җитәкчеләре беренче кунакларыбыз булды. Татарстан туграсы элементы бизәкләрен студия дизайнында файдалану аларга аеруча ошады. Республикабызда милли телевидениене кайгырту сизелеп тора – эш процессында туган сораулар игътибарсыз калганы юк.

Яңа студиядә барлыгы җиде кеше без: оператор, монтажер, инглиз, татар теле буенча редакторлар... Тату гаилә кебек без: бер йодрык булып эшлибез, юбилеебызга матур уй-планнар белән киләбез. Башкаланың татар автономиясе тормышын яктырту белән беррәттән, без халыкара массакүләм мәгълүмат чаралары белән дә тыгыз элемтәләр урнаштырырга җыенабыз. Татарстан һәрчак күз уңында, билгеле төбәк бит. Колачлы проектларыбыз шактый. Көнләшүчеләр дә, уңышларыбызга икеләнеп караучылар да бар, алар белән бераз бәхәсләшеп тә алдык. Журналист халкы болай да бераз шикләнүчән бит. Ә чит илләрдәге дусларыбыз Россия төбәкләренең активлыгына, нишләптер, ышанып бетми – чит илләр эшләре министры Сергей Лавров федераль һәм халыкара матбугат вәкилләрен кабул иткәндә сизелде бу. Без аларны Татарстанга чакырдык, «Иннополис»ны, яңарган Казанны, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы белән таныштырырга телибез. Үз күзләре, үз объективлары белән күрсеннәр – һәм дөньяга танытсыннар!

КАДРГА КЕРМӘГӘННӘН...



Кайда, кайчан туган? – Чаллы шәһәрендә 28 майда, Чик сакчылары көнендә туган!

Белеме – Казан университетында – журналист, МГИМОда халыкара юрист белгечлеге алган.

Гаилә хәле – кияүдә. «Күп еллар сөеп һәм сөелеп яшим!» – ди.

Уңышлары – Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре, Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы, күпсанлы фестиваль, конкурслар лауреаты.

Яраткан китабы – Джон Голсуорсиның «Сага о Форсайтах» әсәрен, рәхәтләнеп, кайта-кайта укый.

Яраткан фильмы – совет комедияләрен балачактан ук үлеп ярата, аеруча «Здравствуйте, я ваша тетя!»ны (Александр Калягин «түткәй» ролендә искиткеч дип саный).

Яраткан телеканалы – Мәскәүнең «Москва-24» информацион каналы (аны «Россия 24» кабатлый). «Бик креатив һәм яшь канал. Җай чыккан саен карап барырга тырышам, үзебез өчен дә файдалы әйберләр эзлим».

Хоббие – зәркән бизәнү әйберләре дизайны белән шөгыльләнә. «Башта яңа бизәнү әйберен хыялымда күз алдыма китерәм дә, зәркәнче белән бергәләп ясап бетерәбез, аннары инде дус кызларыма бүләк итәм. Мода атналыкларына йөрергә ятам. Россия дизайнерлары белән рәхәтләнеп аралашам. Яңа трендларны өйрәнәм. Гардероб яңарту минем өчен шатлык һәм илһам чыганагы».

ТВдагы кумиры – кумирлары юк, профессиядә чиксез хөрмәт иткән кешеләре бар: «Беренчесе, әлбәттә, әнием – радио һәм телевидение журналисты Роза Газалиева!» Дмитрий Киселевның «кадрда» эшләве ошый.

Шигаре – «Гайрәтле яугир яхшы күңелле була» дигән япон мәкале. «Миңа калса, агрессия, тәкәбберлек, башкаларны санга сукмау көчсез кешеләргә хас. Ул үзенә игътибарны шулай җәлеп итмәкче. Безнең коллегалар арасында да очрый андый «йолдыз чире».

Ял итү рәвеше – көн саен уртача 1–1,5 километр йөзә, пилатес белән шөгыльләнә, кардиотренажерларны үз итә. «Мин йөри торган клуб бассейнында – диңгез суы. Шулай итеп, рәхәт белән файдалы бергә – һәм миндә алар гел янәшә!»

ҖӘМГЫЯТЬ



Татарстан районнарыннан килгән ветераннар Казан Кремлендә Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов кулыннан медальләр алдылар. «Сез — бүгенге чор геройлары, республика һәм ил үсеше өчен зур өлеш кертүчеләр, намус, батырлык, патриотлык үрнәкләре», — дип, алар белән горурлануын әйтте Рөстәм Миңнеханов.

ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов Әнкарада Төркия—Татарстан эшлекле форумында катнашты, Төркия Республикасының вазыйфаи шәхесләре белән очрашты. Төркия җитәкчелеге Татарстан белән мөнәсәбәтләрнең Төркия өчен бик әһәмиятле икәнен белдерде. Рөстәм Миңнеханов ике арадагы мөнәсәбәтләрдә сәламәтлек саклау, урта һәм кече бизнес өлкәләрендә хезмәттәшлекнең алгы планда булуын әйтте. Форум кысаларында Әнкараның иң зур тамаша залында Татарстан сәнгать осталарының «Җырлы-биюле Татарстан» концерт программасы күрсәтелде.



Татарстан радиосының шеф редакторы, атказанган мәдәният хезмәткәре Рәзин Нуруллинның Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләүче Бөтенроссия «Татар гаиләсе» фонды белән берлектә уздыра торган «Пар канатлар» тапшыруының быелгы бәйрәме дә Г. Камал театрында узды. Бөек Җиңү елында узган бу очрашуның сәхнә түрендә сугыш авырлыкларын кичкән парлар булды. Кичәнең төп сюрпризы — Муса Җәлилнең моңа кадәр мәгълүм булмаган шигырьләрен яңгырату булгандыр. «Татар гаиләсе» фонды җитәкчесе Миләүшә Гайфуллина ветераннарны фонд исеменнән бүләкләде. «Сөембикә» журналы исә үз бүләген — чиккән парлы мендәрләрне — талантлы биш кыз әнисе Зөлфия Ганиуллинага тапшырды. Бәйрәм турында тулырак мәгълүмат һәм фоторепортажны сайтыбыздан карап була.

КОТЛЫЙБЫЗ



Канаданың (Монреаль) Джон Аббот көллиятендә укучы студент кыз Камилә Хәмәдиярова һәм Актаныш талантлы балалар гуманитар гимназия-интернатында белем алучы Айдар Шәйхин татар теле һәм әдәбияты буенча III Халыкара олимпиадасында Гран-прига лаек булды. Бәйгедә Россиянең 22 субъектыннан һәм 10 чит илдән 500 дән артык мәктәп укучылары катнашты. Җиңүчеләргә бүләкне Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов үзе тапшырды.

МӘДӘНИЯТ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узган Туган тел көненә багышланган тантаналы чарада быелгы Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде. Шагыйрә Клара Булатовага, рәссам Ирина Колмогорцевага һәм «Алтын Урда» спектаклен иҗат иткән Татар дәүләт опера һәм балет академия театры иҗат төркеменә әлеге олы бүләкне ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов зурлап тапшырды.



Казан музейларында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына багышланган күргәзмәләр ачылды. «Казан» милли мәдәният үзәгендәге «Бөек Җиңү аурасы» дип аталган тарихи-документаль күргәзмәдә хәрби бүләкләр һәм билетлар, Кызыл Армия кенәгәләре, фронт хатлары, ипи карточкалары, һәлак булу хәбәрләре һәм башка тарихи әйберләр урын алган. «Казан Кремле» музей-тыюлыгына исә Фәрит Гобәевнең «Бөек Җиңүнең 70 йөзе» дигән күргәзмәсе ачылды. 70 ветеран портретын эшләү өчен автор Татарстанның 45 районын йөреп чыккан. Күргәзмәне ачу көненә ветераннар үзләре дә музейга килгәннәр иде. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Ак-кара фотолар. Гади генә нәрсә түгел бу... Фронттан гаиләләргә килгән фотолар шундый булган», – дип портретларның үзенчәлеген искәртте.





ЙОЛДЫЗ СҮНГӘН, НУРЫ ЮЛДА ӘЛЕ



Асия ЮНЫСОВА

ЕГЕРМЕ ӨЧ КЫЗГА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ДИГӘН ИСЕМ БИРЕЛГӘН. ШУЛАРНЫҢ ИКЕСЕ – МӘГУБӘ СЫРТЛАНОВА БЕЛӘН ОЛЬГА (ЛӘЙЛӘ) САНФИРОВА ТАТАР КЫЗЛАРЫ.

1941 елның октябрендә Энгельс шәһәрендә 46 нчы хатын-кызлар авиация полкы оештырыла. Мәшһүр очучы, Советлар Союзы Герое Марина Раскова (фотода: уңнан беренче) ул полкка очучы кызларны үзе туплый. Немецлар «Төн пәриләре» дип йөрткән куркусыз кызлар, төннәрен дошман позицияләрен утка тотып, Бөек Җиңүгә биниһая зур өлеш керткәннәр. Өч ел эчендә егерме өч меңнән артык сугышчан очыш ясалган, дошман өстенә өч миллион килограмм бомба ташланган.


егендар очучы Марина Раскова канаты астына җыелган «Төн пәриләре» – уртача 17–22 яшьләрдәге 115 очучы кыз – беренче сугышчан очышларын 1942 елның 12 июнендә башлап, 1945 елның 5 маенда Берлин күгендә тәгәлләлиләр. Бу полк Кавказны, Кырымны, Белоруссияне, Польшаны азат итүдә катнаша. Төп вазыйфалары дошман өстенә бомба ыргыту саналган очучы кызлар зәмһәрир суыкларда йөзәр килограммлы бомбаларны очкыч канатына элгәндә кул итләрен салкын тимер йолкып калуга да, күселәр йөгерешкән землянкаларда яшәүгә дә түзәләр, сызлаган сөяк-санакларын җылыта алмый да тилмерәләр. Госпитальдән качып кайтып та, очкычларына чит кеше ярдәме белән менеп утырып та төнге күккә омтылалар. Чөнки Кырым ярында камалган совет солдатлары, тилмереп, азык-төлек, хәрби кирәк-ярак көтә.

Казанда эшләнгән У-2 (ПО-2) очкычларында, фанерага перкаль тукыма катырылып кына ясалган, ни пулеметы, ни ябык кабинасы, ни рациясе булмаган нәни очкычларда 1080 төн дәвамында хәрби батырлыклар кылган кызларны данлап, әле 1943 елның 9 октябрендә үк, Мәскәүдә 224 орудиедән егермешәр залп белән салют бирелә. Полкның гвардия байрагына Кызыл Байрак һәм Суворов орденнары беркетелә.

«Төн пәриләре» арасында татар кызлары да, казакъ, удмурт кызлары да булган. Без Мәгубә Сыртланова исемен ишетеп үстек. Соңрак Ольга Санфирова хакында белдек. Лена Салихова исеме менә яңгырарга өлгерми кала. Бәхетсезлек. Бомбалар ташлап кайтып килүче очкычлар берсе өстенә икенчесе кунаклау сәбәпле, ике экипаж – өч кыз берьюлы – аэродромда бит! – һәлак була. Фәкать казакъ кызы Хиваз Доспанова гына исән кала.

Кызларның батырлыгы легендар Мәгубә Сыртланованың аудиоязмаларында, Шәһрезадә әкиятләре сыман, төне-төнгә теркәлеп калган. Шулар һәм 46 нчы гвардия Тамань полкы эзләреннән йөреп тупланган материаллар нигезендә язучы Шамил Рәкыйпов «Кызлар-йолдызлар» дигән роман язып калдырды. Заманында Мәгубә Сыртланова турында матбугатта язмалар еш күренә торган иде. Ә менә Марина Раскованың беренче бойрыгын үтәү йөзеннән, дулкын чәчләрен кисеп ташлап, очучылар сафына баскан чамасыз гүзәл, кипаристай зифа буй-сынлы, кара күзле, карлыгач кашлы Ләйлә Санфирова исеме сирәгрәк телгә алынды. Аның нindирәк кыз булуын укучы күз алдына китерә алсын өчен китаптан бер өзек укып үтик. Өч йөз кырык дүртенче төн турындагы хикәят ул.

«Иртәгә 1 Май. Ә безнең күңелләрдә бүген үк бәйрәм. Полк командиры һәммәбезне тәбрик итте һәм гвардияче значокларын тапшыру өчен дивизиядән киләселәрен әйтте.

Штабтан сафларга тезелеп кайтырга түземлегебез җитмәде. Йөгереп кайтып кердек тә чемоданнарыбызга



■ Мәгубә Сыртланова. Эскадрилья парторгы, гвардия өлкән лейтенанты. 1912 елның 16 июлендә Бәләбәй шәһәрендә туган. Татар кызы. Тбилиси хәрби комиссариаты тарафыннан сугышның беренче көннәрендә үк хәрби хезмәткә чакырылган. 780 төнге очыш ясаган. Советлар Союзы Герое. Ленин ордены, ике Сугышчан Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, Алтын йолдыз медале белән бүләкләнгән. 1971 елны Казанда вафат булды. Казанда, Бәләбәйдә аның исемендәге урамнар бар.

ташландык. Аннан парад киемнәре чыкты, үтүкләр чыжылдады, бөтен бүлмә эче вакса, хушбуй исе белән тулды. Кызлар тыз-быз йөгерешә, мутраклары, бармакларын пешерә-пешерә, көзге алдында чәч көдрәли, каш каралта, ирен кызарта. Сабырраклары гимнастеркасына ак яка тегә, төймә тага. Көндезге уникеләрдә хәзерлек тәмамланды. Кызлар берсеннән-берсе чибәр. Күзләр – тәрәзәдә.

Ә бомбалар ташлау... Аныcы һәр төнне үтәлә торган күнегелгән, әмма чамасыз хәтәр эш!

– Киләләр! Киләләр! – дип хәбәр итте адъютант кыз. Күп тә үтмәде, өсләрен юл тузаны сарган ике җиңел машина полк штабы урнашкан йорт каршына килеп туктады. Без, алдан ук әйтеп куелганча, колхоз бакчасына кереп, алмагачлар ышыгында сафларга тезелдек.

Озак көттермәделәр. Башта штабтан бәләкәй өстәл чыкты, аннары башлыклар.

– Дивизия командиры генерал Попов килгән! – диде Женя Руднева.

– Кемгә генерал, кемгә Дмитрий Дмитриевич! – дип, усал Себрова, киная белдереп, Ләйләгә таба карап куйды.

Вәт бит ә!.. Ни генә белми диген син бу Себровaны! Тик вак-төяк белән кызыксыныр чакмыни хәзер?!

Генерал Попов кыска, әмма тирән мәгънәле речь сөйләде. Тавышы тагын үзенең! Тыңлап кына торырлык.

Ләйләгә күз төшереп алам. Кызыбыз генералга караган да тәмам онытылган. Тукта, теге чакта, полкка гвардия исеме бирелү турында Указ укылганда да,



Ольга Санфирова. Эскадрилья командиры, гвардия капитаны. 1917 елның 2 маенда Самарада туган. 630 төнге очыш ясаган. Татар кызы. Ленин ордены, Александр Невский, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары һәм Советлар Союзы Героеның Алтын йолдыз медале (һәлак булганнан соң) белән бүләкләнгән. 1944 елның 13 декабрендә һәлак булган. Гроднода күмелгән. Гроднода һәм Самарада аның исемендәге урамнар бар. Самарада аңа һәйкәл дә куелган.



бу исәр кыз генералга нәкъ шулай карап торган иде бит! Димәк, Себрова хаклы булып чыга?

Шул арада генерал сафлар буенча китте һәм значокларны тапшыра башлады. Берәм-берәм кызларның кулларын кысты: «Тәбрик итәм!» – диде. Ә Ләйлә янына җиткәч... Күзләребез шар булды. Ләйләгә генерал бөтенләй икенче итеп, сөеп карады. Һәм кызыбызның күкрәгенә значок белән бергә Кызыл Байрак орденын да тагып куйды. Ләйләнең югалып калуын күрсәгез иде! Башка вакытта чәчрәп-яшьнәп торган кеше «Советлар Союзына хезмәт итәм!» – дип чак-чак әйтә алды.

Караңгы күктә прожекторлар яктысында аның һәр хәрәкәте әллә кайдан күренеп тора.

Бүләкләр тапшырылып беткәч, икенче эскадрилья кызлары генерал белән бергә рәсемгә төшәргә теләүләрен белдерделәр. Риза булмас, әдәпле генә баш тартыр дип уйлаган идек. Әмма Ләйләбез кашларын сикерткәләп үтенгәч, генералыбыз эреп китмәсенме! Бер минут эчендә генерал тирәсенә тезелеп тә өлгердек.

– Күрдеңме? – диде Себрова тулай торакка кайткач. – Чибәр якташың фотога төшкәндә генералның сул ягында – йөрәк ягында иде шул!

Ләйлә белән сөйләшергә телем бик кымырҗый иде, ләкин җае чыкмады: мине һава разведкасына җибәрделәр. Аннан кайтуга Түбән Бакандагы дошман гаскәрләрен бомбага тотарга очтык.

Ләйлә машинасы өченче булып күтәрелде. Бишенчедә Женя белән мин. Сөйләшә-сөйләшә барабыз. Женя, гадәтенчә, йолдызлар турында гәп куерта. Миңа Үгезбозау йолдызлыгындагы Марс белән Сатурн планеталарын күрсәтә. Мин шул ук йолдызлыктагы иң якты йолдызның исемен сорыйм. Женя бераз дәшми тора. Мөгаен, белмидер. Белмиме соң! Ул – безнең җырларда җырлана торган Зөһрә йолдыз, ягъни Чулпан, ә астрономнар телендә Венера үзе икән ләбаса!

Мин Женядан шуны да белдем: кайбер йолдызлар Кояшка караганда ифрат зур, алар бик-бик еракта булганга безгә бөтенләй күренми икән, кайберләре исә сүнәләр, ләкин үзләре сүнгәч тә, нурлары әле байтак вакыт җиргә таба килә икән.

Мин гаҗәпләнәм: йолдыз үзе сүнгән, юкка чыккан, ә якты нуры килә. Әкәмәт түгелмени бу?! Җирдә моңа тиңләшерлек нәрсә бар?

Фәлсәфәгә бирелерлек вакыт калмый. Алдан очкан самолетлар цельгә керәләр. Күк йөзен прожектор кайчылары телә. Снарядлар шартлап, берьюлы дистәләгән утлы чалма кабына.

Иртәгә 1 Май икәнлеген истә тотып һәм бәйрәм алдыннан күпләп кузгаласыбызны чамалап, гитлерчылар безне ныклап әзерләнеп көткәннәр икән. Күктә тәмам гарасат купты. Беренче ике самолет мотор сүндереп, искәрмәстән килгәнлектән, бомбаларын уңышлы ташлап, уттан ансат ычкынды. Ләйлә мәхшәрнең уртасына эләкте. Барлык прожекторлар аны кармаладылар, барлык пушкалар аңа төбәп ата башладылар. Ләйлә бөтен осталыгын җигеп, цельгә үтәргә тырыша. Самолет янында снарядлар ярылудан барлыкка килгән утлы боҗра кысылганнан-кысыла бара. Тагын аз гына, аз гына түз, Ләйлә! Без якынайгач, сиңа төбәлгән ут яңгыры кими төшәр. Түз... Ләкин фашист ләгыйнь дә тиз кыймылдый шул.

Ләйлә очкычына ут капты. Шуннан ул бомбаларын ташлап, кайтырга борылды. Моторы тартса, канаттагы ялкынны җилләтеп, сүндерергә уйлый иде булса кирәк.

Инде ут давылы безне төреп алды.

– Санфирова яна-яна төшә, – диде миңа штурманым Руднева.

Артыннан утлы койрык сузылып барган чыра кебек җиңел самолетның офыкка кереп югалуын күреп калдым.

Беттеләр!

Бәлки әле... Юк шул, бу тирәләр казылып-актарылып беткән. Исән-сау калулары икеле. Җиргә төшеп утырсаң да, дошман тырнагына эләгәсең...

Бу төнне без дүрт очыш ясадык. Дәшми-тынмый очтык та очтык. Фашистларның алгы сызыкка баручы техникасын сафтан чыгардык. Ләкин күңел барыбер күтәрелмәде. Йөрәк сулкылдый-сулкылдый тибә һәм берөзлексез «Ләйлә... Ләйлә» дип кабатлый иде». Мәгубә апа тасвирлаган манзара күз алдына килә. Иреннәр таныш җырдагы сүзләрне кабатлый: «Исән калды микән, дөрләп янды микән Алтын йолдыз таккан таң кызы...» Моңа кадәр бераз ясалмарак тоелган җыр сүзләре кинәт үзәкне өздереп ала, бүтән – фаҗигале мәгънә ала: «Исән калды микән...»

Җиңел канатларына 300 килограммга кадәр бомбалар аскан фанер очкычлар кара төндә шыпырт кына килә дә йокылы-уяулы фашист позицияләренә, йә, паровоз мичennән чәчрәгән утлы «бөҗәкләргә» ориентирланып, корал төяп көнчыгышка – Сталинградка ашыккан эшелоннар өстенә бомбаларын ташлап китә. Китә... Әйе, тиз генә китә алса... Бомбалардан арынгач та бит әле «кукурузник»ның тизлеге 130 километрдан артмый. Беренче бомбадан «уянган» прожекторлар көлтәсе сукырайта башлагач, зениткалар хәрәкәткә килгәч, ике кешелек экипаж утлы пәрәвез тоткынында кала. Менә шул чагында сынала инде очучының осталыгы. Кайда дөрләп яна башлаган канатларны җил ташкыны белән сүндерергә тырыша-тырыша, кайда өстеңә турылап килгән «мессер»лардан кадала-кадала җиргә төшкән сыман качып, кайда зениткалар утыннан диңгезгә ышыкланып, үз «алан»нарына кайтып мәтәлгәндә бәләкәй очкычның ямар-төзәтер җире калмаган була. Алай да, ничек кирәк шулай ямыйлар да, тагын төнге күккә томырылалар. Болытлы, дөм-кара, ягъни әйбәт төннәрдә дүртәр-алтышар очыш ясала. Чын-чыннан җенле кызлар! Дуся Носальгә соңгы талпыныш өчен нинди җеннәре көч бирде икән? «Аэродром өстеннән бер шәүлә үтте. Ул, адашкан каз кебек әйләнеп, бер түбәнәя, бер күтәрелә. Төшәргә һич кыюлыгы җитми. Күрәсең, самолет бәлагә тарыган... Очкычларыбызны аэродром читенә алып куйдык. Самолет тагын ике әйләнеш ясагач, аэродромның тәмам чистарып калуын чамалап булса кирәк, сигнал утларын санга сукмый-нитми, газны да әллә ни киметми генә төшә башлады. Менә көпчәкләр җиргә тиеп, самолет бер сикереш ясады, икенчене... һәм ягулыгы бетте, ахры, моторы тынды. Җан-фәрманга очкычка таба йөгердек. Пилот кабинасында җан әсәре сизелми. Дуся... Ул эндәшми. Прибор тактасына ябыштырылган фоторәсемгә башын салган да тынып калган». Шамил Рәкыйпов китабындагы документаль язмадан өзек бу.

Менә икенче бер очракның каһарманы – Мәгубә Сыртланова үзе. «Курстан тайпылганбыз. Керосин җитәрме-юкмы? Аста – диңгез. Үч иткәндәй, җил көчәеп, болытларны тарата башлады. Әллә нишләп йокыга оета. «Марта, фашист килә! – дигән сүзләр айнытып җибәрде. Көмеш сыман ай яктысында куксел болытлар өстеннән, канатларын кыса төшеп, корбанына ташланган карчыгадай, «мессер» безгә якынлаша иде. «Беттек!» дип уйлап, йөрәгем чәнчеп куйды. Биеклек мең сигез йөз метр, болытларга чумып өлгерә алмыйбыз. Иләк ясый хәзер бу бездән! Штурманым дәшми.

Безнең белән дуэльгә күтәрелгән «мессер»ның моторы 1550 ат егәрлекле, ул сәгатенә 644 километр тизлек белән оча ала!

Ул арада фашист якын ук килеп җиткән иде инде. Бетүебез шушы икән! Мин фашист очучысының йөзен хәзер ап-ачык күрәм. Нык куркудан елан авызына чыелдап барып кергән куяндай, туп-туры үлемгә якынлашам. Немец очучысы, ансат кына кулына килеп кергән табышы белән ләззәтләнергә теләп булса кирәк, тизлеген киметте, фонарьны (пыяла каплавыч) ачты. Әнә ул, авызын ерып, сул кулының ике бармагын безгә күрсәтә. Янәсе, ике тапкыр атсынмы? Бу оятсыз, масаюлы карашны күрмәс өчен ни генә эшләмәс идем мин хәзер!!! Чиксез каударланып, сул педальгә бастым, идарә тоткасын уң бортка... Шулчак артымда гына нидер өч кат дөпелдәде. Әллә тылсым бармы дөньяда?! Фашист кабинасында сыгылып төште, идарәсез калган «мессер» түбәнгә таба юнәлде... Мин очкычыбызны тигезләдем. Җиргә кайтып төшкәч, беренче эш итеп, штурманым Аронованың пистолетын үптем. Аннан көзгедән карадым – бер тотам чәчем агарган иде».

Теге вакытны дөрләп янып офыкта югалган төн кызлары исән кала. Сафтан чыккан мотор белән дошман территориясенә төшеп тә исән калалар бит, әй! Икесе ике якка аерылган Ләйлә белән Руфина берничә көннән снаряд чокырында кочаклашалар. Һәр тарафта фашистлар. Күренмәс өчен тирән елга суын ерып атлыйлар. Мең газап белән алгы сызыкка якынлашалар. Үрмәлиләр, шуышалар... Алар бәхетенә күктә һава сугышы кыза. Ыгы-зыгыдан файдаланып, кызлар үзебезнең солдатларга барып бәрелгәнче йөгерәләр дә йөгерәләр. Анда да беренче сүзләре: «Кулларыңны күтәр. Атам!» Әй көлә инде кызылармеец егет: «Атмыйсыз. Сез бит безнең кызлар. Аннары көпшәсенә балчык тулган пистолет атмый ул».

Шулай да куш йөрәкле батыр кызлар бала гына бит әле. Күсе-тычканнан куркалар, чәчәк яраталар, сөяләр,

сөеләләр. Хыялланалар. Һәрберсе Бөек Җиңү таңына кадәр яшәячәгенә ышана. Һәм... һәр төнне диярлек үлемгә каршы оча. Гомерләрен һәр төнне кыл өстенә кую – алар өчен гадәти хәл. Тәвәккәллек – батырлыкның үзе инде ул, дип уйлый белделәр микән алар? Кешенең асылы иң җаваплы мизгелләрдә сынала. Теләсә кайсы төндә, йолдыз кебек янып һәлак булырга әзер кызлар үлемсезлек турында түгел, бәлки, тиздән киләчәк Җиңү таңы, тиздән кавышачак сөйгән ярлары, тиздән киеләчәк туй күлмәкләре турында хыялланалар. Тик Ләйлә Санфирова өчен дә, һәлак булган тагын утыз ике кыз өчен дә Рейхстаг диварына Мәгубә Сыртлановага тамга салырга туры килә.

Өлкән кеше өчен игътибардан һәм җылы сүздән дә кадерлерәк тагын нәрсә бар?!

Кырым бөркете – данлы очучы Әхмәтхан Солтанны гашыйк итә алган Идел кызына туй шатлыгын тату насыйп булмый. Үзе кебек меңләгән кызлар чын бәхеттә яшәсен өчен чибәрләрнең-чибәре салкын гүр куенына кереп ята.

Төнге очыштан кайтып, табын янына утырасы кызлар – Ольга Санфирова белән Руфина Гашева, Носельск тимер юл станциясен өченче тапкыр бомбага тотып кайтып килгәндә зениткалар утына эләгәләр. «Ләйлә! Күрәсеңме, янабыз! Ләйлә дәшми. Ничек тә булса фронт сызыгын чыгасы иде бит! Инде ялкын фюзеляжны ялмый. «Руфа, сикер! – дип миңа команда бирә Ләйлә. «Ә син?» Кайнар һава дулкыны кагып җибәргәндә Ләйләнең дә төпсез бушлыкка атлавын күреп, түбәнгә очтым». Руфина Гашева сөйләгәннәрдән бу.

Руфина бәхетлерәк булып чыга. Ул танкларга каршы куелган миналар өстенә килеп төшә. Ләйлә пехота өчен куелган миналарга эләгеп, ике мәртәбә шартлый.

Польша җирендә һәлак булган Ләйләне Гродного алып кайтып җирлиләр. Табутта яткан гүзәл очучы кыз белән хушлашыр өчен биш сәгать дәвамында халык агыла. Аның кабере янәшәсендә ике кипарис үсеп утыра. Белоруссия өчен ятрак бу агачларны Әхмәтхан Солтан утырткандыр дип уйлыйлар. Чөнки очучы егетнең күктәге пароле дә кипарис була бит.

«Мәхәббәтем минем,
Ерак йолдыз кебек,
Үзем сүнгәч тә әле
Сүнмәс – нур чәчәр».

Ләйлә язган шигырь түгел микән бу? Кайбер ерак йолдызларның нуры җиргә килеп җиткәндә, йолдызлар чыннан да үзләре сүнгән була икән бит. Полкташлары да, сөйгән егете Әхмәтхан да бик озак оныта алмыйлар йолдыз-Ләйләне. Казанда да бер урамга аның исеме бирелергә тиештер.

ВЕТЕРАННАР — КАДЕР-ХӨРМӘТТӘ



Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира ЗАРИПОВА

Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә без янә сугыш ветераннарына чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Кызганыч, аларның сафы сирәгәя бара. Соңгы айларда гына да 2 мең 702 ветеран бакыйлыкка күчте. Бүген Татарстанда 76 мең 839 Бөек Ватан сугышы ветераны яши. Шуларның 1148 е – сугыш инвалиды, 140 ы – концлагерь тоткыны, Ленинград блокадасы кичергән 222 кеше бар. Аларның мәнфәгатенә игътибарны икеләтә арттырдык, тормыш шартларын, мохтаҗлыклары нидә икәнен тагын бер барлап алдык. Тыл хезмәтчәннәрен, сугышта катнашучыларның тол хатыннарын да онытмыйбыз. Өлкәннәр өчен чаралар бер-бер артлы узып тора. Мартта ветераннар арасында «Балкыш» үзешчән сәнгать фестивале гөрләп узды...

Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов 25 мартта узган «Ел хәйриячесе» тантанасында Бөек Җиңү уңаеннан сугыш ветераннарына юбилей медальләре тапшырды. Бүген бердәнбер исән Советлар Союзы Герое Борис Кириллович Кузнецов хатыны белән бергә Мәскәүдә – Җиңү бәйрәмендә катнашты. 7 май көнне Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында сугыш ветераннары өчен тантана уздырылды. Җиңү паркындагы Мәңгелек ут янына, Арча зиратындагы сугышта катнашкан монументына, Советлар Союзы Геройлары – Михаил Девятаев белән Гани Сафиуллин каберләренә чәчәкләр куелды.

18–29 май көннәрендә исә ветераннар өчен Идел елгасы буйлап Мәскәүгә круиз оештырылачак. Хөкүмәтебез ветераннарга матди ярдәм (азык-төлек җыелмасы) күрсәтү турында да онытмады. Татарстанның муниципаль җирлекләрендә яшәүче 90 яше, 100 яше тулган ветераннарга РФ Президенты Владимир Путин исеменнән котлау открыткалары җибәрү дәвам итә.

Шунысын да әйтик: республикада ветераннарның социаль һәм икътисадый иминлеген булдыру өчен зур эшләр башкарыла. Безнең министрлык аларның социаль паспортында язылган чараларның үтәлешен тикшереп тора. Ветераннар өчен хастаханәләрдә махсус палаталар эшли. Ветераннарны торак белән тәэмин итү дәвам итә. 18743 кеше торак алу исәбенә куелган. Шуларның 18410 сы субсидияләр алды инде. Торак шартларын яхшыртуга, ремонтлауга мохтаҗларга да ярдәм күрсәтелә. 628 ветеран яшәүче йортларда капиталь ремонт ясалды. Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов юбилей чараларын лаеклы уздыру белән беррәттән, ветераннарга кадер-хөрмәт күрсәтүне киләчәктә дә дәвам итү кирәклеген һәрдаим искәртеп тора.









Диңгез пехотасында бердәнбер взвод командиры Евдокия Николаевна Завалий. Взвод командиры сыйфатында ул бик күп шәһәрләрне азат итүдә катнаша. Будапешт шәһәрен азат иткәндә Е. Завалий, противогаз киеп, шул рәвешле канализация юлларыннан үтеп кереп, немец командованиесе бункерын кулга төшергән.


ХАТЫН-КЫЗ ҺӘМ ҖИҢҮ

1941–1945 елларда армиядә хатын-кызларның саны

	СССР	АКШ	Бөекбритания
Шәфкать туташлары һәм санитаркалар	1 000 000	550 000	200 000
Пехота гаскәрләрендә	48 000	1 000	1 500
Элемтәдә	45 500	19 000	1 200
Артиллериядә	6 080	–	–
Очучылар	3 500	130	–
Снайперлар	2 580	560	300
Разведчиклар	2 350	1 650	980









СССР **АКШ** **Бөекбритания**



Сугышлар тарихында иң шәп снайпер хатын-кыз Людмила Павличенко. Ул Молдавиядәге сугышларда, Одесса һәм Севастополь оборонасында катнашкан. 1942 елның июленә анық хисабында 309 корбан исәпләнә. Шуларның 36 сы – үзләре дә снайперлар.

90 хатын-кыз Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм Советлар Союзы Героеның Алтын йолдыз медале белән бүләкләнгән (49 ы һәлак булганнан соң).

Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында хатын-кызлардан тупланган иң зур хәрби берләшмә 1942–1943 елларда СССРда оештырыла. Бу артиллерия, миномет, танк, сапер һәм башка хәрби бүлекләрдән торган меңләгән хатын-кызны туплаган корпус була. Берничә ай дәвамында аларны тәҗрибәле фронтовиклар хәрби эшкә өйрәтә. Яугирләр фронт өчен әзерләнә. Тик, нигәдер, корпус тиз арада таркатыла. Аның сугышчылары берәм-берәм дә, төркемләп тә төрле гаскәрләргә таратыла.



Бердәнбер хатын-кыз танк батальоны командиры Александра Григорьевна Самусенко. 1941 елның октябреннән Брянск, Көнбатыш һәм Воронеж фронтларында сугыша. Өч тапкыр яраланган, бер тапкырында авыр яралана. Хәлиткеч Курск танк сугышында катнаша. Кылган батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.



Дөньяда бердәнбер хатын-кызлар авиация полкы – «Төн пәриләре» дигән дан алган 46 нчы төнге бомбардировщиклар авиация полкы сугыш вакытында 23, 5 мең очыш ясап, дошман өстенә 3 миллион килограммнан күбрәк бомба ташлаган.



Инфографика: asafin

icc



Фото: Газинур Хафизов

ҖЫЛЫ БОЛЫТ КОЧАГЫНДА



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Шәл, чәчәк аткан гөл кебек, сезнең иңнәрдә, сезнең җылыдан гына мамыкланырга тиеш...

«Оренбург шәлчеләре» предприятиесе директоры Альбина Фаил кызы ӘБСӘЛӘМОВА үзенең иң беренче шәлен... алты яшендә бәйли. Хәер, шәл бәйләүчеләр авылы саналган 1 нче Зубачида элек бу гадәти күренеш саналган. Ә бүген? Компьютер артыннан тормаган, гаджетларын кулдан төшермәгән замана кызларын кул эшенә ничек өйрәтергә? Кайчандыр патшабикәләр ябынган, Парижның мода салоннарында кием-салымга үтә нәзберек француз хатын-кызларын да сокландырган, Лондон, Вена, Филадельфия, Чикаго кебек шәһәрләрдә узган күргәзмәләрнең төп бизәге булып торган атаклы Оренбург шәлен киләчәк буыннар белерме? (Алга китеп булса да әйтим – бу сорауга җавабым бар минем!) Оренбург шәле турында Альбинадан остарак итеп берничек тә сөйләү мөмкин түгел, сүз – әңгәмәдәшемә.

Тәвәккәллек – ярты бәхет

Яңа эшкә тотынганда тәвәккәллек кирәк. Анысы миндә җитәрлек! Ападан узып, 18 яшемдә үк кияүгә чыкмас идем югыйсә. Хәер, әтием Фаил адашын – булачак ирем Фаилне бер күрүдән үз улы кебек якын итмәсә, аларның хәер-фатихасыннан башка бу адымны ясамас идем анысы... Беренче балабыз Тимур туды, аннан икенче улыбыз – Динислам... Мин шәфкать туташы булып эшлим. Хезмәт хакым күбрәк булсын дип, өстәмә нәрсәгә өйрәнергә, укырга була – барысын да эшләдем. Тик алган акчам һаман биш меңгә дә тулмады.

Шәл бәйләргә мине Мәгъмүрә әбекәем, урамга уйнарга да чыгармыйча, мәҗбүриләп өйрәткән иде. Бәйләүчеләр күп ул, тик безнең әни кебек бу эшкә иҗади якын килүчеләр, шәлнең бизәкләрен үзләре уйлап чыгаручылар сирәк. Мин аның мәктәбен уздым. Әни кебек нәзек итеп эрләргә өйрәндем.

Шәһәрдә үссә дә, Фаилгә дә шәл бәйләү эше ят түгел иде. Кайнатам гомер буе Оренбург шәл фабрикасына кәҗә мамыгы әзерләү белән шөгыльләнгән. Фаил дебетнең сыйфаты нинди булырга тиешлеге хакында ишетеп кенә белми, ул аны классификацияли, сортларга аера.

Утырып сөйләштек тә, үз эшебезне ачып карарга булдык. Балаларны иремә калдырдым да, Мәскәүгә, Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенә чыгып киттем. Әнинең бәйләгән шәлләрен алдым, бианамныкын, үземнекеләрне. Бөтенесен сатып кайттым! Аннан икенче күргәзмә буласын ишеттем... Барган саен сатырга әйбер җитми кала. Монда кулдан алып, тегендә сатсаң, файдасы бөтенләй юк. Бәйләтергә кирәк! Без дебет ала башладык. Алабыз да шәл бәйләүчеләргә таратабыз. Әзер шәлләрне җыеп кайтабыз да, мин өйдә агартам, киерәм... 2007–2008 елларда Фаил белән юлдан кайтып та кермәдек: кайда нинди күргәзмә, нинди ярминкә – без шунда идек. Екатеринбург, Чиләбе, Уфа, Санкт-Петербург, Архангельск, Ухта, Череповец...

480 сәгать

Зур бер мамык шәлне өлгертү өчен шуның кадәр вакыт кирәк. Челтәр шәлгә азрак – 320 сәгать. Бу вакыт эченә кәҗәне тараганда аның мамыгын классификацияләү, мамыкны эшкәртү (юу, киптерү, тарау, аялау, тетү, агарту, буяу, парда тоту), эрләү һәм бәйләү керә. Безнең предприятие шушы эшләрне башыннан ахыргача тулысынча башкара. Дебетне Биләй районындагы «Донской» хуҗалыгыннан алабыз. Алар унике мең кәҗә асрый. Дебет сайлау, әйткәнемчә, Фаил өстендә. Илле-алтмыш килограммнан башлаган идек, былтыр менә ике тонна сигез йөз килограмм алдык. Бер шәлгә илле-сиксән грамм мамык китә. Югары сортлы, элиталы мамыкны (аны кәҗәнең түш тирәсеннән тарыйлар) халыктан җыябыз. Мондый мамыкны йортта 5-6 кәҗә булганда, аларны бик әйбәт итеп тәрбияләгәндә генә алырга мөмкин. Мин ул мамыкны аерым тотам, иң яхшы бәйләүчеләремә генә бирәм.

Мамыкның сыйфаты бик күп нәрсәләргә бәйләнгән. Хәтта кышның салкын яки җылырак килүенә дә. Бер кәҗәнең мамыгы икенчесенә бервакытта да охшамый. Тагын бер нәрсә бар. Бер кәҗәнең дебетен ике бәйләүчегә бүлеп бирәсең. Алар бәйләгән шәлләр исә бер-берсеннән җир белән күк кебек аерылырга мөмкин – кулдан бик күп тора. Кемдер тыгызрак эрли (андый шәл озаграк кабара, әмма озаграк яши дә), кем бушрак эрли (андый шәл тиз мамыклана). Шәл сайлаганда дебете нык күпергәненә кызыкмагыз диясем килә – андый дебетнең инде коеласы гына кала. Ә Оренбург шәле ул җиңел, нәзек итеп эрләгәнгә күрә артык мамыкланмый. Палантиннарыбызның мамыгы күренми дә, кайберәүләр аптырап: «Моның дебете бармы соң?» – дип сорый хәтта. (Һәрбер әйберебезнең 85 проценты – дебет, 15 проценты – җеп.) Үзе күренмәсә дә, уникаль Оренбург мамыгыннан ифрат зур җылылык килә.

Мамыкны эшкәртү цехы тулысынча Фаил өстендә. Миңа ул эрләгән әзер җеп, йә агартылган, буяган дебет кенә бирә.

Иң өлкән шәл бәйләүчебез Мөнәвәрә апа Кашаевага 87 яшь!

Осталарның осталары

Шәл бәйләүче осталарның иң-иңнәрен ачыклау өчен өлкә буйлап бөтен авылларда конкурс үткәрдек. Шундый сиксән алты бәйләүчебез бар хәзер. Алар бер-берсен кабатламый. Хәтта үз-үзләрен дә кабатламый! Безнең һәр шәлебез – бердәнбер! Аларга түләгәндә барысын да исәпкә алырга тырышабыз: бәйләүнең катлаулылыгын, нинди элементлар кергәнен... Минем үзем өчен беренче урында сыйфат тора. Саткан әйберем өчен йөзем кызармау кирәк.

Айга ничә шәл бәйлиләрме? Төрлечә булырга мөмкин. Иңе-буе ике метрдан арткан шәлләр бәйләүчеләр бар. Үзләре эрләп! Кәлимуллина Сәкинә, Рәмзия апалар... Икешәр ай бәйлиләр! Алар шактый кыйммәт йөри – унсигез меңнән егерме биш меңгә кадәр. Эксклюзив саналган автор эшләре беркайчан да арзан була алмый! Сарыкташ районы Чишмә авылыннан Хәмидә апа белән аның кызы Эльвина шәлне сәйлән белән бизәп эшли башладылар менә. Бу әле яңа технология. Безнең максат – сатып алучыны гел гаҗәпләндереп тору. Кибеткә килгәч, миннән: «Берәүгә дә күрсәтмәгән эшең бармы?» – дип сораучылар бик күп.

Мамык шәлгә бәйләүченең күз нурлары, күңел җылысы кергән, диләр. Юкка әйтмиләр! Кәеф булмаса, шәл бәйли алмыйсың – кул бармый. Үземнән беләм. Әнкәй дә шулай ди. Үзеңне ирексезләп тотынсаң, барыбер матур килеп чыкмый. Күңел күтәренке булганда исә кулда энә биеп тора. Дебетне мин бригадирларга калдырам, алар бәйләүчеләргә тарата. «Бу апа бу атнада шәл бәйләсен, тегесе – челтәр шәл», – дип әйтеп китәм. Төрле чаклар була. Кайберләре шалтырата да: «Әй, иркәкәем, бу атнада шәл килеп чыкмады, утырдым да челтәр шәл бәйләп куйдым», – ди. Нишләтәсең, димәк, шәлгә кулы бармаган. «Ярый, апа, икенче атнага бәйләр-









сез», – дим. «Апа, читлəренə ландышлар куеп бəйлə, биш ай-бизəк сал», – дип киткəннəн соң: «Бу атнада андый бизəк чыкмады әле», – диючелəр бар. Аңлыйм, күңеле тартмаган... Ул авыл апалары миңа гел телəк телəп торалар. «Пенсиялəребезгə никадəр өстəмə китерəсең», – дилəр. Иң гади палантинга мең ярым алалар, ə алар аны көн ярымда бəйли... Безнең якта хатын-кыз телевизор каршына да кулына энə тотмыйча утырмый.

Бездə һəр шəлнең шəхси номеры бар: кайчан кабул ителгəн, кайчан сатылган – барысы да теркəлə.

Кем эрлəгəнен, кем бəйлəгəнен, кем кулы икəнен шəлгə кагылуга таныйм. Əниле-кызлы бəйлəүчелəрем бар. Беркөн Ирина: «Менə палантинны бетердем», – дип китерде. «Бу синең кулың түгел», – дим. «Нишлəп алай дисез, менə бит бизəге дə минеке», – ди. Чыгып киткəндə генə: «Минеке түгел иде шул, Альбина апа», – диде. Оренбург өлкəсе зур – бер төбəкнең шəллəре икенчесеннəн нык аерыла. Сарыкташта нəзек кенə энə белəн вак итеп бəйлилəр – анда шəллəр затлы. Орск, Медногорск яклары калын итеп эрли: аларның палантиннары мамыклы. Хəтта бер авыл икенчесеннəн аерыла – шəлнең «теллəре» һəркемнең үзенчə килеп чыга.



«Күршем сездə эшли, ə мин аннан да яхшырак бəйлим», – дип яныма килүчелəр бар. «Эшлəрегезне күрсəтегез», – дим. Бөтенесенеке дə ошап бетми, билгеле. Əмма авыл кешесенең күңеленə каты бəрелəсе дə килми. Мин һəр əзер шəлне үзем карап кабул итəм. Тигез эрлəнмəгəн, тигез бəйлəнмəгəн шəллəрне алмаячакларын белəм... Андый очраклар өчен зур капчыгым бар, җыеп барам да, гадəттə, əбилəргə хəер итеп таратам яки монастырьга бүлəк итеп бирəм (Свердловск өлкəсе Среднеуральск шəһəрендəге бер монастырь ел саен бездəн сиксəнлəп шəл сатып ала).

Бəйлəүчелəребезнең барысы да диярлек пенсия яшендə. Бүгенге əнилəр дə, бəлки, кызларын кул эшенə өйрəтергə тырышадыр, əмма яшьлəр үзлəре, аларның кызыксынулары башка хəзер... Буыннан-буынга күчеп килгəн һөнəрне саклыйсы иде бит! Авылларда кызларны шəл бəйлəргə өйрəтү өчен түгəрəклəр ачтык. Сарыкташта – Сəкинə апа Насаева, Куандык районында Дания апа Ишкининалар бу эшкə бик телəп алынды. Кызлар эрлəргə дə өйрəнə. Бəйлəгəн, юган, киергəн əзер палантинга 500 сум түлим. (Ул палантиннарны кибеттə дə 500 сумга сатам. «Укучылар эше» дип, алар бездə аерым ята.)

Оренбург сəнгать колледжында бəйлəргə өйрəтүче бүлек бар. Бу эшкə яшьлəрне Рима Якупова өйрəтə. Үткəн җəй аның студентларын үземə практикага алдым. Арада кулы эшкə ятучы кызлар бар. Күңелемə салып куйдым: яңа кешелəр, яңа куллар, яңа идеялəр гел кирəк.

Күргəзмəдəн – күргəзмəгə

Мин Мəскəү Һөнəрчелəр палатасында əгъза булып торам. Шуңа күрə күргəзмəлəрдə еш катнашам. Узган ел: «Дубайга барабыз, анда Россиянең нəрсə белəн яшəгəнен күрсəтергə тиешбез», – дип шалтыраттылар. «Ул эсседə безнең шəллəр кемгə кирəк булыр икəн?» – дия-дия, юлга җыендым. Кала да алмыйм: Оренбург шəле – илнең атаклы брендларының берсе. Беренче челтəр шəлемне: «Кара, нинди матур эскəтер!» – дип бер хатын сатып алды. Фирая апа ул шəлне ике айга якын бəйлəгəн иде, ə монда «өстəлгə ябам», дилəр... Борчылсам, эчтəн кайнасам да, дəшмəдем – бер шəлне булса да сатып кайтырга кирəк бит. Икенче көнне яныма Согуд Гарəбстаныннан бер абзый килде. «Мəккəдə сигез кибетем бар», – диде ул. Мəчет төшерелгəн шəллəрне күрсəтеп торам, ул: «Алам», – дип ымлап бара... 26 шəлемне алып китте!

Гыйнвар ахырында – Берлинга, «Яшел атна» аграр күргəзмəсенə бардык. Безнең өлкəдəн кырык кешелек





делегация иде: губернатор үзе, министрлар, район башлыклары... Килүгә, миңа өстәл бирделәр – шәлләрне урнаштыра башладым. Башымны күтәрсәм, үзебезнең делегация вәкилләре чиратка басып шәл сайлыйлар. «Оренбургта кибеттә йөрергә вакытыбыз юк», – диләр...

Кызыбыз Азалия машинада үсте дисәм дә була. Аның белән беренче тапкыр юлга чыкканда ике генә атналык иде... Алты ай чагында аны алып Мәскәүгә, Һөнәрчеләр фестиваленә киттек. Калдырыр идем – имезәм, күкрәктән аерасым килми. Фаил бала белән машинада утыра, мин ике сәгать саен ашатып киләм. Кунакханәдә кич коендырабыз – Азалиянең аяк бармагы арасына кадәр дебет... Хәзер каядыр барасы булса: «Командировкага кил», – дип әнкәйгә шалтыратабыз. Ул ишектә күренүгә Азалия миңа: «Әбекәй килде, син кая китәсең?» – дип тотына... Хәтта әнкәй кунакка килгәндә дә!

Заман белән бергә

2006 елны шәлләрне алмый башладылар. Яшьләр: «Әбиләрнеке кебек», – диләр дә борылып китә... Ак һәм соры төс бит инде бездә. Бер күргәзмәдә җитеннән теккән кием-салым сатучылар белән янәшә басып тордык. Шундый ук проблема белән очрашкач, алар продукцияләрен төрле төсләргә буйый башлаган. Мин дә тотындым! Нинди генә буяу кулланып карамадым?! Өч ел элек, ниһаять, туры килгәнен таптым. Кировтан кеәм буйый торган буяу алабыз – ул мамыкның сыйфатын бозмый. «Мамык төрле төсле була алмый», – дип, белгечләр каршы да чыкты. Әмма бит халыкка ошый! Без моны Оренбург шәленә яңа сулыш өрү дип саныйбыз. Соңгы вакытта палантиннан туй күлмәге, якалар, яшьләр өчен стильле кием-салым җитештерә башлавыбыз да – сатып алучы ихтыяҗын канәгатьләндерүебез.

Тиздән цехыбызга Италиядән яңа җиһазлар кайтырга тиеш. Бик көтәбез! Безнең Оренбург мамыгы өчен махсус эшләнә! Пычрак, чүпле чималны кертеп җибәрәсең, ул аны икегә бүлә дә бирә: бер ягында каймак кебек дебет, икенчесендә – чүп. Ә ничек нәзек итеп эрләвен күрсәгез! Орчык белән эрләү, гомумән, онытылып бара. Аннан, бер шәллек мамыкны бер утыруда эрләргә кирәк: торып, бүленеп йөрсәң, җепнең юанлыгы югала, тигез килеп чыкмый.

Соңгы вакыт мамыкны башта ук пар белән «бүрттереп» утырту кебек яңа технологияне кулланабыз. Хәзер безнең паутинкаларны юганнан соң тарттырып киптерергә кирәкми: сатып алучы аны үзе дә юа ала.

> *...Уңыш берәүгә дә бер көндә генә килми. Үргә күтәрелү өчен еллар кирәк.*

Мамык эшкәртү цехы, дүрт кибетләре – икесе Оренбургның үзендә, берсе Орск шәһәрендә, тагын берсе – Бозаулыкта. Шуларның икесе – музей-кибет. (Ул музейларда шәл бәйләү процессы башыннан ахырына кадәр күрсәтелгән. «Безгә бит кунаклар, төрле делегацияләр бик күп килә. Гади кибеткә кергән кебек кенә тәэсир калмасын иде аларда дип тырышабыз. Кунаклар музей янында фотога төшәргә ярата», – ди Альбина.)

«Евразиянең иң яхшы товарлары» Халыкара конкурсы – Гемма»ның Алтын медале иясе (2012, 2013), «Россиянең иң яхшы 100 предприятиесе һәм оешмасы» Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе (2012), «Россиянең халык һөнәрчеләре фестивале – Ладья» (2004–2012) күргәзмәсе бүләге иясе... Кибет диварларындагы мондый язуларны саный китсәңме?! Әйе, ундүрт ел эчендә шактый җыелган алар. Әмма рәхмәтләрнең тагын да кыйммәтрәкләре бар. Алары – гади сатып алучыларның хатларында: «Әтием Оренбургка командировкага барган иде. 8 Март бәйрәменә миңа сездән шәл алып кайтты. Аның матурлыгы!» «Беренчедән, заказымны бик тиз үтәдегез, рәхмәт! Икенче рәхмәтем, әлбәттә, шәл өчен! Оренбург шәлен мин нәкъ шундый итеп күз алдына китергән идем...» «Бүләккә дип сездән шәл алган идем. Әнием шулкадәр канәгать!..»

Сатып алучылар дигәннән... «Оренбург шәлчеләре» фирма-кибетенә керергә туры килеп, шәл сайлаучылар арасында кемнедер Мәскәү артистына охшатып калсагыз, гаҗәпләнмәгез – алар, чыннан да, бу кибеттә еш кунак. Гомумән, Оренбург җиренә аяк баскан һәр кунакның юлы шушы кибет аша да уза. Җаныгыз ни тели: шәл, челтәр шәл, палантин, пончо, пелерина, пальто, перчатка, бияләй... Күңелегезгә яткан әйберне сайларга булышканда, әллә күпме киңәш тә бирерләр.

...Оренбург шәле – кул эшләренең кыйммәтен, кадерен, дәрәҗәсен белгәннәрне сокландыруын дәвам итә. Ул, әлбәттә, яшәячәк. Альбина Әбсәләмова кебек үз эшен яратып, бирелеп эшләүчеләр булганда яшәячәк. Әнә бит ул шәл турында ничекләр итеп сөйли!

– Шәл ул сине болыт кебек урап алырга, тәнеңне генә түгел, җаныңны да җылытырга тиеш...









ЧӘКЧӘК ҖЫЕНЫ



Лилия ГӘРӘЕВА

АЗНАКАЙ ЧӘКЧӘГЕ ИЖАУНЫКЫННАН НӘРСӘСЕ БЕЛӘН АЕРЫЛА? Ә АКТАНЫШТА АНЫ НИЧЕК ПЕШЕРӘЛӘР? АВЫЗДА ЭРЕП КИТӘРЛЕК ГӨБӘДИЯНЕҢ СЕРЕ НИДӘ?

Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы милли аш-су әзерләүчеләрнең мастер-классларын уздырмаган булса, ул серләрнең барысын берьюлы белә алмас идек. Ник дисәгез, бер генә оста да үзенең сер капчыгын селкеми. Укучыларыбыз: «Азнакай якларындагыча эре чәкчәк пешерергә өйрәтегез әле», – дип сорыйлар иде, менә бит, форсаты чыкты. Ике көндә нинди генә милли ашлар пешерергә өйрәнмәдек. Берсеннән-берсе уңган осталарыбыз, ялындырмый-нитми генә, серләрен ачты да бирде. Аларны, кадерле укучыларыбыз, сезнең белән дә бик теләп уртаклашабыз. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Рәес кызы Идрисова әйткәнчә, без йортыбызга килгән кунакны ачык йөз белән каршы алып, йөзгә кызыллык китермәслек итеп сыйлый да белергә тиеш. «Сөембикә» журналы каршында оешкан «Ак калфак» милли хәзинәләребезне халыкка кайтару җәһәтеннән бик кызыклы проект башлап җибәрде – илебезнең төрле почмакларыннан гына түгел, хәтта чит илләрдән дә килгән йөзләп кунакка милли ашлар пешерергә өйрәтәбез.

«Тәмле җыен»ның беренче көне. Халыкара хезмәт күрсәтү көллиятендә чәкчәк, талкыш кәләвә һәм гөбәдия пешерәбез. Татар кызларын әллә каян танырлык: билләрендә чигүле алъяпкыч, башларында энҗеле калфак.






Фото: Шамил Абдюшев, Булат Ибраһимов

Гөбәдия

Аш-су остасы **Гөлсинә СӘЙФУЛЛИНА** гөбәдия пешерергә өйрәтә.

Гөбәдия өчен камыр ясау:

майлылыгы 15 процентлы 1 литр каймак, 6 йомырка, 1 аш кашыгы тоз, 3 уч шикәр комы (120 г тирәсе), 80 г чүпрә (коры чүпрә ярамый, камырны начар кабарта икән), 200 г акмай, 50-60 г үсемлек мае. 1 литр сыеклыкка 2 кг исәбеннән он алына. Онны салганчы, сыеклыкны чак кына җылытып алырга кирәк.
Май камырны басып бетерер алдыннан гына салына. «Аркадан тир бәреп чыкмый торып, камыр әзер булмый», – ди Гөлсинә ханым. Басканнан соң камырның бераз кабарганын көтәргә кирәк. Бу кадәр камырдан өч таба гөбәдия чыга.

Эчлеген ясау:

(бер таба гөбәдиягә)

1 стакан тулыр-тулмас дөге, 5 йомырка (кабыгы әрчелгән йомырканы тозга манып алып, эре угычтан уалар), 1 стакан йөзем җимеше, 300 г корт, 350 г акмай. Эчлек катлы-катлы итеп салына. Акмайны йөзем өстенә түшәп чыгалар. Гөбәдиянең аскы ягына – 500 г, өске ягына 200 г камыр кирәк.

Гөбәдия пешә торсын, без икенче залга – Азнакайның Буралы авылыннан танылган чәкчәк остасы **Фәридә ШӘЙДУЛЛИНА** остаханәсенә юнәләбез. Фәридә ханым чәкчәк пешерү белән егерме еллап шөгыльләнә икән. Дүрт ел элек үзенең чәкчәк пешерү цехын да ачып җибәргән. «Кызлар, өйләрегезгә кайткач, сез дә чәкчәк пешереп карагыз. Бик табышлы», – дип, безне дә кызыктырды әле. Гомумән, Фәридә ханым бик үзенчәлекле кеше. Буралы авылының «Ак калфак» оешмасы рәисе дә ул, үзләрендәге «Сердәш» ансамбленә дә йөри. Быел юкка чыккан авыллар турында кичә уздырырга ниятли. Барыбызны да көз көне узачак каз өмәсенә чакырып калды.

Фәридә ханым каз өмәләре дә, «Чәкчәк бәйрәмнәре» дә оештыра.

Азнакай чәкчәге

5 йомырка, 1 аш кашыгы үсемлек мае, бер чеметем тоз, бер чеметем чәй содасы. Боларның барысын бергә кушып, аз да түгел, күп тә түгел – нәкъ 20 минут миксер белән күпертәбез. Аннан соң агач кашык алып, он куша-куша, туглыйбыз. Камыр кашыкка ябышмаслык булсын. Бер кашык камырны онлы кунага төшереп, бау кебек тәгәрәтәбез. Кулны үсемлек мае белән майласаң, камырны тәгәрәтүе уңай икәнлеген беләсез инде. Камыр «бау»ны 3 см озынлыгындагы кисәкләргә кисәбез. Һәр кисәкне аерым-аерым тагын бер кат тәгәрәтеп чыгабыз. Бер кеше камырны тәгәрәтеп, икенче кеше майда пешереп торса, эш тизрәк бара.



Фәридә апа чәкчәкне ике савытта пешерә. Бер савыттагы майда кыздырганда, икенче савыттагысы суына тора. 1 литр көнбагыш маена ярты стакан салкын су салалар. Туңмай яки елкы мае да өстәп җибәрсәң, чәкчәк тагын да тәмлерәк була икән. Камырны җылымса майга салып пешерергә кирәк. Бик гаҗәпләнеп: «Суына төшкән майда пешергәндә камырга май сеңәдер бит?» – дигәнебезгә, Фәридә ханым чәкчәкне кайнар майга салып та пешереп күрсәтте. Дөрестән дә, салкын майга салырга кирәк икән шул. Кайнар майга салган камыр бик нык җәелде.

Пешкән чәкчәкне иләккә салып, артык маеннан арындыралар.

Күнелә егермешәр кило чәкчәк пешерәбез. Туйларга бишәр килолы чәкчәккә заказ бирәләр.

Фәридә ханым чәкчәк катыру өчен ширбәтне болайрак әзерли:

3 стакан шикәр комын, 1 стакан суны, 2 аш кашыгы балны 15 минут чамасы кайната. Әзерлеген белү өчен ике бармак белән кыскалап карарга кирәк. Сузылса, әзер.

Ширбәтне сөт белән дә ясарга була. 3 стакан шикәр комына 1 стакан сөт салып кайнатасы. Сөтле сироп белән катырылган чәкчәк аеруча матур, ялтыравыклы була икән.

Фәридә ханым моңа кадәр берәүгә дә әйтмәгән бер хәйләне дә өйрәтте: «Әгәр дә чәкчәкне бик тиз пешерергә кирәк булса, камырдан әвәләнгән «бармаклар»ны майлы табага тезеп, мичтә пешерәләр. Табаның бераз тирәнен алырга кирәк. Май камырны күмәрлек булмаса да ярый. Вакыт-вакыт табаны селкеткәләп торырга кирәк».

Фәридә ханымнан соң, плитә янына Әгерҗе районында туып-үскән **Фәния ГАЙНЕТДИНОВА** басты. Алар ягындагыча пешерелгән чәкчәктән дә авыз итеп карыйк.

Иҗау чәкчәге

Фәния апа биш йомырканы миксер белән күпертеп, туңдырырга куя икән. Иртәгә чәкчәк пешерәсе дигән көнне, кичтән аларны эретергә алып калдыра. Иртәгәсен ул шушы йомыркаларны янә миксер белән агарганчы күпертә, ярты аш кашыгы үсемлек мае сала, ярты бал кашыгы соданы бер бал кашыгы аш серкәсе белән сүндереп, йомыркалар янына өсти. (Соданы аш серкәсе белән сүндереп салсаң, чәкчәкнең эче куыш булмый икән.) Тоз салмый, ул камырны җәя ди. Он сала-сала, агач кашык белән туглый. Камыр шактый ук йомшак булса да, кашыкка ябышырга тиеш түгел.

Шушы камырны он сипкән кунага төшереп, уклау белән җәя. Җәймәнең калынлыгы 0,5 см чамасы. Җәймәдән 2 см киңлегендәге тасмалар кисә. Моның да хикмәте бар. Фәния апа пычак урынына юка читле тәлинкә куллана. Тәлинкәне кырын бастырып, камыр өстеннән тәгәрәтә. Камырны тасмаларга тәлинкә чите белән кисүе бик уңай икән.

Ширбәт

Ширбәтне Фәния апа болай ясый: 3 стакан шикәр комына 1 стакан су һәм 600 г бал сала.

Тагын бер серне ачыйк әле: чәкчәк пешкән майны да ташламыйлар. 1 литр майга 0,5 литр су салып, ярты сәгать кайнатсаң, май чишмә суыдай чистара икән.

Без монда чәкчәк белән мәш килгәндә, күрше залда талкыш кәләвәгә үк керешкәннәр. Талкыш кәләвә тәмле тәгам булса да, ясавы гаять четерекле. «Кәләвәгә тотыну өчен бик зур тәҗрибә кирәк. Беренче тапкырдан гына түгел, бишенче тапкырыннан да килеп чыкмый әле ул», – диләр бу татлы тәгамне ясый-ясый остарып беткән пешекчеләр. Талкыш кәләвә пешерергә **Миләүшә МИРОНОВА** өйрәтә.

Талкыш кәләвә

75 г балга 75 г су һәм 250 г шикәр комы кушып, 20–25 минут кайнаталар. Әзер булгач, шушы карамельне чак кына суытып, суза башлыйлар. Кулга башта бер кат чүпрәк перчатка, аның өстеннән калын резин перчатка кияргә кирәк. Эш рәвешен тасвирларга тырышып карыйм: карамельне сул кулга тотып, уң кул белән бер башыннан тартып сузабыз. Бик артык озын сузарга да кирәкми. Шуны урталай бөкләп, сул кулга кайтарып салабыз. Бу тиз-тиз эшләнә. Карамель агарып, җепселләнә башлагач, кунага салып, ике башыннан ике кеше суза башлый. Сузалар да, урталай бөкилиләр, сузалар да бөкилиләр...Ул арада әлбәсен дә пешереп алырга кирәк.

Анысы болай ясала:

50 г онны 75 г сары майда кыздырабыз. Әлбәне кунага бушатып, карамельне шушы әлбә өстендә сузабыз. Әлбә карамель җепселләре арасына сеңеп бетә. Җепселләр бик нечкәреп, сынучанга әверелгәч, талкыш кәләвәне формага тутырып (кечкенә рюмка да ярый) подноска каплап барабыз.

Талкыш кәләвәдән соң аш-су остасы **Гөлнур ХАМАТНУРОВА** Актаныш чәкчәгенең серен ачты. Ул якта да йомырканы туңдырып эшлиләр икән. Чәй содасын аш серкәсе белән сүндереп салалар. Камырны йомшак итеп басалар. Уклау белән җәеп, тасмаларга кисәләр. Һәр тасманы тагын аркылыга кисеп чыгалар. Гөлнур ханым камырны кайнап торган үсемлек маена салып кыздырды. Актаныште ширбәтне болайрак әзерлиләр: 500 г балга 250 г шикәр комы кушып, кайнатып чыгаралар. Ике бармак белән кыскач, сузылса, ширбәт әзер. Суга тамызып та белергә мөмкин: шар кебек катарга тиеш. Пешкән чәкчәкне табакка бушатып, өстеннән ширбәт агызалар, һәм кулны салкын суга манып ала-ала, матур бер формага кертеп, подноска өяләр.

Беренче көнгә тәгаенләнгән мастер-класслар шуның белән тәмам. Кичкә кунакларыбызны Кытайда туып-үсеп, Казанда белем алучы татар яшьләре белән очрашу көтә иде. Анысы хакында язып тормыйм, әмма Кытай яшьләренең татарча шулкадәр матур сөйләшүләре, борынгы җырларыбызны искитмәле итеп башкарып, безне биһуш иткәннәрен генә әйтеп китәм.

(*Дәвамы киләсе санда.*)

КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ...

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызларының ике форум арасында үткәргән бәйге-чаралары:

■ «Гаиләдә һәм җәмгыятьтә татар хатын-кызының урыны»: рәсем сәнгате, графика, гамәли-сынлы сәнгать әсәрләре конкурсы.
■ «Гаиләдә һәм җәмгыятьтә татар хатын-кызының урыны»: хикәя, эссе, очерклар иҗат итү буенча әдәби конкурс.
■ «Илемне саклаучыга вәгъдә бүләгем — чиккән кулъяулык».
Кулъяулык чигү үзенең яңарыш чорын кичерә. Элек-электән кулъяулык — сөю, вәгъдә билгесе. Бәлки, яшьләр бүген дә аны бер истәлек формасы итеп алыр?
■ «Сабантуй батырына — чиккән сөлгем — минем бүләгем». Кабатланмас бизәкләр төшерелеп чигелгән чүпләм, чуптарлы, кызыл башлы сөлгеләр... Сөлге — осталыкка өлге!
■ «Ак калфак» чигүчеләр арасында конкурс. Күчмә калфак алдынгы оешмаларга биреләчәк.
■ Җиләк җыючылар бәйгесе. (Бу көнне җыелган җиләк тә, коелган как та, бәйләнгән мунча себеркесе дә мохтаҗларга, авыруларга сәдака итеп өләшенде.)
■ Калфак һәм изү чигү, татар ашларын әзерләү буенча мастер-класслар үткәрелде.

КИЛӘСЕ ЕЛГА НИЯТЛӘНГӘН ЭШЛӘР:
■ Шәҗәрә бәйрәме.
■ Татар милли киемнәре тегү буенча дөньякүләм дизайнерлар конкурсы.
■ Димчеләр, яучылар җыены.
■ Татар гинекологлары җыены.
Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми — балалар күкрәк сөте имеп үсәргә тиеш.
■ Яңа өйләнешүчеләр, яшь әниләр мәктәпләре ачуны дәвам итү.
■ Һәр балалар бакчасына бишек җырлары җырлауны кертү.
■ Мәктәпләрдә тәнәфес вакытында кыңгырау чыңы итеп татар халык көйләрен кертүгә ирешү.
■ Төрле йола бәйрәмнәре үткәрү.
■ Яңа туган сабыйны каршы алу белән бәйле йолаларны яшь гаиләләргә аңлату, сәхнә аша күрсәтеп бирү юнәлешендә эшләү.


Резеда ВӘЛИЕВА

Шигырь сөючеләрнең ягымлы, җайлы, җырлы, талантлы шагыйрә апасы бар – Резеда ВӘЛИЕВА ул. Аны мәктәпләрдә, студентлар аудиторияләрендә, авыл клубларында көтеп алалар. Тәмле теле, бит очлары чокыраеп китеп елмаюлары, дустанә сөйләшүләре, зыялы һәм зәвыклы табигате белән йөзләр, меңнәр күңелен яулый да шигърияте белән сихерли. Яраталар Резеда апаны! Үзен дә, иҗатын да. Бүген аны 85 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, иҗат уңышлары телибез!

БӘЙРӘМ БҮГЕН ИЛЕБЕЗДӘ!..

Аналар теләге

Бәйрәм бүген илебездә,
Бәйрәм туган җиребездә.
Агыла халык, агыла бергә
Бар мәйданнар тулып.
Язгы аяз күгебездә
Күгәрченнәр оча бездә,
Байраклар чайкала җилдә,
Ялкын кебек булып.
Мәйданнарда – тын һәйкәлләр,
Мәйданнарда – тол әнкәләр.
Мәйданнарда – ал чәчәкләр
Һәм иелгән башлар.
Чагылып китә яшьле күзләр,
Кирәк түгел, артык сүзләр:
Бәгырьне телгән исемнәр
Уелганнар ташка...
Әкрен генә җилләр исә,
Ел артыннан еллар үтә,
Ә халыкта тик бер теләк,
Гүя бердәм сулыш:
Мәрмәр һәйкәлләр каршында,
Яшьле күзләр карашында
Катгый таләп:
Җирдә кабат
Кабынмасын сугыш!
Дөньялар гел тыныч булсын,
Кояш һаман көлеп торсын,
Фирүзәдәй саф күк йөзен
Капламасын болыт.
Гомере булсын балаларның,
Нурлы йөзен аналарның
Кара кайгы көйдермәсен
Кара ялкын булып.
Күгәрченнәр очсын уйнап,
Дуслык йөрсен илләр буйлап,
Зәңгәр күктән үлем түгел,
Нурлар яусын җиргә.
Яшьләр кулга-кул алышып,
Хезмәттә, җырда ярышып,
Килер көннәр каршысына
Атласыннар бергә!

Толымнарың синең

18 яшендә Бөек Ватан сугышына киткән сөекле апам Рәүзия истәлегенә

Хәтеремдә, мин төшемдә сине
Югалттым дип куркып уяндым.
Күзем ачсам, тып-тын якты иртә,
Син янымда. Шундый куандым.

Басkансың да көзге каршысына,
Озын толымнарың сүткәнсең.
Тезләреңә төшкән дулкыннардан
Нәкъ су кызы булып киткәнсең.

Ә күзләрең шундый, шундый уйчан,
Әллә ничек моңсу карыйсың.
Назлап сөйгән төсле чәчләреңне
Тарыйсың да һаман тарыйсың...

Мин сокланып сиңа карап ятам,
Куанычым сыймый эчемә.
Шулчак...
Кулларыңда кинәт кайчы күреп,
Сикереп торам!..
Әйе, исемдә,
Илгә килгән бәла минем өчен
Синең чәчләреңнән башланды:
Күз алдымда куе көлтә кебек
Толымнарың кисеп ташладың...
– Апам!!
– Мин фронтка, сеңлем!..
Әйтерсең лә, җир тетрәде кинәт,
Утлар сирпеп, туплар күкрәде.
Әйтерсең лә, сугыш өйгә керде –
Сабый күңелем шулай тетрәнде!

Аңладыңмы хисләремне минем,
Күкрәгеңә кысып үптең син:
– Чү, елама, мин бит үзем теләп!
Яшьләремне ашыгып сөрттең син...

Тын бакчада аннан таңга кадәр
Тальян гармун түкте моңнарын.
Аһ, мин беләм, ул кич тальян синең
Толымнарың сагынып елады...

Озатырга сине таң атуга
Бөтен авыл килде җыелып,
Соңгы сүзләреңне әйткән чакта
Көчкә генә тордым тыелып:
– Җиңү өчен!..

Шул җиңүгә илткән ут эчендә
Эзләреңне ничә җуйдык без,
Ничә тапкыр салкын толымнарың
Кайнар яшьләр белән юдык без...

Әле дә булса сөйләсәләр әгәр
Сагышларын сугыш елының,
Күз алдыма килә көлтә кебек
Киселеп төшкән ике толымың...

Яран гөл

(Сәүбән Чуганаев музыкасы)

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгырькәем, мине күрде исә.

Кайгы-хәсрәтем дә юк сыман,
Йөрәккәем яна ут сыман.
Газапланам иртә-кичләрен,
Әйтә алмыйча йөрәк хисләрем.

Яннарыма гына килсә иде,
Сөям сине, бәгърем, дисә иде.
Күзләреңнән алмый күзләрем
Сөйләр идем йөрәк серләрем.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгырькәем, мине күрде исә.

Агыйдел сылуына

(Илгиз Закиров музыкасы)

Агыйдел агышлары,
Зифадыр камышлары.
Агыйделнең бер сылуы –
Йөрәгем сагышлары.

Кушымта:
Агыйдел яры текә,
Сулары ерак китә.
Язны көткән назлы гөлдәй
Күңелем сине көтә.

Агыйдел каты ага,
Аккош канатын кага.
Аккош булып оч та, ярым,
Серемне әйт син аңа.

Кушымта.

Таңнар аткан чагында,
Агыйдел якларында.
Яннарыңа барыр идем
Дулкын канатларында.

Кушымта.

Асия ЮНЫСОВА

Күрше әбиләр

Сугышның нәрсә икәнен
Әле белмәгән чакта
Әбиләрнең сөйләшкәнен
Тыңладым бала чакта.

Кулларында тал чыбыгы,
Имеш, бәбкә саклыйлар.
Күләгәдә гәп саталар,
Яннарында сабыйлар.

Бар гамьнәре шунда кебек,
Үткәнне сагыналар.
Сыктамыйлар, елашмыйлар,
Көлешәләр җай гына.

Шундый кызык хатирәләр:
«Кара син Хәтирәгә!
Кем охшатыр аны бүген
Сука тоткан бер иргә?»

«Ә үзең соң, Фәхриямал,
Әйләндең бит Фәхригә,
Гыйззәт булган иде Газзә,
Шәмгун булды Шәмгыя».

«Малакаем, ул заманда
Бүтән чара калмады.
Балтасы да, чалгысы да
Безнең кулда уйнады».

Ятим калган киң яланнар,
Бүреләре азынган.
Кырга чыккан хатын-кызлар
Учак-казан яныннан.

«Хатын-кызга буйсынамы
Эш коралы, мал-туар?
Ирләр өнен ишетсеннәр –
Тамак кырдык, бил будык».

«Башкавыллар нишләгәндер,
Ә без таптык әмәлен:
Ирләр булып каршыладык
Ил белән Җиңү көнен».

Ямьле генә гәпләшәләр
Чирәмле күләгәдә.
Балачагым әбиләре,
Сагынам сезне мәгәр!

Күз яшьләремне сеңдерде
Алъяпкычлар итәге.
Ирләренә диган назлар
Оныкларга тәтеде.

Ир йөрәкле әбиләрнең
Догасы һаман бер үк:
«Шөкер әле, илләр тыныч,
Сугыш чыкмасын берүк...»

Кырлар түренә сибелгән
Ирләргә диган назлар...
Читән буе күләгәдә
Әбиләр белән казлар...

* * *

Һәр авылның үз һәйкәле
Сугышта калганнарга.
Һәйкәлгә язган исемнәр
Җитәдер полкларга.

Олау-олау киткәннәрнең
Кайткан бары кырыгы.
Авылдашлар куйган «һәйкәл»:
Бусы, диеп, Сәми үре,
Бусы Вәли тыкрыгы.
Шул үрләрдән чана шудык,
Ыкка төштек тыкрыктан.
Авыл шулай «уйлап тапкан»
Яуда калган ир-улларын
Саклау җаен тарихта.

Өйләр дә хәзер ят өйләр –
Үр-тыкрык янындагы.
Хуҗалары ятып калган
Кайсы ил туфрагында,
Нинди үр яулаганда?

Ятим өйләр тирәсендә
Мин кабат йөрдем юри.
Үзгәрмәгән атамалар:
Һаман шул Вәли тыкрыгы,
Һаман шул Сәми үре...















Фото: Анна Арахамия

КАРА САВЫТЫННАН... ХИКӘЯ



Эльмира ЗАКИРОВА

«Сөембикә» журналы редакциясендә түгәрәк өстәл тирәли утырып, гамьле сөйләшү – «Әдәби әсәрләрдә хатын-кызның урыны» дигән темага әңгәмә корылды. Анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Ләйсән Юнысова, һәм шушы темага уздырылган конкурс-бәйгегә килгән әсәрләрне бәяләгән жюри әгъзалары Нәбирә Гыйматдинова, Зиннур Мансуров, Вакыйф Нуриев, Эльмира Шәрифуллина, шулай ук редакция хезмәткәрләре катнашты. Конкурсны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстан Язучылар берлеге игълан иткән иде. Әдәбият елы уңаеннан актуаль темага уздырылган бу конкурс иң элек үзенең колачы белән сөендерде. «Туган телгә игътибар кими», «тел бетә» ише шикле уйларны юкка чыгара торган матур эш булды ул. Иҗатчылар арасында узарга тиешле бәйге күпләрне кузгатты. Җәмгысы 225 кульязма кабул ителде. Нигездә, хикәяләр, эсселар, очерклар. География киңлеге дә сөендерә. Татарстанның 24 районыннан һәм республика шәһәрләреннән, Башкортстанның 13 районыннан һәм Уфа, Нефтекама шәһәрләреннән, Австралия, Литва, Казакъстан, Төрекмәнстанда яшәүче милләттәшләребез дә бәйгегә кушылдылар. Киров, Пенза, Томск, Омск, Сембер, Самара, Оренбург, Курган, Әстерхан, Кырым татарлары каләм тибрәтте. Жюри рәисе җиңүчеләрне атады. Ркаил Зәйдулланың «Дәү-дәү әни» хикәясе – 1 нче, Галимҗан Гыйльмановның «Нигез йорт»ы – 2 нче, Айгөл Әхмәтгалиева («Баланнарда бал төме») һәм Гөлүсә Батталова («Саваплы сабак») хикәяләре 3 нче урын белән бәяләнде. Түбән Камадан Фәрит Имамов һәм Чаллыдан Гөлназ Шараева хикәяләре кызыксындыру бүләгенә лаек дип табылды. Конкурста яшьләрнең дә катнашуы – үзе үк матур фал! Пензадан 7 нче сыйныф укучысы Юлия Дәүликамова юллаган «Бала йөрәге» язмасы махсус приз белән билгеләп үтелде. Эссе, очерк, «Буыннар чылбыры» шәлкеменә караган эшләр дә гадел бәясен тапты. Түгәрәк өстәл янында сөйләшүдә әлеге конкурс нәтиҗәләре, гомумән, әдәбиятта хатын-кыз образын чагылдыру хакында кызыклы фикерләр, бәхәсле мәсьәләләр яңгырады.

Кадрия Идрисова: Үткәндә югалып калган әхлакый кануннарыбыз хакында мәгълүмат җитми хәзер. Конкурс әнә шул максатны күздә тотып та оештырылган иде. Килгән эшләрнең барысын да рәхәтләнеп укып чыктым. Гаҗәп күп эшләр. Урын яуламаганнары да игътибарга лаек. Истәлек язмалар да шактый. Конкурска килгән рәсемнәр белән бизәп, китап итеп чыгарасы иде! Кайбер өзекләрне үзем дә күчереп алдым. Мәсәлән, «Төшкә кадәр булган вакыт кына – вакыт. Төштән соң булган вакыт куянга атлана» кебек мәгънәле җөмләне.

Эльмира Шәрифуллина: Язмаларда хатын-кыз күңеленең искиткеч бай икәне күренеп тора. Өндә генә: безнең хатын-кызлар дәррәү кузгалырга әзер икән. Шулкадәр матур язмалар бар. Гореф-гадәтләребезгә, йолаларыбызга, кануннарыбызга кайтып, шулардагы байлыкны бала тәрбияләгәндә, гаилә тормышында кулланырга әзер алар. Эсселарны укыганда, әдәби әсәргә торырлыклары белән таныштым.

Ләйсән Юнысова: Бу бик кирәкле, бик вакытлы эш булды. Аны кузгатып җибәрү кирәк иде. Юкса соңгы елларда безнең әдәбиятта хатын-кыз образы югалып та калды кебек. Журналда да сизелә ул. Һаман шул бер үк тема: авыл, әби, сугыш еллары... Әби булмаган хатын-кызлар арасында матур персонажлар күренми.

Зиннур Мансуров: Бу конкурсның ике төп максатны күздә тотты дип уйлыйм. Иң беренчесе – телебезнең торышын ачыклау. Икенчесе инде рәсми максат – бүгенге җәмгыятьтә хатын-кызның урыны һәм каләм әһелләренең әдәби осталыгын бәяләү. Әсәрләрне гаҗәпләргә калып укыдым һәм бик сөендем. Кодрәтемнән килсә, бөтен кулъязмаларны да кертеп, аерым китап төзер идем. Күбесе, 90 проценттан артыгы, әдәби яктан эшләнгән, китапка кертеп була. Безнең телебез яши икән! Икенче яктан исә хатын-кызның роле хикәяләрдә берьяклы гына ачыла. Без хатын-кыз темасында бер чиктән икенчесенә ташланабыз. Йә хатын-кызны фәрештә итеп сурәтләргә тырышабыз; нинди фаҗига, бәхетсезлек бар – бөтенесенә ирләр гаепле булып чыга. Бәхәсле шәй бу. Монда алтын урталыкны табарга кирәк.

Ләйсән Юнысова: Игътибар итсәгез, «Сөембикә»дә хатын-кызны аерып өскә күтәрү, ир-атны таптап китү дигән әйбер юк. Ир-атларны, ата кешене күтәреп, зурлап күрсәтәбез. Әйтәсе килгән әйбер башка иде. Бездә өлкән буын гына матур татар хатыны итеп күрсәтелә. Заман укучысына бит бүгенге тормыштан алып язылган әсәрләр кирәк. Бүгенге яшьләребез татар китабын укырга алына. Чөнки аларда туган тел белән, матур әдәбият белән кызыксыну бар әле. Укый башлыйлар да, и-и, безнең язучылар шуның турында гына язалармыни, дип, китапны читкә алып куялар. Матур, тирән әдәбият булсын ул. Мөнәсәбәтләр тирәсендә генә әйләнмәсен. Булсын фәлсәфи әсәрләр, булсын тарихилары... Яшьләр китап укымый дисәләр дә, китап кибетендә – гел яшьләр бит. Кырылып китап алалар, ләкин үзебезнекен түгел. Безнең каләм ияләре, бөтен күрсәтер әйберләребез авылда һәм өлкән буында гына калган кебек, һаман үткән белән илһамланалар. Ә бит никадәр зур, бай мирасыбыз, образларыбыз, язучыларыбыз бар. Чит илләрдә дә укылырлык китаплар язылсын иде!

Вакыйф Нуриев: Тормыш үзгәрә – әдәбият та, үзебез дә, хатын-кыз да үзгәрә. Әдәбият тарихына күз салсаң... «Татар хатыны ниләр күрми?»ләрне алып карагыз... Сугышка кадәрге хатын-кыз белән сугыштан соңгы хатын-кыз инде бөтенләй башка. Хатын-кыз сугыштан соң аяк терәп сөйләшә башлый ул, Мәһдивчә әйтсәк, сытып эшли, усал. Мәһдиевнең Васфикамалы, Әмирхан Еникиның «Саз чәчәге»ндәге Нажиясе... Алар инде җәбер-золымда яши торганнардан түгел. Алар инде башка. Хатын-кыз гел үзгәреп тора. Бүгенге хатын-кыз инде ул – лидер, җитлеккән хатын-кыз. Ә җәмгыять аны лидер итеп кабул итәргә әзер микән? Конкурс хикәяләрен караганда шул сорауга җавап эзләдем. Хатын-кызлар Франциядә дә, АКШта да ил башы ролен даулый. Безнең илдә дә алдагы Президент хатын-кыз булырга мөмкин дигән фараз юктан түгел бит.

Хикәяләр күп, әмма әйбәтләре юк дәрәҗәсендә. Әйбәт дигәннәрендә дә хатын-кыз образы әби була, гадәттә.

Нәбирә Гыйматдинова: Конкурска килгән хикәяләрне укыгач, шундый тәэсир калды: әйтерсең, авторларга алдан ук чәйнәлгән-тапталган, бер үк эчтәлектәге тема бирелгән дә, алар игезәкләр кебек бер-берсенә охшаган хикәяләр әвәләгән. Күбесе хикәя жанрына туры да килми әле. Ир яисә хатын хыянәте, сәрхуш хатын яисә сәрхуш ир, ятим бала, ире үлеп тол калу, дус кызының ирен тартып алу, ялгыз гына бала үстерү, үткәннәрне сагыну, бәхетсез мәхәббәт, ирдән кыйналып яшәү... Авторларның фантазиясе шул түгәрәктән чыга алмый. Хәзер татар хатын-кызының җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге ролен бу мескеннәр образы аша билгелибезмени?! Билгеле, аларның да яшәргә хакы бар. Тик моның өчен оста каләм белән каһарманның психологик кичерешләрен сурәтли белү таланты кирәк, коры сөйләп чыгу гына җитми. Кайда безнең татар хатын-кыз эшмәкәрләребез, завод яки төрле фирма директорлары, табиблар, рәссамнар, укытучылар, аш-су осталары, сәхнә артистлары? «Менә бу аныкы гына, ул бирәүне дә кабатламый», – дип сокланырлык чын әсәр табылмагач, кәеф төшкән иде, соңрак өч-дүрт авторның хикәясе кулга керде. Ркаил Зәйдулланың «Дәү-дәү әни», Галимҗан Гыйльмановның «Нигез йорт», Айгөл Әхмәтгалиеваның «Баланнарда бал тәме» хикәяләре конкурсның дәрәҗәсен күтәреп җибәрде. Гөлүсә Батталова – яңа исем, аңа өметем зур.

Асия Юнысова: Хикәя югалды... Бездә хикәя дип вакыйга сөйлиләр. Җанны актарып ташларлык бер тема табалар да, шуны сөйләп чыгалар. Әнә, Чехов, мин кара савытын да хикәя темасына әйләндерә алам ди. Бездә кара савытыннан хикәя «тартып чыгара» белмиләр.

Разил Вәлиев: Хикәя ул әдәбиятның иң камил, иң кызыклы формасы.

Асия Юнысова: Хәзер бездә бер мода китте: үз авыллары теле белән яза башладылар. Безнең авыл теленең әдәбиятта хакы бар дигән тенденция китте. Мин ул тенденцияне кабул итеп бетермим. Образны ачканда кирәк ул җирле сөйләм. Типиклык өчен, типаж ясау өчен кирәк. Гомәр Бәшировлар оста файдалана иде, шивә ярдәмендә образга керү өчен кирәк иде ул...

Җиңүче хикәяләрдә төп каһарманнар – гел карчыклар. Әгәр шушы хикәяләр аша безнең хатын-кыз язмышы да, әдәбият язмышы да, милләт язмышы да күренә дип карасак – символика коточкыч. Чөнки хикәянең соңгы битендә теге дәү-дәү әбиләр үлеп китәләр. Әдәбиятта бер әйбер дә тикмәгә генә язылмый. Бал корты оча икән, аңа ниндидер мәгънә салынган. Әгәр әби дөнья куя икән, милләтнең, халыкның традицияләре югала, кабергә китә... Шәһәрдән кунакка кайткан оныкторыннарда гына каладырмы әле ул?!

Балтыйк буеннан Татар бугазына чаклы татарларыбыз яшәгән һәр җирдән каләмле кешеләр яза торган хикәяләр килә. Әмма болай итеп берәү дә әйтмәгән диярлек, сагаеп калырлык хикәя юк. Сүз дә юк, безнең хикәяләр елата да, җанны актарып та ташлый... Менә шундый әсәрләр. Ләкин без бит XXI гасырда яхшырак язарга тиеш. Аннары шунысына игътибар иттем: хикәяләрнең берсендә дә чистарындыра, тетрәндерә торган мәхәббәт юк. Нәрсә, хәзер ярата белмиләрмени? Бәлки, хәзерге тормыштан ярату киткәндер? Ни өчен Вишневскийның «Одиночество в сети» бәяны кебек әсәрләр юк?

Безнең дә бит каләм осталары да, күрсәтерлек образларыбыз да бар.

Разил Вәлиев: Рәхәтләнеп кызыксынып тыңлап утырам. Хикәяләрне укыйсым килә башлады. Күпме кешене кузгаткансыз! Бу әдәбият өчен дә, язучы өчен дә, укучы өчен дә кирәк.

Хатын-кыз – гаиләнең терәге, гаилә – илнең терәге. Бу турыда бәхәсләшәсе юк. Милләтнең аның ике аягы бар: берсе – гаилә, икенчесе – дәүләт. Хатын-кыз укымышлырак дигән фикерне әйттеләр бит. Китапханәгә йөрүчеләрнең күпчелеге – хатын-кызлар (75%), университетта укытучыларның 60% ы – хатын-кыз. Табибәләр, тәрбиячеләр, укытучылар – бар да хатын-кыз.

Әбиләр кирәк, әмма ләкин бик дөрес әйтәсез, яшьләр дә кирәк. Оныкларга да, Әмирхан Еники хикәяләрен укыгыз, дим. Әмма аларга үрнәк алырлык яшьләр образлары кирәк – бүгенге, алар яши торган чордан.

Зиннур Мансуров: Берьяклылык мине дә борчый: гел дәү әниләр. Урта буынга, яшь буынга адресланган геройлар юк, диелде. Югыйсә бит язучылар арасында яшьләр дә җитәрлек. Алар яшь кеше психологиясен яхшы белә. Ничек язарга алар өчен – бөтен алымнарын беләләр, компьютер белән үскән буын. Ләкин шунысы сәер: хикәя язган яшьләр дә ихтыяҗ булган темаларны күтәрми бит. Сәер хәл бу. Хәтта классик мирасны да кайберләре кире кага.

Разил Вәлиев: Русча яза торган татар язучылары да бар безнең. Аларның хикәяләрен дә биреп барырга кирәктер. Мәсәлән, Альбина Нурисламованың хикәясен укып чыктым. Шулкадәр кызык яза.


Андый кешеләребез, талантлы яшьләребез бик күп. Кичә генә Альбина Шаһиморатова концертында булдык. Шаккатып утырдык! 10–15 минут аягүрә басып алкышладылар! Кемнәр генә юк!.. Каян килгән аңа шулхәтле моң?! Ләкин болай итеп татар җырын бары татар гына җырлый ала. Өйрәнеп кенә түгел, күңел төбендә еллар буе җыелып яткан моң бу! Татарда бит бик әйбәт гыйбарә бар: баланың теле ачыла, диләр. Моң да шулай ук. Аны әдәбият ачарга тиеш. Иң камил татар теле элек мәчетләрдә булган. Муллаларның, мөфти, имам, хәзрәтләрнең теле сокланырлык булган. Хәзер дә кайберләрендә бар ул. Мәсәлән, Рамил хәзрәттә. Ул бит Тукайлар заманыннан килгән. Шул нәрсәне югалттык.



Ләйсән Юнысова: Әдәбиятта да үзебезне югары дәрәҗәдә күрсәтергә иде. Чыңгыз Айтматов әнә ничек үз халкын таныткан! Гади генә образлар белән яза, оста гына итеп кыргыз сүзләрен кертеп җибәрә. «Манкорт» терминын кертүе генә дә ни тора!

Ел саен татар китаплары чыгып тора. Шактый гына саннар – зарланырлык түгел, горурланырлык! Басылып тора, сатылып тора... Әмма менә нинди алар? Яшьләр ихтыяҗын канәгатьләндерәме?

Разил Вәлиев: 2015 елда 115 китап чыгачак. Күбесе, 80 проценты, татар телендә. Узган ел 145 китап басылган иде. Инфляция, кәгазь, типография бәяләре арту һәм башка сәбәпләр бар монда... Милли китапханә бер зур эш башкара: бөтен дөньядагы татар китапларын туплау белән шөгыльләнә. Америкага барып, 30 нөсхә кульязма һәм басма китаплар алып кайттылар. Алар Казанда басылган. Революциягә кадәр үк, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында. Алар шәхси китапханәләрдә булган башта. Хуҗалары күчеп киткән Кытайга, Кытайдан куылгач, Японияга киткәннәр, аннан Кореягә, Көньяк Кореядән киткәннәр Төркиягә, Төркиядән – Канадага, хәзер күчкәннәр Америкага... Китапны калдырмаганнар! Нинди авырлыклар белән, кайларда!.. Төркиядә Туфан абый белән ифтар мәҗлесендә булган идек. Төрек кешесе шундый вакыйга сөйләде. Гади мөһаҗирләр, күчкән вакытта, Кара диңгез буена килеп җиткәннәр. Көймәгә утырыр алдыннан, көймә бәләкәй, барыгыз да сыймыйсыз, ике генә төенчек алыгыз, дигәннәр. Утырганнар, төенчекләрен алганнар. Йөзеп чыккач, төенчекләрен чишеп җибәрсәләр, берсендә – самавыр, икенчесендә – китап, ди! Менә бит нинди мөнәсәбәт булган безнең халыкта телгә, китапка!

...Әңгәмә әнә шулай кызыклы, бәхәсле, җанлы үтте. Яңа эшләргә юнәлеш бирде. Мондый иҗади конкурсларны гел үткәреп торырга, хикәяләр бәйгесен киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк дигән уртак фикергә килenде. Хәерле сәгатьтә булсын!





Шаһинур МОСТАФИН
«Ядрәләрне эреткән йөрәкләр»

Танылган эзтабар язучы-архивчы һәм шагыйрь, Россия Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Шаһинур Мостафинның әлеге китабына дәһшәтле сугыш чорында, дошманның үлем уклары сибүче дзот амбразураларын күкрәкләре белән каплап, җиңүгә юл ачкан каһарманнарыбыз турында төрле елларда республикабыз һәм илебез матбугаты битләрендә дөнья күргән документаль-публицистик язмалары туплап бирелә.

Клара БУЛАТОВА
«Күрдеңме син?»

Илле елга якын яшь буынга Тукай телен өйрәткән – мөктәптә укытучы булып эшләгән, иҗаты белән әдәбият сөючеләрнең күңелен яулаган Клара Булатованың бу китабы һәрвакыттагыча көтелгән бүләк. Өстәвенә, яраткан шагыйрәбез быел Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды. Аның иҗатына бу көннәрдә – аерым игътибар. Китапка шагыйрәнең укучыларга таныш булган шигырьләре белән беррәттән, моңарчы басылмаган әсәрләре дә туплап бирелгән.

Рәдиф ГАТАШ
«Гөлтуран»

Бу китапта – Рәдиф Гаташның төрле елларда иҗат иткән шигырьләре, газәлләре, робагыйлары һәм төрки мирастан шигъри тәрҗемәләре. Гаташ – мәхәббәт шагыйре. Әмма «Гөлтуран» китабына кергән робагыйларда күтәрелгән темалар шактый төрле: милләт, милли гамь, ватанпәрвәрлек, халык, иман, намус... Әмма бу – ул мәхәббәтне урап узган дигән сүз түгел! Газәлләрендә дә мәхәббәт лирикасы төрле яклап чагыла. Гаташ беркемне дә кабатламый. Мәхәббәт хисен ул үзенчә җырлый.

Газинур МОРАТ
«Кош хокукы»

Г. Морат – үзенә генә хас шигъри алымнарга ия булган, тыгыз фикерле, серле сагыш-моң белән өртелгән, романтик рухлы, бер үк вакытта заманча публицистик яңгырашлы поэзия тарафдары. Аның шигырьләре көтелмәгән чагыштыру-метафораларга, хикмәтле, канатлы сүз булып китәрдәй тирән мәгънәле гыйбарәләргә бай булуы белән аерылып тора. Саллы сүз хикмәте, җитдилеге белән тирән, тирәнлеге белән мәгънәле иҗат галәме... Аның шигъриятенә битараф булмаганнар бик күп. «Кош хокукы» китабы – шундыйлар өчен.

Ринат МӘННАН
«Кызыл күбәләк»

Тапкыр саескан, хәйләкәр керпе, тәкәлтура, карлыгач, кырмыска, песи, күбәләк, үрдәк бәбкәләре... Ш. Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты Р. Мәннан «Кызыл күбәләк» исемле яңа китабында балаларны табигать кочагына алып чыга. Сиздермичә генә сабагын да бирә: чәчәкләр үсеп утырганда, күбәләкләр чәчкәле болында очып йөргәндә генә матур! Кызыл күбәләк сүзен ишетүче табыла – Азат та, Сара да ятьмәне кулларына башка алмый. Аларга хәзер китапны укучы сабыйлар да кушылыр...

Ленар ШӘЕХ
«Алдамыйм!»

Керпе ничек энәле булган? Ни өчен куянның колагы озын? Кайсы җәнлек кайда яши? (Аждаһаның өе кайда икәнен белмәгәнсездер әле? Әкияттә, рәсемдә!) Китапка кергән әкият-шигырьләр әнә шул хакта. Улыгыз яки кызыгыз белән табышмак әйтешеп уйнарга телисезме? Китапны гына ачыгыз! Балагызга ягымлы сүзләр өйрәтергә телисезме? Бу китапта ул сүзләрнең барысы да бар. Ә шагыйрь нәрсә турында «алдамыйм!» дип әйтә. Анысын да китапны укыгач белерсез.

ТӘЭСИР.



Рәхилә НИЗАМЕТДИНОВА, социаль хезмәткәр



Балачактан китап җене кагылган миңа, кулыма кергән китапны соңгы битенә кадәр укып чыкмыйча туктамыйм. Шул китап битендә сурәтләнгән чорларга күңелем белән кайтып сәяхәт итеп килэм... Роза Хәбибуллинаның яңа гына «таба»дан төшкән «Мулла килене» дигән китабына юлыктым менә.

...Миргаяз мулланы 1930 елда хатыны һәм өч улы белән авылларыннан удмурт җиренә, урман кисәргә сөрәләр. Хәзрәт моны Аллаһның сынавы дип кабул итә... Авылдан куылганда үзләре өчен кадерледән-кадерле ике әйберне – Коръән белән самавырны гына яшереп алып китәргә өлгерәләр: калган бөтен нәрсәләрен тартып алалар. Изге китапны Миргаяз, җанын алсалар да, бирмәячәк. Самавыр исә – дөнья яме, гаилә тоткасы: аннан башка тормышны күз алдына китереп булмый... Юк, читтә, коточкыч шыксыз урман арасында да адашмый мулла гаиләсе, әкренләп булса да тернәкләнә, аякка баса.

Татар халкының авырлыклар алдында баш имәве, чиста күңелле һәм хезмәт сөючән булуы әсәрдә бик матур итеп тасвирлана. Сугыш елларының ачы газабы, тылда калган хатын-кызлар, балаларның авыр тормышы, тырыш хезмәте бернинди үлчәүләргә салып та үлчәнә алмый. Баласын югалткан ана газабы, сөйгән ярын җуйган тол хатын, әти сүзен бер тапкыр да әйтә алмаган сабый...

Бу кичерешләр шундый нечкә итеп тасвирланган, укыганда күзләрдән яшь ага да ага.

Туган җирләреннән сөрсәләр дә, кешенең күңеленә берәү дә богау сала алмый. Миргаяз мулланың гаиләсе дә җил-давыллардан исән-имин чыга. Тамырлары тирән агачны җил ега алганы юк! 16+

Язучы, шагыйрь, драматург Ркаил Зәйдулла әсәрләрен укучылар һәрчак аерым бер кызыксыну белән көтеп ала. Аның иҗатында халык, милләт язмышын кайгырту үзенә бер кайнарлык, ихласлык, фәлсәфилек белән чагыла.
Игътибарыгызга «Татар җәмгыятендә һәм гаиләдә хатын-кызның урыны» дигән бәйгедә Ркаил Зәйдулланың беренче урынга лаек булган «Дәү-дәү әни» хикәясен тәкъдим итәбез.



Ркаил
ЗӘЙДУЛЛА

ДӘҮ-ДӘҮ ӘНИ

(Хикәя)

Кайтасы килмәгән иде Амалиянең бу авылга! Гомумән, бернинди авылга да кайтасы килмәде аның. Тик алар гаиләсендә диктатура. Авторитар режим. «Кайтасың!» – диде әтисе. Каршы килеп маташу файдасыз иде. Амалия инде белә: ирене кысылып, күзе шарланса, әтисе барыбер үз дигәнен итәчәк. «Киребеткән!» – дип, хәтта әнисе дә кулын селти аңа. Юкса кирелектә икесе бер иш. Амалия кайчакта уйлап та куя: өлкәннәрнең һәммәсе дә шундый бит! Үз сүзләре генә сүз.

Кичә генә мәктәптә кыңгырау чылтырады, бүген менә ул авылга китеп бара. «Кайтабыз», – ди әтисе. Ул кайта, әлбәттә, ул бит аның туган авылы, Амалиянең исә ул авылны күргәне юк әле. Дус кызлары белән бергә җәйгә әллә ниләр уйлап куйганнар иде югыйсә. Иң башта чиркәү янындагы җәйге мәктәпкә барасылар иде. Рухани атакай аларга инде мәктәп кирәк-яраклары да алып куйды: «Килгәч, спорт киемнәре дә бүләк итәрбез, нәфис гимнастика белән шөгыльләнерсез, – диде. – Рухи яктан да, физик яктан да сәламәт кешеләр булып үсәрсез!» Әтисе бу ниятләрнең барысын да чәлпәрәмә китерде. Башта бик нык аптырады, очкылык тота башлады. Авызыннан төкерек чәчеп, н-сс ди-ди нидер ысылдап, ишекле-түрле йөгереп алды. Аннары буасы ерылды: «Оятсызлар! – дип кычкырды ул. – Акча түләп укытабыз, ә алар шул акчага баланы чукындыра». Шакката Амалия. Әтисенең кыланмышы әнисен дә туйдырды, ахрысы, кулын гадәттәгечә күкрәгенә кушырды да торып басты, күзендәге ялкын теле керфеген көйдергәндәй булды. «Монда-а, – диде ул сузыбрак, – тавышланудан ни файда? Чебен дулап тәрәзә ватамы? Барып карадың бит шкулларына... Иле белән чукынгач, син генә нишли аласың?»

Әтисе күкрәген уа-уа аш бүлмәсенә чыгып китте. Анда нәрсәдер шылтырап алды...

Ул вакытта Амалия, мәктәптән кайткач, нигә безнең почмакта икона юк, дип, ата-анасын өнсез калдырган иде. Кызга аларның миңгерәү чырае көлке тоелды, тагын да шаккаттыру өчен ул уң кулын очындырып, маңгаена, түшенә төртенеп алды, хуплау көтеп бер әтисенә, бер әнисенә күз ташлады. Аларның телсез калуын үзенчә юрап, мактау өмет итеп елмайды:

– Молитва укып күрсәтимме?

Әнисе шаркылдап көлә башлады. Ләкин аның күзе көлми иде.

Икенче көнне әтисе мәктәпкә китте. Кызу кеше иде ул болай. Тиз кызып китә торган гадәте бар иде. Шул гадәтенә күрә тиз генә директорга кереп, мәктәптә баласын чукындыруга үзенең катгыян кире мөнәсәбәтен белдермәкче иде. Сүзләре дә тел очында: «Бездә дин дәүләттән аерылган! Сезнең хакыгыз юк!», фәлән-төгән... һәм башка шундый кискен сүзләр. Тик директорга алай ансат кына кереп булмый икән. Ишек төбендә утыручы кызыл авызлы кыз аның юлын бүлде, директорның мәшгуль икәнен әйтеп, беразга көтәргә кушты. Беразга дигәне шактый озакка сузылды, ачуы сүрелә башлаганын тоеп, Роберт Замалиевич – аны үзе эшләгән төзелеш трестында шулай олылыйлар иде! – урыныннан калкынып, ишек түрәсе кызга үзенең һәмишә монда икәнен искәртте. Тик алдындагы компьютерга кадалган кыз, авыр керфекләрен күтәрергә дә иренеп, кулын күтәреп учын гына күрсәтте. Сезнең ишеләр монда күп килә, янәсе, ә директор берәү генә. Инде канына тарала башлаган ярсуы янә утлы төергә укмашып, Роберт Замалиевич кабинетка ыргылды. Артта кызыл авызлы кызның чинап алуы ишеккә кысылып калды.

– Сез кем? – дип чәрелдәде директор ханым, чәрелдәде... олы гәүдәсенә карамастан, буш мичкә эчендә калган тычканныкыдай хәтта чинабрак чыга иде тавышы. – Сез нигә рөхсәтсез бәреп керәсез? Полиция чакыртам хәзер!

Роберт Замалиевич сүзне нидән башларга белмичә каушап калды. Үзенең биредә укучы Амалия Айзатуллованың әтисе булуын аңлатырга маташты. Аны монда чукынырга өйрәткәнсез, ә без этник мөселманнар дип бытылдады.

Ишектә ярым хәрби киемдә сакчы күренде. Директор хатын, Роберт Замалиевичның өтек-төтек сүзләренә игътибар итмәстән, шул сакчыга ябырылды:

– Син нигә мәктәпкә ят кешене керттең? Эшеңнән куам хәзер үк!

– Гафу итегез, туалетка киткән чагым иде... – Сакчы Роберт Замалиевичның җиңенә килеп ябышты.

– Позвольте...

– Не позволим! – дип чәрелдәде директор хатын. – Православие культурасын өйрәнү бездә мәҗбүри. Культураны! Аңлыйсызмы? Оныттыгызмы кайсы илдә яшәгәнне?! Әллә сез мөселман экстремистымы? Яхшы, без тиешле урынга хәбәр итәрбез.

– Мин бит... мин, – дип тотлыкты Роберт Замалиевич, – киңәшергә дип кенә... – Хәер, бу сүзләрне мәктәптән чыгып киткәч үз-үзенә пышылдады бугай ул.

Шул көннән соң мәктәпкә эзе суынды Роберт Замалиевичның.

– Каникулга чыгуга ук авылга кайтарырга кирәк Амалияне, – диде ул хатынына. – Анда әле минем әбинең әнисе дә исән, мулла булып йөри, бисмилла булса да өйрәтер кызга.

Моңарчы авылны өнәп бетермәгән хатыны да иренә каршы төшмәде.

– Кайтсын шул, – диде. – Анда сөт-катык... башкасы. Барысы да натуральный.

Авыл Алатыр шәһәреннән әллә ни ерак түгел иде. Ике йөз чакрымнар булыр. Тик кендек күптән өзелгән, хатыны да шәһәрдән булгач, Роберт Замалиевич анда урык-сурык кына кайткалап китә, җәйге елларда алар йә Анталиягә, йә якын-тирәдәге шифаханәгә баралар. Тормышлары шулай бер көйдә иде. Менә бит... авыл искә төште. Роберт Замалиевич та, институтта укытып йөргән Луиза Маратовна да, әлбәттә, моңарчы үзләренең нинди диндә булулары турында уйланганнары юк иде. Әлепне таяк дип тә белмәгән килеш ничек уйланасың? Ләкин күз алдында бердәнбер баланы чукындырганда кайдадыр эчтә ниндидер кыл сискәнеп куйды. Бигрәк тә Роберт Замалиевич... Ул мәктәптән кайтканнан соң төне буе йоклый алмады. Таң алдыннан төш күрде: зират капкасының баганасына сөялеп, мәрхүм әтисе елап тора иде...

Амалия, иреннәрен кысып, әнисе белән салкын гына саубуллашты. Үзе шәһәрдә калды әнә, ә кызын – сөргенгә... Әтисе инде машинасын кабызган иде. Алатырдан чыккач, әтисе дә иркенлекне тансыклык авылларны узып, машина алга очты.

– Синең өчен бөтенләй яңа дөнья анда, – дип әтисе кызын юатырга маташса да, Амалия аны инде ишетми, йокыга оеган иде. Авылга килеп җиткәнен ул сизми дә калды.

Шифер түбәле тәбәнәк кенә өйдән ике әби ашыгып чыкты. Яшьрәге Амалиянең әтисен кочаклап алды.

– Руберт, кайттыңмы, таем!

Олырак карчык Амалияне җитәкләп алды, йомшак кына аркасыннан какты:

– Менә бит нибәрәбез дә кайткан, Алланың хикмәте. Киленнең быел да эше тыгыздыр инде...

Шаулашып өйгә керделәр.

– Дәү әби кайда соң? – дип, әтисе як-якка карады.

– Гөлҗиан әптәйнең килене ир олан тапкан. Шуңа исем кушарга китте анай, – диде олырак карчык. – Самавыр кайнаганчы кайтып җитәр. Әле торасыздыр бит?

– Иртәгә миңа эшкә. Бүген китәргә кирәк. Амалияне генә кайтардым. Ялга чыккач, иркенләп кайтырмын әле.

– Син шулай әйтәсең дә... – Яшьрәк әби күзен сөртеп алды. Амалия аны әтисенең әнисе дип юрады.

– Кызыңны апкайтуың яхшы булган, үзең дә беләсең, җәй көне бездә җан рәхәте. Тиздән җиләкләр өлгерер. – Олы әби елмайды. – Тик анай аны бездән тартып алыр инде.

– Барыгызга да җитәр, – дип әнисе белән әбисен юатты Руберт, үзе берни дә аңламыйча күзен тасрайтып утырган кызының, сөеп, чәченнән сыйпады. Самавырны өстәлгә куйдылар, куертылган каймак, сөт-катык, бал, бавырсаклар килде. Тик әбиләр самавырны борчырга ашыкмады. Кунак мәгънәле итеп сәгатенә дә караштырып алды.

– Хәзер кайтып җитә ул. Аңардан башка ризыклану килешмәс.

– Белә-әм...

Капка шыгырдаганы ишетелде. Амалия җитез гәүдәле берәүнең ишегалдыннан үткәнен күреп калды. Шул мизгелдә үк ул ишектән дә килеп керде. Барысы да урыныннан торды. Амалия дә калкынды. «Директор» монда шушы әби икән дип уйлады. Бу әби өйдәге ике әбидән аерылып тора, өлкән булса да – юкса болары сикереп тормаслар иде! – күзе җемелди, җиңел сөякле, йөзе дә тәбикмәк сыман – бер җыерчык эзе күренми.

– Кемнәр, кемнәр ка-айткан... – дип көйләп сөйлисөйли ул түргә үтте, андагы – күрәсең, аның өчен! – буш торган көрпә салган урындыкка утырды, ике учын йөзенә китерде, шактый гына озак мыдырдаганнан соң,«Аллаһ әкбәр!» дип битен сыпырды. Үзен гаҗәпләнеп күзәткән Амалиягә күз ташлап, торынына борылды:

– Руберт улым, кызың амин тота белми мәллә?

– Менә өйрәнергә кайтты бит инде, – дип кызганыч елмайды торын.

– Ярар, ярар, яхшы булган, соң түгел әле. Әйдәгез, чәйдән житешегез.

Амалия сизмичә дә калган, чынаякларда инде чәй тутырык, бер әби аңа бавырсак салып маташа.

– Бездә шулай эчәләр, – диде әтисе.

Сездә эчсәләр соң... Амалия иренен турсайтты, чәйгә ирен тигерергә уйламады да. Башын күтәреп караса, «директор» әбинең күзе аңарда! Амалия ашыгып чәйгә иелде.

– Амилә кызыма бал ерак, – диде «директор», ике әби, каударланып, кыз каршына бал савытын шудырдылар. «Бик матур исем – Амилә», – диештеләр.

– Әле Гөлҗиан килене тапкан малайга Абдрахман дип кушып кайттым, анасы күзен терәп, Артурмы, Амурмы дип тик тора, адәм ыстрамы. Нишләп мин үз балама үзем исем куша алмыйм, беля-ясызмы, мин аны ниччек авырттырып тудырдым, ди бит әле, миңгерәү. Тилибизыр карап азынганнар. Ничауа, тәртип урнаштырып киләм инде. – Ул торынына карап елмайды. – Миңа кадәрге мулла бик йомшак иде. Халаякка тәртип куялмады.

– Хатын-кызга мулла булырга ярыймы?

– Нишлисең инде, – дип, иңен сикертте кортка, – безнең картларның җыенысыннан бер чырапычак чыкмый. Әлепне таяк дип белмиләр. Урыс арасы бит, бернишләп булмый.

– Авыр түгелме соң бу яшьтә?

– Яшемә ни булган? Аллага шөкер. Яшьләргә биргесез әле мин! – Ул янәшәсендәге әбиләргә карап алды. Тегеләре аны җөпләп ияк какты. – Шушы җәйдә йөз тирәсе була, әлхәмделиллаһи...

Ул мут кына каш сикертте.

– Бәрәкалла! – диештеләр әбиләр.

– Зур юбилей бит бу! Зурлап үткәрергә дә кирәк, – диде кунак. Блокнотына нидер язып та куйды.

– Авыр инде, авыр булмыйча соң. – Карчык торынының соравын онытмаган иде. – Тик хак юлга чыксаң, Алла ярдәм бирә ул.

Чәйдән соң әтисе китәргә җыенды.

– Ярар, кызым, сау бул, абикаларыңның сүзен тыңла.

– Нинди абика булыйм әле мин? – дип Рубертның әнисе ризасызлык белдерде. – Миңа дәү әни дисен!

– Миңа әбекәй дисә дә ярый, бик күркәм сүз, – диде уртача карчык.

– Ә миңа ярамый, – дип кинәт киреләнде «мулла» әби. – Миңа Амилә дәү-дәү әни дип эндәшсен! Пуняла, мин – дәү-дәү әни!

– Поняла, – диде Амалия... юк ла, Амилә!

Әтисе китте. Амилә калды. Бернишләп тә булмый!

Иртәгәсен дәү-дәү әнисе аны таң белән уятты. Кызның торасы килмәде, әлбәттә. Каникулда да рәхәтләнеп йокламагач! Тибенеп тә карады, тырнарга да маташты, шулай чәбәләнә торгач, йокысы качты.

– Йокы чүлмәге булмыйлар алай, – дип сөйләнде дәү-дәү әнисе. – Кояш чыкканда йоклап ятсаң, беләсеңме ни була? – Ул кызның колагына иелде. – ... йон чыкмый кала!

Кыз, әйе, Амилә, урыныннан корт чаккандай сикереп торды. Дәү-дәү әни нибәрәсен кочаклап алды.

– Үсеп беткәнсең бит инде, йөрәк маем, күкрәгең дә әнә бөреләнеп килә. Бераздан, һии...

Ул аны ашыктыра-ашыктыра, кыстый-кыстый чәй эчерде. Үзе һич тынмыйча сөйләнә иде. Амилә инде аны аңлый да башлады сыман. Сүз сөрешен чамалый кебек иде ул аның. Тик әле авыз күтәреп кушыла гына алмый.

– Хәзер урманга барабыз, – диде дәү-дәү әнисе. – Урман, пуняла?

– Поняла, – диде Амилә.

– Әнә ул урман, авыл өстенә егылырга тора. Шунда бармыйча авылда яталармы, юләр? Өйдә, шәһәрдәге кебек, үз исеңне иснәп...

Чыннан да, урман авылга ерак түгел икән. Һавасын сулагач, Амиләнең башы әйләнеп китте. Чәчәкле аланга килеп чыктылар. Дәү-дәү әнисе иелеп үлән чемли башлады.



Рәсем: Наталья Васильева

– Менә кузгалак, мәле-мәле, ашап кара әле... Тәмлеме? Һи, сез аның тәмен беләсезмени... Төкермә, юләр... Менә монысы юа... Йәле-йәле, кыр суганы да диләр аны.

Дәү-дәү әни артыннан йөри-йөри Амилә тәмам арыды, аяклары сыдырылды, черки талады.

– Бераз тамак ялгап алыйк, – дип, дәү-дәү әнисе төенчегеннән ипи телемнәре, ике пешкән бәрәңге, ике йомырка чыгарды. Андый тәмле ризыкларны Амиләнең беркайчан да ашап караганы юк иде! Тамак ялгаганнан соң ял итеп алдылар. Күк йөзе шундый тирән һәм серле иде. Болытта гына йөзеп, ак сакаллы Алла бабай килеп чыгар кебек. Дәү-дәү әнисенең Алла бабайны күргәне бар микән? Күрсә дә күргәндер, ул бит үзе дә бик карт икән, йөзгә җиттем, диме... Алланың улын да беләдер әле.

– Алла ул берәү генә, аның улы да юк, хатыны да. – Әллә Амиләнең уен укый инде ул? – Ул бит кеше түгел үрчергә. – Дәү-дәү әнисе торып басты, җыйган үләннәрен икегә аерып бәйләде. Кечкенәрәк бәйләмне Амиләнең җилкәсенә салды, зурысын үзе күтәрде. – Кайтыйк булмаса. Югалтканнардыр. Әле Хәйрүшләргә ашка барасы да бар.

Кайтуларына капка төбендә озын буйлы, ябык бер ир-ат көтеп тора. Ул тәмәке тарта иде, ахрысы. Урманчы әби белән кызны күргәч, тәмәкесен каядыр яшерде.

– Нигә көттерәсез инде, муллаттәй, кунаклар күптән җыелды, Коръән укыргае, – дип каршы алды ул аларны. Үзе озын булса да, тавышы шактый сыек чыкты.

– Бар әле, монда моңаеп торма, кайта тор, менә нибәрәбез белән бик тиз килеп җитәрбез.

– Беләбез инде сезнең тиз дигәнне, – дип зарлана-зарлана, чакыра килгән адәм китеп барды.

– Үзегез укый белсәгез, көтмәс идегез! – дип әйтеп калды дәү-дәү әнисе аның артыннан.

Алай да бик кичекмәделәр, җәһәт кенә юынып, чиста киемнәрен киделәр дә мәҗлескә ашыктылар. Дәү-дәү әни Амиләне янәшәсенә түргә утыртты. Өстәлдәге ризыклар әле юка япма белән капланган; муллаттәй каршына нәни савыт белән тоз куйдылар. Ул җайлап утырды да, тамагын кыргалап торгач, дога укый башлады: Әгузу билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рәхииим... Амилә табын тирәсенә җыелган карт-корыга карады. Нигәдер монда барысы да ирләр, хатын-кызлар мәҗлесенә муллаттәйне кабат чакырасылар, имеш. Дәү-дәү әнисенә кара син, бер карт әби генә бит югыйсә, ә үзеннән ничек шүрләп торалар. Хөрмәт итәләр.

Әнә бит ул нинди кибарәнә, ничекләр матур итеп борын эченнән суза: Әл-хәмдү лилләәһи раббилгааләмииин...

Амилә дәү-дәү әнисенә ияреп җәй дәвамында шундый мәҗлесләргә еш йөрде. Ул моңа шундый күнекте, мәҗлес озаграк булмый торса, күңеле нык төшә иде. Сыйланып йөрү, матур сүзләр ишетү җанга сары май булып ятса, сәдака өләшүләре дә ошый иде Амиләгә. Муллаттәй белән янәшә утырган шәкерт кызга агайлар яхшы ук тамыза, әбекәе махсус тегеп биргән янчыгы тулып килә иде инде кунак кызның.

Беркөнне төш вакытларында алар өенә өч ир-ат килеп керде. Карчыклар шактый ук шомландылар да бугай. Нигә халыкка әфьюн таратасың, дип, элекке замандагы кебек алып китсәләр? Аллам сакласын, булыр да...

– Айнизямал Мухаметзяновна здесь проживает?

– Амиләне качыр! – дип кычкырды әбекәй. Аның кычкыруында да мантыйк бар, бу вакытта инде Амилә «Колһуалла»ны өйрәнеп җиткән иде.

Бераздан аңлашылды, район үзәгеннән үк дәү-дәү әнине йөз яше белән котларга килгәннәр икән. Түшенә «Йөз яшь!» дигән медаль дә тактылар. «Алатырдан сезнең өчен махсус ясатып кайтарттык», – диде башлыклары депутат. Берсе медаль такканны черт-черт сурәткә төшерде. Гәҗиткә чыгарабыз, диделәр. Карчыкларның аңа исләре китмәде, авылда гәҗит алучы кеше юк иде. Озак тоткарланмады чакырылмаган кунаклар, саулык-сәламәтлек, озын гомер теләп чыгып киттеләр. Дәү-дәү әни тагын нәрсәгәдер өметләнгән иде дә... нишлисең, медаль дә бүләк. Ак яулыгына төреп, сандыгына салып куйды.

Амилә авылдан китмәскә булды. Шәһәргә кунакка гына баргалап килер ул, әлбәттә. Әти-әнисен күреп... Тик кеше исәпли, тәкъдир хисаплый, диләр шул... Август аеның соңгы көннәре иде. Әтисе иртәгә кайтасын белдереп, телефоннан шалтыратты. Өч карчык та, тыз-быз килеп, кунак каршыларга әзерләнә башлады. Дәү-дәү әнисе йомыркалар алырга дип кетәклеккә менеп киткән иде. Шунда баскыч әйләнеп киткән дә... Дәү әнисе белән әбекәе аны, мыш-мыш килеп көчәнеп, өйгә алып кереп караватына салдылар. Амилә дә булышты. Дөресен әйткәндә, дәү-дәү әни авыр түгел иде. Җиңел иде ул. Ыңгырашмады, тып-тын гына ятты. Амилә аның чатнаган иреннәренә юеш сөлге тидереп, янәшәсендә утырды. Ул аны үләр дип уйламады да. Аның дәү-дәү әнисе бит ул! Үлемне күз алдына китерә алмый иде Амилә.

Икенче көнне әтисе кайтып җитте. Ул Амиләне алырга кайткан иде. Дәү-дәү әнинең урында ятканын күреп бик пошынды. Нишләргә белми өйдә ары-бире йөренде. Өмет юк... өмет юк. Аны мондый хәлдә ташлап китәргә дә әллә ничек... Нишләргә?

Дәү-дәү әни аның гасабилануын аңлады, әлбәттә. Ишарәләп янына чакырды.

– Алып кит Амиләне, – диде ул газаптан чәрдәкләнгән авазларны өзек-өзек чыгарып. – Бәхил булыгыз.

– Торыйк әле бераз, – дигән булды әтисе.

– Әле мин берничә көн җәфаланам. Көтмә. Амиләнең исендә исән килеш калыйм.

– Тереләсең әле син, дәү әни. Моңарчы үлмәгәнне...

Дәү-дәү әни елмайган кебек булды.

– Сандыктан... мидалны... – Килене зур сандыкны ачып, теге депутат абый алып килгән медальне алып килде.

– Амилә, – диде дәү-дәү әнисе. – Менә бу сиңа...

Амилә медальне учына йомарлады.

– Йөз яшеңә җиткәч, син дә аны нибәрәңә бирерсең.

Машина моңаеп торган ташландык авылларны узып, киң кырлар аша Алатырга ашыкты. Әтисе: «Амалия, Амалия», – дип эндәшеп караган иде дә, кыз, йоклаганга сабышып, җавап бирмәде. Сөйләшәсе килми иде аның. Күңелен дәү-дәү әнисе турында уйлар биләп алган иде. Ничек икән аның хәле? Тиздән Аллаһы Тәгаләгә нәрсә әйтер икән дәү-дәү әнисе? Амилә турында берәр сүз кыстырыр микән? Ул елмаеп куйды. Әллә ул дәү-дәү әнисен белмиме? Кыстыру гына түгел, авыз тутырып әйтер: Амилә бик тәрбияле, тәртипле кыз, дияр. Синең бер һәм бердәнбер булуыңа ышана ул, дип тә өстәр.



Асия
ГАЛИУЛЛИНА

БӨЕК ЖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН ХАТЛАРНЫ БИРӘ БАШЛАДЫК... ВАКЫТ ШАУКЫМЫ ЭЗ САЛГАН ХАТЛАР, САНДЫКЛАРДАН ЧЫГЫП, РЕДАКЦИЯГӘ АГЫЛА БАШЛАДЫ. САКЛАГАННАР БИТ!

САНДЫКТАГЫ ХАТЛАР

Безнең өйдә дә бар иде шундый бер сандык. Келтерәп ачыла торган йозаклы, тимер коршаулы сандык. Аның өстендә кунаклар килгәндә генә кузгатыла торган түшәк-ястык өелеп тора. Сандыкның бөтен сагы шул түшәкләр. Сандык капкачының киереп ачып куелган чагын бер дә белмим. Һәрхәлдә, бер төнгә кадәр.

Бер җәйге төндә Түбән очта янгын чыкты. Капка төбенә чыгып бастык. Зур авылның икенче очындагы янгын кара төндә бигрәкләр дәһшәтле күренә. Авылның ул башы, дөрли-дөрли, утка кереп бара сыман. Миңа алты яшьләр булгандыр. Шул чагында йөрәгем алынып курыкканымны хәтерлим. Олыларның куркышуы миңа да йоккандыр инде. Алар бит, әнә, минем кебек канлы ялкын шәүләсен күзәтеп, тик кенә тормыйлар. Ыгы-зыгы киләләр. «Җил шул яктан!» – аларны шул җил хафага сала. Тимер коршаулы сандыкны, баш-башындагы колакларыннан тотып, таш келәткә чыгарып куйгач, олылар да сабырлана төште. Димәк, иң кыйммәтле хәзинә сандыкта, һәм ул ышанычлы урында!

Янгын онытылгач, сандык янәдән үз урынына кереп утырды. Кабат өстенә түшәкләр өелде.

...Ун-унике яшьләргә өйдә нәрсәнең кайда торырга тиешлеген олылардан артык «белә» торган бәләкәй «хуҗәйкә» булып җитешкән идем инде мин. Беркөнне теге тимерле сандыкка да чират җитте. Кадерледән-кадерле ни-нәрсә бар икән соң аның эчендә? Ачтым мин бу тимерле сандыкны! Иң өстә әбиемә әнисеннән калган «Кузнецов тәлинкәсе» ята. Читкә алып куйдым. Бер кырыйда саргайган кәгазь



төргәге күреп алдым. Аны сүттем. Чәч толымы! Унсигез яшендә тылдагы авыр хезмәттән өзлегеп, гүр иясе булган Мәрхәбә түткәйнең толымы бу. Тагынниләр бар? Әһә, монысы күлмәк! Күлмәк! Әниемнеке!

Тагын бер төргәк! Монысында әниемә ак күлмәкне кигерткән Гасыйм Зәкиевнең сугыштан язган хатлары булып чыкты. Өчпочмаклы «кош телләрен» сүтеп, сандык янына чүгәләгән килеш укыдым мин ул хатларны. Сталинград сугышында солдатның гомере уртача 24 сәгать саналган. Яшь хатынын һәм сугыш башланган көнне туган нәни кызын калдырып, ут эченә киткән политрукның исеме – Мамай курганындагы Мемориалда.

Мин әле бәләкәй идем, әмма хат эченнән түгелгән ягымлы сүзләрнең җылысын, бомбалар яңгырын аралап килгән «якыным» дип эндәшүнең кыйммәтен аңларлык яшьтә идем.

Редакциягә юлланган хатларга сеңеп калган иксез-чиксез наз да сискәндерде мине. Югыйсә Бразилия сериалларын карый-карый шомарган, хисләр тыйнаклыгы качкан ир-егетләр түгел бит хат авторлары. Гомернең һәр мизгеле санаулы икәнлеген сизеп-тоеп тору күңелнең иң нечкә кылларын кузгаткандыр. Тыныч заманда күңел сандыгына тирән яшерелгән иркә хисләрне, назлы сүзләрне, сугышка кергәндә, үкенечкә калдырмый, әйтеп өлгерергә кирәклеген аңлаган инде алар. Ярата белгәннәр дә соң татар авылының садә егетләре! Саргайган, уалырга торган хатлардан менә инде җитмеш елдан артык наз агыла.

Әтнә районының Яңа Бәрәзә авылыннан Шиһабетдинова Радалия ханымны да редакциягә сандыктан табылган хатлардагы соклангыч матур сүзләр китергән. «Кайнанам Гөлбаһарның сугышта хәбәрсез югалган беренче ире – Яңа Бәрәзә мәктәбе директоры булып эшләгән җирдән сугышка киткән Сәлах Хисамов хатлары болар, – дип башлады ул сүзен. – Бу хатларны сандыктан алып укыр бер кешесе дә юк аларның хәзер. Мин генә, хатларны укыйм-укыйм да, елыйм. Нинди олы мәхәббәт булган Сәлах белән Гөлбаһар арасында. Нинди матур кешеләр яшәгән безнең Яңа Бәрәзә авылында. Менә фоторәсемнәрен дә алып килдем».

Бер төпкә төпләнгән, һәр хаты номерланган саргайган битләрне укырга тырышып актарабыз. «Гөлбаһар бәгърем», «Сөйкемле иркәм», «Сөекле тормыш гөлем», «Сандугачым», «Куанычым» дип башланган хат араларына бинихая наз һәм сагыну сыйган!

Бу сугыш ничәмә-ничә матур мәхәббәтнең йолдызын, гаилә учагын сүндергән, мәхәббәт белән кавышкан ярлардан күпме бала тумый калган. Сугыш касәфәте белән татар авылының матур, гыйффәтле, гыйрфанлы мәгыйшәте, Атлантида сыман, төпкә киткән. Нинди үкенечле, йөрәкләрне әрнетә торган бәйрәм бу! Кыйммәткә төшкән Җиңү бәйрәме!



Беренче мәхәббәт

Җыйнап сугыш серен,
Мәңгелек ут сөйли,
Сүзсез сөйли тарих ялкыны:
Исән калды микән,
Дөрләп янды микән
Ап-ак шәлен япкан яу кызы,
Алтын йолдыз таккан
таң кызы?

Чәчләрдәге бәсләр,
Күзләрдәге яшьләр
Югалганнар, өмет өзмим мин.
Утлы юллар узган,
Таң нурыдай кызлар,
Яз җилләре иссә, түзмим мин,
Чәчәкләрдән сезне эзлим мин.

Мәңгелек ут дөрли.
Кояш җиргә сөйли.
Шәһит дөнья яман ярсулы.
Бәхет өмет иткән,
Туйлар вәгъдә иткән,
Хыялдагы туйны
күрми киткән –
Мәңгелек ут – җаннар ярсуы.

Мансур
ШИҺАПОВ

«МӘҢГЕЛЕК УТ»

Ямьле май аеның беренче көнендә миңа 75 яшь тулды. Гомер юлымны барлыйм да үткән юлыма багам. Анда якты маяклар булып минем җырларым тезелеп киткән икән ләбаса. Дөрес, гомер җырлап кына узылмады. Әмма җырлар белән юандым мин. Үземне юатырга язган җырларым халкым йөрәгенә дә үтеп керә алды. Миннән еш кына, теге яки бу җырыңны язу өчен нәрсә сәбәп булды, дип сорыйлар. Чыннан да, бер сәбәпсез җил дә исми. Хатирәләремне кузгату өчен «Җыр дәфтәре»мне тәүге битеннән актара башлыйм әле.

Кешеләр йөрәгенә, бигрәк тә татар кешесе йөрәгенә юл яра торган җырларның моңлы, сагышлы булырга тиешлеген төшенгән идем инде мин. Сугыштан соңгы елларда «Сагыну», «Юксыну» кебек җырлар җырланды. Тормыш җай гына барганда сагышланмыйсың әле ул. Алай да җыр язып карарга теләк бар иде. Бу теләкне күрше генә яшәгән композитор Сара Садыйкова һәрдаим кымтырыклап торды. Минем әнием Нәфисә янына сирәк-мирәк чәй эчәргә кергәндә гел әйтә бу: «Мансур, минем яныма Гомәр килеп йөри, Сибгат килә. Нәби Дәүли керә. Бөтенесе җыр яздыралар. Син кермисең. Аның каруы, сезгә мин үзем кереп торам. Яз инде матур сүзләр, көен үзем иҗат итәрмен. Илһам яза башлагач килә ул. Менә син туган авылыңа кайт. Елгагыз булмаса, инешегез бардыр. Төшеп утыр күпер төбенә. Тыңла су агышын. Төне буе утыр. Иртәнгә, мөгаен, җыр туар».

Сара ханым кебек кешенең киңәшен ничек тыңламыйсың. Кайттым Яншыкка, төштем күпер

төбенә. «Җил белән серләшкән каеннар», «ак шәлен ябынган шомыртлар» турындагы «Яшьлегем эзләре» җырының сүзләре шулай туды. Бирдем күпер астында туган шигырьне Сара ханымга. Бер атна, ике атна көтеп йөрим. Бер тапкыр хәтта туктатып сорадым да. Янәсе, җыр өлгердеме әле? «Өлгерде, өлгерде. Мендәр астында гына ята», – булды җавап. Бу аның җырны уемда йөртәм дигәне икән. Җыр Нәфисә Василова җырлавында юл ярды. Мәрхүм дустым Мөхәммәт Мәһдиев бу җырдан тәкатьсез була торган иде. Халык йөрәгеннән килгән авазларны табу шул була торгандыр инде ул.

Җыр язып караган бар хәзер. Инде «Хәзинә» (Г. Ахунов) романы буенча куелган спектакль өчен җыр кирәк булгач, кыюланып тотындым. Бу юлы «Туй күлмәге» җыры язылды. Көен Мәсгут Имашев язган бу җырны иң беренче булып Тинчурин театры артисткасы Ләлә Миңнуллина җырлаган иде. Люция Хәсәнова, Нәзифә Кадыйровалар аны бик теләп репертуарларына алдылар. Яшермим, халык та бик яратты.

Шуңа сөенәм – минем җырларны зур җырчылар җырладылар. Әйтик менә, көен Рим Хәсәнов язган «Әйләнеп кайтыгыз»ны иң беренче булып Хәйдәр Бигичев җырлады, Асаф Вәлиев популяр итте.

Сара Садыйкованың кулы җиңел булып чыкты. Минем иҗатны Сафьян Ибраһимов, Фәрит Хатипов, Зөфәр Хәйретдинов кебек композиторлар да күрә башладылар. Инде үзем дә җыр язарга гына торам. Берчак шулай спектакль өчен сугыш темасына җыр кирәк булды. Алындым мин моңа. Горький исемендәге парк каршындагы мәңгелек ут тирәсендә ике атналап йөрдем. Балачак хатирәләре уянды. Түшенә – берсе «Ленинград оборонасы өчен», икенчесе «Сталинград оборонасы өчен» дигән ике медаль тагып, 1945 елны – миңа биш яшь тулганда сугыштан кайтып кергән, берничә елдан, яраларыннан мантый алмыйча, бакыйлыкка күченгән әти искә төште. Ике иң каты сугышны кичкән булган икән ләбаса әти. Суслонгерын да санасаң... Без аңардан җиде бала калдык.

Образ һаман тумый да тумый. Вариантлар бар – җыр юк!

Бервакыт театр белән Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылына барган идек. Мин Марганова Василиса Максимовналарга фатир төштем. Гаҗәеп чибәр, мөлаем апа иде ул. Кием шкафы ачылып киткәндә түше тулы медальле пинҗәк күреп калдым. «Иреңнекеме?» – дип сорадым. «Юк, үземнеке!» – диде апам. Керәшен кызы Василиса 1940 елда Чистай медицина училищесын тәмамлаганнан соң, Актаныш районының Суыксу участок хастаханәсенә җибәрелгән. 18 яшендә сугышка алынган. Сугышчан юлын Орел өлкәсенең Здынка авылында торган эвакогоспитальдә башлаган кыз Җиңү көнен Польшада, Познань шәһәрендә каршылаган. Сугыштан соң Кызыл Йолдыз районының Биектау авылындагы балалар йортына килеп эшкә урнаша ул. Аннары Котлы Бөкәш хастаханәсендә эшли. Үзе кебек сугышлар кичкән Марганов Алексейга кияүгә чыгып, бер малай, бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Кызлары Роза Алексеевна Вәлиева – педагогика фәннәре докторы, профессор, уллары Геннадий – инженер. Василиса Максимовна әле дә исән-сау. Кышын – Казанда, җәйләрен Котлы Бөкәштә яши.

Шул апаны күргәннән соң, сугыш юлында кичергәннәрен сөйләткәннән соң, нәрсә хакында язасымны тәгаен белә идем инде. Унсигез яшьтә ут эченә кереп исән калган, дүрт ел ут эчендә ир-ат арасында йөреп тә сафлыгын җуймаган татар кызын данларга тиеш мин! Сүзләрне гастрольдән кайтуга ук яздым да композитор Рәшит Гобәйдуллинга бирдем. «Мәңгелек ут» дигән бу җырны Вафирә Гыйззәтуллина тетрәндерерлек итеп башкарды. Сагындыра аның җырлавы. Кызганыч, хәзер аны сирәк яңгыраталар. Ә бит башка җырларым беренче җырлаучылар бакыйлыкка күчкәч тә югалып калмады. Әле берсе, әле икенчесе «әйләнеп кайта». Бөек Җиңү хөрмәтенә «Мәңгелек ут» та кабат дөрләп китмәсме дип өметләнәм.




Василиса Максимовнаның фоторәсемен күргәч, редакциядә аһ иттек. Мансур Шиһаповның ни өчен илһамланып китүен бик тиз аңладык. Вакыт сынаулары да аның матурлыгын җуймаган. Әле яшь вакытта нинди чибәр булгандыр ул! Бу тиклем дә мөлаем, сөйкемле кыз баланы кемнәр, ничекләр итеп утлы өермәгә – сугыш уртасына ыргытырга базды икән? Тиешләр күп, язмыш бер генә. Матур картлыгын кичереп, кызы янында яшәп ятучы Василиса Максимовна язмышына үпкәле түгел. Тәмам картайганчы өлешен даулап, биек ишекләрне кагып йөрмәгән ул. Гаделлек аны үзе эзләп тапкан. Президент үз янына чакырып, фатир ачкычы тоттыргач, әлбәттә, сөенә. Анда да тыйнак кына итеп, дәрәҗәсен белеп кенә. Бөтен уңайлыклары булган дүрт бүлмәле фатирда үз бүлмәсе булса да, күңеле һәр яз саен авылына ашкына. «Тагын күпме язларны-җәйләрне авылда үткәрә алырмын – белгән юк. Аягымда йөри алганда кайтам әле». Капка төбенә азга гына чыккан арада да ничә кеше: «Нихәл, Василиса түти», – дип үтеп китә. Ул Котлы Бөкәшнең һәр кешесе өчен кадерле, үз агъэбиләре. Һәммә кеше аңа озын гомер, имин көннәр тели. «Тазалык та, иминлек тә барыбызга да кирәк. Илебез бәхетле булсын, яшь кызлар шинель кимәсен», – дип тели ул.

«Өеңдә ни барын күршеңнән сора! Синең хәл-әхвәлеңне күршең, кайчак, үзеңнән яхшырак белә», диләрме әле?! Бу йөремсәк мәзәкнең кинәт искә төшүенә сәерсенмә, укучым, «Сөембикә»нең күз уңыннан читтә калу ихтималы булган хәл-вакыйгаларны авторларыбыз, абунәчеләребез хәтергә төшерә икән... бер дә гаҗәп түгел, сөенеч кенә бит бу! Күңел офыкларын киңәйтә торган шундый бер язма күптән түгел безгә Үзбәкстаннан килеп төште. Ташкентта яшәүче милләттәшебез – туган якны, халкыбызның олуг шәхесләрен, аларның иҗатын, тормыш юлын өйрәнүне намус эше санаучы милләтпәрвәр Рафаэль Хәсән улы ЗАРИПОВ-КИЛЬМЕТОВ язмасындагы гаҗәеп кызыклы бер истәлек шунда ук игътибарны җәлеп итте.



Роза КАМАЛЕТДИНОВА



«КӘЛӘШ» ЯКИ БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Рафаэль әфәнде тарихка кагылышлы фотосурәтләр, танылган татарларның революциягә кадәр үк төшкән рәсемнәрен җыю белән яшь чагыннан ук мавыга икән. «1992 елда Казанга килгәч, фотосурәтләремнең күчермәләрен Г. Ибраһимов исемендәге тарих, тел һәм әдәбият институты архивына тапшырмакчы булдым, – дип яза ул. – Һәм мин аларны Марсель Әхмәтҗановка күрсәттем. Фотосурәтләр арасында Мәхмүд мирза Терегулов рәсемен күреп алды галим. Аларның Казандагы туганнары – Хәлимә Ибраһим кызы Булатова-Терегулова белән очраштырырга вәгъдә бирде.

Хәлимә ханым безне ачык йөз, такта чәй, тәмле бәлешләр белән каршы алды. Бераздан Марсель аганы кайсыдыр редакциягә телефоннан чакырып алдылар, ә хуҗабикә белән, тарих төпкелләренә төшә-төшә, без әле бик озак сөйләшеп утырдык. Сүз ара сүз чыгып, ул миннән: «Ташкенттагы сәнгать музеенда «Татар кызы портреты»на игътибар иткәнегез булмадымы?» – дип сорап куйды. Әлбәттә, ул картинаны күргәнем бар! Бер генә дә түгел, озак-озак карап торганымны сөйләдем».

«Глядя на Халиму Ибрагимовну, я подумал – а ведь передо мной сидит «оригинал» картины Бенькова «Обрученная невеста» – княжна Терегулова... Картина тиражирована на почтовых открытках СССР. На них она – «невеста» ушедшего века», – дип укыйм. Картинаның исемен «Ярәшелгән кәләш» дип

тәрҗемә итәргәме? Сәеррәк яңгырый. «Кыз елату» йолалары искә төшә. Сурәттәге «кәләш»нең моңсу күз карашы үзәк-бәгырьләргә үтәрлек... Ә кием-салымы затлы. «Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Павел Беньков «Татар кызы портреты»н язганда, әңгәмәдәшем аңа образ тудыруда ярдәм иткән – рәссамга өлге булган икән. Терегуловлар гаиләсенең дусты Павел Петрович Хәлимәнең рәсемен әнисе белән бергә ясарга уйлаган, әмма Гайшә ханым авырып китә. Рәссам күптән язарга хыялланган картинасына Хәлимә туташның санәм – өлге булуын үтенә. Хәлимә апа: «Әгәр Ташкент рәссамнарының берәрсе шул картинаның күчермәсен ясап җибәрә алса, мин бик шат булыр идем...» – дигән теләк тә белдергән иде. Әмма, ни аяныч, сөйләшкәләп карасам да, аның үтенечен тормышка ашырырлык рәссам табылмады. Беньков үз иҗатында шәрык халыкларының үзенчәлеген, бигрәк тә татарлар тормышын чагылдырырга яраткан. «Йөк ташучы татар», «Галимҗан Ибраһимов» кебек әсәрләре – моның ачык мисалы. 1926 елда татар театры «Зәңгәр шәл» спектаклен сәхнәгә куйганда аны бизәүче рәссам итеп чакыралар. Сәхнәдән төшми уйнала торган әсәрнең бер вариантын Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев белән бергә иҗат иткән рәссам да әле ул».

Табигый ки, мин дә рәссамның «Татар кызы портреты» турында тулырак мәгълүмат эзләргә тотынам. Ләкин Татарстан рәссамнарына багышланган җыентыкта Николай Фешин белән бергә Павел Беньковның да Казандагы Сәнгать училищесында укыган рәссамнарга остазукытучы булуы хакында бер-ике саран җөмлә генә очратып була. Әле дә ярый дөньяда интернет дигән хикмәт бар! Павел Петрович Беньков 1879 елда Казанда туа. Санкт-Петербургта сәнгать академиясен тәмамлый. Парижда укуын дәвам итә, осталыгын чарлый. Аның егерме еллык иҗат гомере Казан белән бәйле. «1928 елда ул Бохарага китә. Кояш, андагы иркенлек сокландыра рәссамны. 1930 елда Сәмәркандка күченеп китә. Ул нигез салган Ташкент сәнгать училищесы байтак вакытлар аның исемен йөрткән. Казаннан киткәндә ул үзе белән фәкать ике-өч картинасын – шуларның берсе «Портрет татарки. Обрученная невеста» әсәрен генә ала. Бу әсәрен ул 1927 елда Бөтентатар күргәзмәсендә тамашачылар хөкеменә тәкъдим иткән була. «Татар кызы...» портретын язганда рәссамга Хәлимә Терегулова өлге булган. Павел Петрович Терегуловлар йортына еш барып йөри, алар яшәгән йорт, бай китапханә, дуслары-танышлары күңеленә хуш килә. Идел буе болгарлары тарихы белән кызыксына, татар зыялылары белән аралашырга ярата. Ләкин рәссам иҗатының бу чоры ныклап өйрәнелмәгән» дигән юлларны укыйм.

Хәлимә ханымның әтисе морза Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов татар мәдәниятенә гаять зур өлеш керткән шәхес. Укытучы сәләте аңа табигатьтән бирелгән булгандыр, Казан ветеринария институтында укыганда ук аны Шиһабетдин Мәрҗани үзе эшли торган мәдрәсәгә рус теле һәм әдәбияты, биология укытырга чакыра. Институтны тәмамлагач, Ибраһим әфәнде Казандагы татар укытучылар мәктәбендә укыта. Укымышлы, тирән белемле, зирәк мөгаллимнең юмарт, ярдәмчел, кешелекле булуын, ятим, ярлы балаларга бушлай уку мөмкинлеге тудыруын да онытмыйлар. Ә җәмәгате Гайшә ханым иренә теләктәш, таяныч була, һәр эштә аңа ярдәм итә.

Терегуловлар татар театры тарихында да якты эз калдырган. Без театр тарихын 1906 елдан башлап исәплибез. Ә Фатих Әмирхан бер дустына язган хатында татар өйләрендә тамашаларның 1903 елда ук куела башлавын әйтә. Бу чорда рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең мәдәни хәрәкәте шактый киң колач җәя. Бу хәрәкәт «Шимбә» исемендәге түгәрәк оештырылу белән башланып китә. «Бишенче ел» күкрәп күтәрелә. Гомум ашкыну, фидакарьләр күңелендә туган изге уйның чынга ашасына чиксез ышану... Татар дөньясы уяну, канатлану чоры бу. Фатих Әмирханның «татар сәхнәсенең бу дәвере сөйләнгәндә... Ибраһим абзый Терегуловлар гаиләсен, гомумән, зекер итми китәргә мөмкин түгелдер» дип, алар гаиләсенә басым ясап әйтүе шактый зур әһәмияткә ия. Бу урында беренче татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская истәлекләренә тукталып китү дә урынлы булыр. Аңа унөч яшь. Дус кызларына ияреп, бию мәктәбенә, рус театрына йөрүен яза. «Акчам булмаса, иптәшләр белән бишәр тиенләп салышып булса да барабыз. Менә бервакытны Терегуловалар татарча любительский спектакль куйдылар. Минем дә бик катнашасым килде. Ләкин булмый, монда морзалар гына уйныйлар. «Морза кызы булмаганнарны катнаштырмыйбыз», диләр. Шулай булгач, без анда барып та йөрмәдек». Шул заманда ачылган «Яңа клуб» һәм «Шәрык» клубы театрга гашыйк фидакарьләргә иҗади сәләтләрен үстерү мөмкинлеге ача. «Яңа клуб»ның тәүге артистлары – Терегуловлар гаиләсе, дуслары, туганнары...

Димәк, «Обрученная невеста» – «Ярәшелгән кәләш» портретында – татар кызы Хәлимә Терегулова!

1905 елның 26 апрелендә бу тату гаиләдә якты дөньяга аваз салган бишенче кыз – Хәлимә әле бу хәлләрдән бигүк хәбәрдар түгел. Әмма әнисе – укымышлы Мөхәммәтгали Мәхмүдовлар гаиләсендә үскән, балачактан милли тәрбия, ныклы гыйлем алган Гайшә ханым бишек җырлары аша сабыйлары күңеленә игелек орлыкларын мул сала. Чөнки үзе дә театрга, сәнгатькә гашыйк зат ул. Кызлары белән бергә театр уйнап йөри. Ә кызлары бишәү: Әминә (1887–1995) – булачак

табиб, профессор Əбүбəкер Терегулов белəн театр уйнап йөргəн чакта таныша һəм аңа кияүгə чыга; Мəдинə (1892–1984) – Троицк, Касыйм һəм Казан калаларында укыткан; Рабига (1895) – Н. И. Лобачевский исемендəге китапханəдə китапханəче; Фатыйма (1903) – биолог, Бөгелмəдə эшлəгəн. 98 яшендə дə аның һəр иртəне физзарядка белəн башлавын сөйлилəр. Алар һəммəсе озын гомерле!

Шəрык клубының чыгырын əйлəндерүчелəр, хуҗалары кем соң? Клубның эшчəнлеге – аксакаллар шурасы җитəкчелегендə бара. Клуб оешкан көннəн – 1907 елның 1 декабреннəн аның даими рəисе Ибраһим ага Терегулов була. Ə совет əгъзалары – Гафур Колахмəтев, Галиəсгар Камал кебек зыялылар. Шəкертлəрнең дөньяга карашын киңəйтү максаты белəн биредə əдиплəр, шагыйрьлəр, җырчылар һəм артистлар белəн очрашулар уза. Габдулла Тукай да, килеп, монда чыгыш ясаган, дилəр.

Татар хатын-кызлары арасыннан чыккан беренче музыка белгече, СССР композиторлар берлеге əгъзасы ул – Хəлимə Терегулова.

1920 елда Ибраһим Терегуловны Сəмəрканд педагогия институтының биология кафедрасы профессоры итеп билгелилəр. Шунда – Сəмəрканд каласында 1921 елда вафат була.

Төпчек кыз Хəлимə дə сəнгать дөньясын балачактан үз итə. Аны сигез яшендə Гуммертның музыка мəктəбенə укырга бирəлəр. Уку елларында – дүрт ел эчендə ул фортепианода йөгерек уйнарга өйрəнə. Ə аннан соң – Оренбургта ачылган музыка мəктəбе. Аның педагогы танылган музыкант Федотовлар кызы, мəшһүр виолончелист Мстислав Ростроповичның əнисе – пианистка Софья Николаевна була. Тəҗрибəле музыкантлардан осталыкка өйрəнгəн Хəлимəгə укуын тəмамлагач, музыка мəктəбендə фортепиано классын бирəлəр. «Беренче укучым Җəүдəт Фəйзи тора-бара атаклы композитор булып танылды. Ике яшькə олы абыйсы Мидхəт Фəйзуллин – нейрорентгенолог, медицина фəннəре докторы, профессор. Мирхəйдəр Фəйзи дə аларның туганы. Салих Сəйдəшев белəн шунда бергə эшлəү бəхете дə тиде», – дип искə ала ул кызыклы чорны.

П. И. Чайковский исемендəге Мəскəү дəүлəт консерваториясенə укырга кергəч, Хəлимə туташ татар музыкасы тарихын үстерүгə хезмəт итү максатын алга куя. Диплом эше язганда Муса Җəлил белəн очрашуы хəтерендə озак сакланачак. «Тиздəн «Алтынчəч» сəхнəгə менə, дидем. Ул: «Мин эшемне тəмамладым инде, фронтка китеп барам», – ди. Соңгы очрашу булган бу!»

Мəскəүдəн кайткач, Казанда консерватория ачылганчы Хəлимə музыка мəктəбе һəм музыка училищесында укыта. «Укучылары аны, озын зифа буйлы, чəчлəрен шома итеп тарап, калын толымын артка өеп куйган, коңгырт күзлəре нур чəчеп торган яшь укытучыны ярдəмчел, якты күңелле, халык моңнарына гашыйк зат итеп хəтерли», – дип яза музыка белгече Ф. Бикчурина Казан консерваториясенең юбилее мөнəсəбəте илə басылган мəкалəсендə.

Бу – 1996 ел. Хəлимə Терегуловага 91 яшь. «Җаны-тəне белəн музыка дөньясына бирелгəн, озак еллар Казан консерваториясендə укыткан ханым күз алдында яшəрə. «Муса Җəлил исемендəге Татар дəүлəт опера һəм балет академия театрының язмышы мине тирəн борчуга сала, – дип сөйли ул. – Җəлилнең «Алтынчəч»е репертуарда иң озак сакланган опера. Театр сезонны аның белəн ача иде. Əмма Мансур Мозаффаровның «Галиябану»ы, Җəүдəт Фəйзинең «Тапшырылмаган хатлар»ы озак вакытлар куелмау белəн һич килешəсе килми. Татар операсының чишмə башы Солтан Габəши, Газиз Əлмөхəммəтов, Виноградовлар иҗат иткəн «Сания» операсыннан башлана. Əүвəлге елларны татар опералары да рус, чит ил əсəрлəре белəн бертигез күлəмдə куела иде. Мəсəлəн, Хөснул Вəлиуллинның «Самат»ын казанлылар да, автобуслар төялеп килгəн «авыллар» да яратып карый иде. Арабыздан киткəннəр хакында истəлеклəр дə кадерле ич безгə! Онытылмасын иде тарихыбыз!»

Бүген дə көнүзəк мəсьəлə түгелмени болар?!

Һəм, əлбəттə, бу ханым хакында күбрəк белəсем килеп, академик Марсель ага Əхмəтҗановка шалтыратмый түзə алмадым. Бəлки, балалары, оныклары бардыр? «Хəлимə апаны искə төшерүегез өчен бик зур рəхмəт, – дип башлады сүзен күренекле галимебез. – Консерватория укытучысы, музыка тарихы фəненə саллы өлеш керткəн, татар музыкасы тарихын өйрəнү, пропагандалауга бөтен гомерен багышлаган шəхес иде ул. Кеше буларак бик тə тыйнак, намуслы, кешелекле иде... Без бер тирəдəрəк яшəдек. Миңа, тарихчы буларак, затлы зыялыларыбызның тормышын, эшчəнлеген күзаллау кызыклы иде. Хəлимə апа кияүгə соң гына – кырык яшьлəрендə генə чыкты. Ире Əхмəт абый Булатов кызыклы əңгəмəдəш иде. Сугыш елларында Сөембикə манарасын һəр яклап үлчəп, сызымнар төшереп йөргəннəрен сөйлəде. Күрəсең, фашистлар монда кадəр килеп җитəр дə халкыбыз өчен кадерле ядкарь – манара зыян күрер дип курыкканнар. Бер генə уллары бар. Əхмəт абый – Чирмешəн ягы мишəре булганга аны Али дип йөртə. Гали архитектура институтында укып йөрде. Өченче курстан ташлады. Яратып йөргəн кызы – Лəйсəн дə исəн түгел бугай. Балалары юк иде, дип белəм. Озын гомерле булды Хəлимə апа, əмма авырлык белəн мохтаҗлыкта яшəп дөнья куйды. Ире салгаларга ярата иде шул. Гали дə шул замана зəхмəтеннəн ерак китə алмады. Хəлимə апага Казанның Таулы микрорайонында фатир биргəннəр иде. Ни аяныч, соңгы сулышында янында беркем булмаган. Ə бит кадер-хөрмəт күреп яшəргə лаек, дөнья бəһасе ханым иде ул...»



ЯНГУЛОВА Сания

Туган елы: 1924 елның 25 гыйнвары.

Гаиләсе юк, сеңлесе белән яши.

Карьера:
Казанның 3 нче номерлы тегү фабрикасында тегүче булып эшләгән.

Тормыш шигаре: «Яшисем килеп яшим!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Хыялым чынга ашты!

Яшем шактый өлкән булса да, минем көнем шулай корылган: көн саен ярты сәгатькә урамга һава суларга чыгам. Сеңлем Римма белән өй тирәсен урыйбыз. Айга ике тапкыр исә ерак-карак «сәяхәт» итәбез: яңа ачылган берәр кибеткә булса да барып кайтабыз. Казанда океанариум эшли башлаганын телевизордан ишеткән идем. Хәтта пингвиннар да бар, диделәр. Ә мин аларны гомер буе күрергә хыялландым! Туганнарым бу теләгемне дә үтәде. Океанариумдагы эреле-ваклы балыкларны сабыйларча сөенеп карап йөрдем. Әмма иң кызыгы, әлбәттә, пингвиннар иде! Үз күзләрең белән күрүгә ни җитә!


Җылы сүз – җан азыгы

«Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан» медален тапшыру тантанасына чакыру килгәч, башта «йөрмәм» дигән идем. Йөрәк кенә һаман яшь бит... Әмма көне җиткәч, күңел алгысынды – сеңлем белән Совет районындагы 175 нче мәктәпкә киттек. Балалар искиткеч концерт оештырганнар! Үземнең пианинода уйнаган чакларым исемә төште... Медальне бер ир-ат тапшырды. Безне урыннан да кузгатмады: яныбызга килеп, һәркайсыбызны аркадан сөеп, котлап, бүләкне бирде. Җитәкчеләргә, Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка рәхмәт – хөрмәтле беләләр. Безгә тагын ни кирәк?!

Кытай баеса... игелек кыла

Кытайда бер миллионер авылдашларының иске йортларын сүттергән дә, алар урынына яңа, зур, иркен йортлар салдырган. «Үскәндә алардан күргән мәрхәмәт өчен, – дип аңлаткан ул үзенең бу адымын. – Тамырларымны, кайдан чыгышымны онытканым юк. Үземә кайчандыр булышкан кешеләргә бурычымны һәрвакыт түләргә тырышам». Алай гына да түгел, бу игелекле бәндә картларны, мохтаҗ гаиләләрне көнгә өч тапкыр тукландырып торуны да үз өстенә алган. Байлыкка табынмаган кешеләр күңелемә бик якын. Мин үзем бар тапканымны сәяхәтләргә тоттым.

сөендерде 




көендерде 

сөендерде 



көендерде 

сөендерде 



көендерде 

Бәхет тәхеттә түгел...

Үземне белгәннән бирле китап укыйм. Кызганыч, китапханәгә үзем йөри алмыйм инде. Әмма сеңлем тарих белән кызыксынуымны белә. Елена Коровинаның «Великие женщины мировой истории» китабына дөньяны үзгәрткән 100 хатын-кыз язмышы тупланган. Клеопатра, Жанна д'Арк, Индира Ганди, Коко Шанель... Аларның язмышлары, омтылышлары, җиңүләре, фаҗигаләре... «Тарих үзе ир-атларның исемен генә отып калса да, аны хатын-кызлар яза», – ди Гейне. Әйе, исемнәре тарихта калган, ләкин бәхетле тормыш кичергәннәре арада сирәк. Гади генә көн иткән хатын-кызлар арасында бәхетлеләр күпкә күбрәк.

Гаделсезлек дәвам итә

Сугыш вакытында мин тегүче идем инде. Ирләр күлмәге тектек. Эштән бүлеп, окоп казырга да җибәрделәр. Авыр иде, әмма һәммәбездә бер уртак хәсрәт иде ул көннәрдә – шуңа сабыр иттек, түздек. Сугыштан соң исә «әтиле» һәм «әтисез»ләргә бүлендек. Әтиләре фронттан исән-имин кайтканнарның тамагы да тук, өс-башы да бөтен булды. Ишетеп торам, бүген оныкларына кадәр фатирлы иттеләр инде. Ә сугыш ятимнәре?! Алар гел китек күңел белән яшәде: «әти» дип әйтә алмадылар, мохтаҗлык-юклыктан авыр араландылар. Югыйсә туган ил каршында аларның бер гаебе юк бит. Киресенчә...

Пенсиясез ничек яшиләр?!

Колакларым начар ишетә: Путинның турыдан-туры элемтәсен тыңлый алмадым. Әмма сеңлем минем өчен аны махсус карады. «Бездә сугыш булмаячак!» – дип әйткән илбашы. Шул сүзе мине бик тынычландырды әле. Украинадагы хәлләрне телевизордан гел күзәтеп торам. Безнең кебек өлкәннәр анда пенсия ала алмый тилмерә. Күзләрендәге өметсезлек, чарасызлык, гаҗизлек, аптырау, ару... Әле социаль яклау бүлегеннән: «Ишегеңне алыштырыйк, – дип килделәр. – Миңнеханов куша», – диләр. Бөтен җирдә Президентлар безнеке кебек булса икән! Рәхмәт әйтеп баш тарттым.

16+

ХИСЛӘР ИХЛАС БУЛГАНДА...

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Римзил ВӘЛИЕВ,
журналист һәм җәмәгать эшлеклесе;
өйләнгән;
күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Зилә Вәлиева белән 37 ел гомер итәләр.

1. Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

Алай йотлыгып карамаска тырышам. Кешене күргәч тә, артык сокланып, аннан соң якынрак танышкач, чын хакыйкать ачылып, күңелдә юшкын калырга мөмкин... Яшьрәк чакта хатын-кызның сурәтендә иң мөһим деталь – күзләре һәм иреннәре иде бугай минем өчен. Хәзер аларның шәфкатьле, йомшак күңелле булуы, җылылыгы мөһимрәк. Әмма андыйлар сирәк очрый бүген. Әни искә төшә...

2. Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

Рациональ акыллары чамалырак булса, аптырамыйм. Еш очрый андый хәл. Хис, үҗәтлек, интуиция көчле булгач, нишләтәсең, салкын акыл эшсез кала. Дөрес, чыгармалар бар. Йөрәк белән түгел, салкын акыл белән фикер йөртүче, субъективлыкка бирелмәүче хатыннар да була. Ләкин алар күп түгел.

3. Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

Хыянәт, имансызлык, комсызлык өчен.

4. Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сиңа аның кайсы якынрак?

Икесе дә шәп. Тик тормышта өченче кавем дә очрый, ахрысы – тиле гашыйкны тезләндереп, алиһә булырга, мәхәббәттән файда күрергә омтылучылар...

5. Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

Була ала. Һәм бу бик кирәк тә! Бик күп ирләр моны ахмаклык дип санаса да, мин үзем һәрвакыт шуңа омтылам.

6. Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

Хәтерлим. Бу турыда интервьюлар биргәнем дә бар. Ләкин тәкъдимнең ничек ясалуы бер-берсеннән башка яши алмаган, яратышкан парлар өчен әллә ни мөһим түгел. Уртак планнар үзеннән-үзе туа башлый. Карарны Ходай кабул иткәч соң...

7. Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...

Чыннан да, ир кешенең идеалы әнисенә охшаган була. Әни кебек хатын-кызны табу бик читен. Ә хатын-кызларның күбесе ирен әтисе образы белән чагыштыра.

8. Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар...

Авыр хәл бу. Андый чакта иргә чыдарга гына кала. Ахыр чиктә ирнең хатыныннан калышуы барыбер гафу ителмәячәк. Ир кеше үз дәрәҗәсен төшермәскә тиеш. Берәр тармакта зур уңышка ирешсә әйбәт. Аерылу варианты да начар түгел: тигезлек, гадел мөнәсәбәт булмаса, чынлап та, нишләргә кала соң?! Юньле ир кеше хатын табаны астында яши алмый. Әмма акыллы хатын, гаилә бәхете бәрабәренә, үзенең куәтен бераз яшерергә тиеш. Чибәр, булдыклы, бай хатыннарның ялгыз картаюы гаҗәп түгел.

9. Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

Мөнәсәбәтләрне барыбер яшерә алмыйсың. Әмма үзеңне яратмаганга «бәйләнмәскә» кирәк. Ә үзен яраткан кешегә хатын-кыз үзе ачылса да зыян булмас. Әйткәнемчә, яратмаганга гына берни белдермәсен...

10. Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

Буй-сын, акыл, дәрәҗә, байлык, кием-салым, холык.

11 **Хатын-кызлардан үзегез игътибар көтәсезме?**
Төпле, булдыклы һәм ышанычлы ирләр һәрвакыт тансык... Ир кешенең үз фикере булырга тиеш аның. Хатын акылына калмас өчен.

12 **Ир-ат артык чибәр һәм көчле хатын-кыздан курка.**
Шулай. Чибәрлектән гайре сыйфатлары булмаса, нигә кирәк алар? Кызык түгел.

13 **Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.**
Ир кеше субъектив карашка, хисләренә, мөнәсәбәтенә карап тормый, вазгыятьне ничек бар, шулай чагылдыра. Рациональ акыл мантыйгы ярдәмендә. Ә хатын-кызның тормышка карашына аның үз мөнәсәбәте тәэсир итә. Ул акны кара итеп кабул итәргә дә мөмкин...

Бәла шунда: хатын-кыз үзе генә барысын да белә дип уйлый. Кайбер хатын-кызлар үзенең акылсызлыгын аңламый. Дөрес, хатын-кыз холыклы ирләр, салкын акыллы хатыннар да була. Андый ир-ат мине чиркандыра, ә тирән акыллы хатын-кыз күңелемә хуш килә.

14 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**
Аңламаган очрак юк. Һәрвакыт аңлашыла. Хатын-кыз булганга эшлиләр мантыйкка каршы гамәлне.

15 **Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?**
Хаклыгыңны исбатлап маташу файдасыз. Чемодан җыя башларга кирәк. Чыгып китү өчен. Яки эндәшмичә каласың. Шулай җайлырак. Вакыт барысын да үзе хәл итә.

16 **Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин ардым, дип, диванда кырын ятып тора.**
Ә нигә үзең пешермәскә? Шулай тәмлерәк тә килеп чыга әле – ирләр ашы бит ул. Зур проблема түгел бу. Хатын-кызның вакыты җитмәсә, үпкәләргә ярамый. Ә менә ул, гомумән, ялкау булса, аның белән тормаска кирәк. Барыбер дөнья көтеп булмас.

17 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**
Мөмкин булса, көтәсең инде.

18 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.**
Зиләнең миңа бүләк аласы килсә, башта киңәшәбез. Яратмыйм мин бүләк алырга, ничектер уңайсыз... Үзем дә бүләк сайлый белмим. Туксанынчы елларда, каядыр баргач, бүләк алып кайтып була иде әле. Хәзер ярый алмыйсың. Зәвыклары бик алга китте гүзәл затларның.

«Синең өчен яшәмәскә!» – дидем

Дөнья болай да буталчык –
Чуалган гомер җебенең
Нигә очын эзләмәскә? –
«Синең өчен яшәмәскә!»

Аерылгач – юксынмаска,
Очрашканда – сөенмәскә,
Сиңа бәлаләр килгәндә
Борчылмаска, көенмәскә...
«Синең өчен яшәмәскә!»

...Төштә күрергә теләмим!
Һич кирәкми
өннәреңдә эндәшергә,
Таң атканда чык тамчысын
бүлешергә – һич кирәкми...
«Синең өчен яшәмәскә!»


Зәңгәр күккә исемеңне
пышылдарга ярамый!
Шул исемне үләннәргә,
агачларга кушу – ярамый!
Үрелергә, хәтта күренергә ярамый!
...Нинди гөнаһларым өчен
Язмыш мине җәзалый?

Йөз көн шакыдым йөрәк ишекләрең,
Йөз көн шакыдым.
Җавап ишетмәдем...
Каһарманмы мин бер?
Әллә мескен?
Йөз көн шакыдым йөрәк ишекләрең,
Йөз көн...
Синең өчен яшәмәскә!
Яшәмәскә синең өчен.
Яшәмәскә. Яшәмәскә!
Зәхмәт суккан
бөкре сукбай булып чиркандырмам.
Хөкем көткән мәхбүс булып,
Көлке мәхлук булып калмам...

«Синең өчен яшәмәскә!»
Тыңла, җаным, чыда, йөрәк!
Синең өчен яшәмәвем
Булсын сиңа миннән бүләк!

Синең өчен яшәмәгәч,
Беркем өчен яшәмәгәч,
Яшәү миңа нигә кирәк?

(Римзил ВӘЛИЕВнең яшьлек чоры иҗатыннан.)



VIVAT, КУБА!

«Без Кубаның башкаласы Гавана шәһәренә – Хосе Марти исемендәге халыкара аэропортка төшеп туктадык». Самолет кабинасыннан яңгыраган игълан салонда төрле телләрдә сөйләшеп килгән юлдашларым йөзенә бертөсле шатлык булып кунды. Ниһаять! «Аэрофлот» хезмәткәрләренә рәхмәт – тоташ ярты тәүлеккә сузылган очышның авырлыгын сиздермәс өчен барысын да эшләделәр.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Без – җирдә! Төштем дә очкыч аланының ыгы-зыгысына чумдым диюемне көтәсездер. Юк шул! Монда берәү дә ашыкмый, кабаланмый, каядыр йөгерми булып чыкты. Гаҗәп! (Соңрак шәһәр урамнарында йөргәндә дә кат-кат игътибар иттем: Гавана без күз алдына китергәнчә кайнап тормый икән бит. Йөзләрдә елмаю, ачык, якты карашлар, җылы мөнәсәбәт...)

Аэропорттан Гаванага егерме чакрымнар тирәсе. Мәңге җәй булган илдә табигатьнең кайсы фасылы икәнлеген әйтү дә авыррак. Шәһәргә керәбез. Күзем – юлда. Беренче тапкыр Гаванага килүчеләр бар да үзләрен минем кебек ниндидер кинога эләккәндәй хис итәме икән? Моның кадәр ретро-автомобиль! «Антиквариат кебек күренгән бу машиналарны кубалылар үзләре шәһәрнең күрке, символы санамый. Алар өчен мондый машина бүген туристларны йөртү, акча эшләү чарасы. Ретро-автомобильләрнең берсендә дә үз двигателе түгел инде, бүген дә алар йөреп торсын өчен хуҗалары кулдан килгәнне дә, килмәгәнне дә эшли», – диделәр.

Йөк машинасы әрҗәсе тулы ананас... Куба мине адым саен шаккаттырырга уйлый бугай! Шикәр чөгендере төяп, көзен колхоз басуыннан кузгалган машиналарны күз алдына китерегез. Нәкъ шул күренеш! Безне сул яктан узып киткән икенче машинада исә челтәр сеткаларга тутырылган бананнар күреп калдым. Ананас кебек җиләк-җимешнең патшасы дип саналмый, соңгы елларда табыныбыздан өзелгәне юк аның. Әмма агачыннан үзебез өзгән җимеш тә түгел.

Мин бит әле һаман отельгә дә барып җитмәгән... «Националь» кунакханәсенең (Куба турында төшерелгән фильмнарда еш күренә, еш яңгырый ул) швейцары –



■ Гавананы «тәгәрмәчләр өстендәге музей», диләр. Мизгел эчендә ким дигәндә илле елга артка чигенеп куясың... Ачык төсләр яраталар Кубада. Машиналарны да яшелгә, кызылга, зәңгәргә... буяганнар. Читтән караганда матур, һәрхәлдә, борынгы икөнлекләре ул кадәр сизелми.

мохитоны шушында ясыйлар, эчәбезме?» – ди Альберто. Гид белән танышырга өлгердек инде – ул бездә, Харьков шәһәрендә укыган. Кубага кайтып, инженер булып эшләгән. «Кызым укый, хатыным сиксәннән узган әнисен карый, эшләүче мин генә. Хезмәт хакы аз булгач, туризм өлкәсенә күчтем менә, – ди. – Россиядән килгән ханымга экскурсия үткәрәсең, дигәч, сезне нигәдер юан итеп күз алдыма китергән идем. Ә сезнең күзләрегез матур!» «Рәхмәт!» – дип елмаям: хатын-кызга иң еш әйтә торган комплиментлары шушы дип укыган идем – менә ишеттем дә...
Яңа өзгән бөтнек салган боз кебек салкын мохитога караганда, бөтнекле чәй минем өчен тәмлерәк булыр иде...

шактый олы яшьтәге негр – минем Россиядән икәнемне аңлап алуга: «Добро пожаловать!» – дип эндәште. Элек Кубада рус телен радиодан да өйрәткәннәр! Өлкән буын хәтерле, димәк.

Җиде сәгать. Мәскәү белән Гавана вакыты арасында нәкъ шуның кадәр аерма. Мин Гаванага үзебезчә кичке тугызда барып төштем, ә анда әле көндезге сәгать ике. Гомеремдә мондый озын тәүлек булганы юк иде. Кичке аш вакытында ипи урынына... банан коймаклары китерделәр. Аз гына сарымсак кушканнар. Мае сеңсен өчен кәгазь пакетка салганнар. Бер атна мин түзәрмен анысы, әмма бездән күчеп килгәннәр иписез ничек яши икән?! Кубалыларның төп ризыгы – фасоль, дөге, дуңгыз ите. Ә без, яңа гына тотылган океан балыгы ашау мөмкинлеге булганда, шуны сайлыйк әле...

Моңарчы кичке сигезенче яртыда ук ятып йоклаганымны хәтерләмим. Аның каруы, алар вакыты белән төнге икедә йокым туеп уянган идем инде. Казанда эш көне башланды – телефоным шалтырый да шалтырый. Интернет юк, «смс» язарга туры килер. («Ничек инде интернет юк?! Ничек яшиләр соң алар интернетсыз?» Өйгә кайткач, кем белән генә сөйләшсәм дә, шушы сорауны бирде. Яшиләр менә... Аның каруы, бездәге кебек телефонны кулдан төшермәү гадәте юк әле анда. Күзгә-күз карап аралашуның тәмен югалтырга өлгермәгәннәр. Дөрес, кунакханәләрдә интернет эшли, әмма билгеле бер вакытта гына, шактый әкрен һәм кыйммәт.)

Тәрәзә янына басып, океан артыннан кояш күтәрелүен күзәтәм. Исәнме, яңа көн! Мине бүген Гавана белән очрашу көтә.

Де Армас мәйданы

Без – Иске Гаванада. Темплетес чиркәве – килеп урнашкач беренче гыйбадәт кылган җир – 1515 елда шәһәргә нигез салынган урын дип санала. Чиркәү каршында – сейб агачы. Унбишенче ноябрьдән уналтысына каршы төндә – «шәһәр көне»ндә биредә зур чират тезелә икән: һәркем агачка кулы белән кагылып, аны өч тапкыр әйләнеп чыгып калырга тырыша. Теләкләр кабул була ди. Гавананың ун метрдан гына торган иң кыска урамы – Энна да шушы мәйданда. Чиркәүнең уң ягында – «Санта Исабель» кунакханәсе. «Иң тәмле

«Моңарчы кеше күзләре күрмәгән иң матур җир бу».
Христофор Колумб

Элеккеге советлар иленнән килгән һәркем Альберто өчен аерым игътибарга лаек бугай. Яшьлекләре шунда узган бит аларның – сагыналар. Союзда бергә укыганнар Кубада гомер буе дус булып, аралашып, очрашып яшиләр икән. Күрешкәч, студент чакта ашаган ризыкларын пешерәләр: борщ, пилмән... Өзелеп, кара ипи сагыналар! Альберто сумкасыннан фотосурәтләр чыгара: «27 октябрь. Беренче тапкыр кар күргән көнем бу минем!» Сөйләшә торгач, икебез өчен дә күңелле бер нәрсә ачыклана: студентларның төзелеш отряды белән Төмәнгә барганда Альберто Казан аша узган булган! Дөньяны киң диләр тагын...

Мохито эчелеп бетмичә, өстәлдә калды. Кабат де Армас мәйданына чыгабыз. Каршы якта – де ла Реаль Фуэрсо ныгытмасы. Кайчандыр испаннар барлык җыйган алтыннарын шушында саклаганнар. Манара очына урнаштырылган флюгер – «Ла Хиральдилья» – Гавананың төп символларының берсе. (Атаклы «Гавана Клаб» ромы шешәсе тышында





да аның сурәте.) Кулына зур хач тоткан ханым каядыр еракка төбәлгән... Испан губернаторы Эрнандо де Сото бер урында гына төпләнеп яши алмаган: аның күңелен гел ерак илләр чакырган – мәңге яшь калу серен эзләп, ул юлга кузгалган. Ә аның хатыны, көн саен шушы башняга күтәрелеп, ирennән хәбәр көткән: офыкта җилкәннәр күренмиме – кайтып килмиме... Ире Миссисипи ярларында үлеп калган. Ә аны – донна Исабель де Бобадильяны утрауның беренче һәм бердәнбер губернаторы итеп куйганнар...

Узган ел Кубага өч миллион турист килгән.

Кайчандыр хәрбиләр парады узган мәйданда бүген букинистлар китап сата. Алар арасыннан узып, кечкенә генә паркка керәбез. «Гаванада мәчет бармы?» – дип сорагач, Альберто: «Мәчет юк, әмма гыйбадәт кыла торган бүлмә бар дип беләм, эзләп карарбыз», – дигән иде. Таптык бит! Шушы парк артындагы йортның икенче катында урнашкан икән ул. Зур түгел. Әмма Гаванада мөселманнарны да күп дип әйтеп булмый бит: егерме бер ел әлеге бүлмәне алсыз-ялсыз карап торучы 84 яшьлек Вальдо Мисса: «Сыябыз», – ди. Йортның аскы катында безне тавис кошлары озатып кала. Кешедән курку уйларында да юк! Беренче төнне кунакханә бакчасында аларның кычкыруын казларга охшаткан идем. Алар монда туристлар күз салырга мөмкин булган бөтен җирнең бизәге.

Сан-Карлос де ла Кабанья

1762 ел. Башбирмәс Гавананы көтмәгәндә инглизләр басып ала: һөҗүм судан түгел, коры җир аша ясала. Флоридага караганда Куба аңа кирәгрәк дип тапкан Испания, беренчесен биреп, икенчесен кире кайтарса да, бу хурлыкны төзәтергә ашыга. Шәһәргә беркем дә якын килмәслек итеп ныгытма төзи башлыйлар. Аны төзү күпмегә төшәчәген белгәч, Испаниянең короле Карл III, Мадридтагы сараеның балконына чыгып: «Ул кадәр кыйммәтле ныгытма моннан ук күренергә тиештер», – дип, күзәтү торбасын диңгезгә юнәлткән, имеш...

Бүген биредән кеше өзелми. Бигрәк тә кичләрен. Испаннар вакытында һәр көнне кичке тугызда ныгытмада туптан атканнар. «Читләр өчен шәһәргә керү капкалары ябыла» дигәнне аңлата торган була бу. Плацдармда урнашкан тупларның берсе хәзер дә эшли! Кичке тугыз якынлашканда ныгытмадагы утлар сүнә, факеллар гына яна. Милли гвардия гаскәрләре кебек киенгән егетләр тупка дары тутыра. Һәм... Мондый ук көчле шартлау көтмәгән идем – колакларымны томалап, үзем дә сизмичә, җиргә чүгәм. Куркыныч! Ә шундый туплар берьюлы берничәү атса?!

Элек гарнизон урнашкан казармаларда – бүген музейлар. Әмма бу ныгытмага кичке Гаванага карап сокланыр өчен барырга кирәк. Әнә ул уч төбендәге кебек каршы якта ничек матур булып ята!

Ведадо

Гавананың тарихи районнарының берсе бу. Элек бай америкалыларның иң яраткан урыны булган Ведадо: алар бирегә ял итәргә, күңел ачарга, мәхәббәт маҗараларына чумарга килгән. Безгә зәңгәр экраннар аша бик таныш булган Революция мәйданы да шушында урнашкан. Менә мин аның уртасында басып торам. Зур бер кырны күз алдына китерегез. Тик үлән урынына асфальт җәелгән. Ә 109 метрлы бетон (дөресрәге, бетонга бик тә охшаган Куба мәрмәреннән эшләнгән) шпильне уртада үсеп утырган агач дип хис итәргә дә була... Шагыйрь, революционер, Кубаны Испания коллыгыннан азат итү хәрәкәтенең лидеры Хосе Марти истәлегенә салынган мемориал ул. Гавананың иң бөек ноктасы – 99 метр биеклеккә күтәрелеп, шәһәр өстенә күз салырга була...

Мәйданның бер ягында Че Гевара барельефы урнаштырылган МВД бинасы. Туристлар фотосурәткә шул якка басып төшә. Революция мәйданына миллионнан артык кеше сыя, диделәр. Президентлары Фидель Кастроның сигез сәгатькә сузылган чыгышы турында хәтерлисезме? Шушында басып тыңлаганнар аны.

Йортлар арасыннан океан күренә, диңгез һавасы килә... Матур район! Атаклы Куба сигарасын чыгаручы фабрика да Ведадода урнашкан. Туристларга үзләре белән илдән нибары бер тартма тәмәке алып китәргә ярый. Гавана урамнарында юан сигара тартып утыручыларны


бөтенләй очратмадым дисәм... Милли киемнәр киеп, туристларны үзләре белән рәсемгә төшәргә чакырып торучыларның бөтенесенең дә кулында бар ул.

Хемингуэй


Бүген мине атаклы язучы Эрнест Хемингуэй белән «очрашу» көтә. Без аны балыкчылар бистәсеннән – Кохимардан башладык. Хемингуэй торган, ул «Карт һәм диңгез» повестен язган йорт – шушында. (Бу әсәре өчен язучы 1954 елда Нобель премиясенә лаек була.) Сантьяго карт шушы бистәдә яшәгән, шушы урамнар буйлап узып, әкрен генә яр буена төшкән, каядыр шушында якын дусты – Малай белән кәһвә эчкән. Океанга чыгып киткән, зур балыгын тоткан... Җиңелеп түгел, җиңеп шушы култыкка кайтып кергән. (Картның прототибы – 104 яшькә кадәр гомер иткән Грегорио Фуэнтос белән язучы якыннан белешкәннәр.) Ул чакта бистәдә йортлар бүгенгедәй ике катлы булмагандыр, әлбәттә. Башка кешеләр яшәгән, башка заман, әмма океан шул ук булган бит! Язучы үзе дә балык тотарга яраткан. (Кылыч балык тоту ярышын оештыруны Кубада ул башлаган!) «Куба – җирдәге җәннәт ул», – дип язган Хемингуэйны балыкчылар да хөрмәт иткән, яраткан: үз акчаларына Кохимарда аңа куйган һәйкәл – шуның дәлиле.

Гаванада Хемингуэй белән бәйле икенче урын – биш катлы «Амбос Мундос» отеле. Монда – 511 нче номерда – язучы 1932 елдан алып 1939 елга кадәр яшәгән. Иртәнге якта язу өстәле янында тормый иҗат иткән. Аннан ашыкмыйча, салмак кына атлап, тар урамнар буйлап үзе яраткан барларның берсенә киткән: мохито эчәсе килсә – Бодегитага, дайкири эчәргә теләсә – Флоридитага. Соңгысы янында бүген гел халык, чират: мохитодан бигрәк Хемингуэй исеме тартып китерә. Тышкы яктан барның стеналары чуарланып беткән: килгән һәркем үз исемен язып калдырырга тырыша. Тарихта кем нинди эз калдыра инде!

■ Халык бананның вагын гына ашый. «Алмалы» дигән сортын авыз иттем. Тәме!.. Алма дигәннән, Кубада алма да, груша да үсми.



■ «Король пальмасы» дигәннәре әнә нинди була икән: кәүсәсен, әйтерсең, бетоннан койганнар. Таш багана яфрак ярган кебек. Кызык!



Малекон

Испанчадан тәрҗемә иткәндә ул «яр буе» дигәнне аңлата. Гаванага керүче култыктан башланып алты чакрымга сузылган Малекон – кубалыларның да, килгән кунакларның да иң яраткан урыны. Шәһәрне Атлантик океан дулкыннарыннан саклау өчен салынган мол әллә ни биек түгел. Зәңгәрсу-яшькелт төскә күмелеп тыныч кына чайкалып яткан океанның шактый дулап алган көннәре була икән шул. Ике елга бер тапкыр, әмма шундый берәгәйле итеп... «Ут сүнә, су бетә, бик шомлы, куркыныч була. «Океанда давыл» дисәләр, өйдән чыкмыйбыз», – диделәр. Узган ел океанда давыл булмаган, быел көтәләр. Ярга карап утырган йортларның күбесе ярымҗимерек хәлдә булуына да океан гаепле: ярсып киткән дулкыннар юлында очраган һәрнәрсәне вата, җимерә, аларга төньяктан искән җилләр булыша...

Малеконның буш торган чагы юктыр. Сәгать поясы үзгәрү аркасында йокысызлыктан интеккән туристлар иртән иртүк Малеконга диңгез һавасы суларга чыга. Балыкчылар китеп тормый. (Истанбулның Галатск күперендәге кебек берберсенә терәлеп үк басып тормыйлар билгеле.) Ял көннәрендә гаиләләр шушында ял итә. Шикәр камышын җыеп бетергәч, карнавалны да биредә уздыралар. Кичен Малекон буйлап бер-берсенә сыенып утырган гашыйклар тезелеп китә – «дөньядагы иң озын мәхәббәт эскәмиясе» дип юкка атамыйлар!

Кубада сәламәтлек саклау да, белем алу да бушлай.

Күпләр бирегә кояш батканны күзәтергә килә. Шәфәкъның батуы Атлантик океан өстендә беркайчан да кабатланмый, диләр. Әйтә алмыйм, моны тояр өчен бер атна гына күзәтү җитмидер. Менә түгәрәк алтын шар, офыкка сузылган дулкыннарга кереп «чумды». Күзләрдә иртәгә иртән аның кабат чыгачагына ышаныч, өмет янып калды... Кубаның да киләчәге өметле булыр. Туксанынчы елларда бу ил кичергән тетрәнүләр инде артта калган. Дөрес, бүген дә җиңел түгел әле аларга, әмма шушы кечкенә генә утрауны дөньяның бар почмагыннан артык күреп яраткан, аның патриоты булган халык бөтен авырлыкларны да җиңәр дип ышанасы килә!

Казан–Гавана–Казан

ЭШЛЕКЛЕ һӘМ... НӘФИС



ЛЮКС
BOUTIQUE
ул. Калинина, д.37
(843) 264-51-61
Одежда только для Женщин!
Казан, Калинин ур., 37
+7(843)264-51-61
luxkazan.ru
БЕЗ КЕШЕЛӘРНЕ КИЕНДЕРЕП КЕНӘ КАЛМЫЙБЫЗ. БЕЗ ОБРАЗ ТУДЫРАБЫЗ.

Эшлекле киенү рәвеше хатын-кыздан мәгълүм кагыйдәләрне төгәл үтәүне таләп итсә дә, нәфислекне әле беркемнең дә инкарь иткәне юк. Эш-бизнес дөньясында кайнаучы, иҗтимагый яисә дәүләт оешмаларында хезмәт куючы ханым һәм туташлар күбесенчә җитди офис киеменнән йөри. Мондый стиль эш урынында килешле булса да, көндәлек тормыш өчен ярашлы түгел. Җитди, хәтта әйтер идем, артык кырыс бу киенү рәвеше хатын-кызларны торган саен ныграк калыпка буйсындыра, аларга үз-үзләрен күрсәтергә мөмкинлек калдырмый. Эшлекле стильне яратучы хатын-кызлар тора-бара үзләре дә кырыслана кебек. Кайвакыт кием белән холык-гадәтләрен «капларга» да омтылалар шикелле. Җайлы бит!

Эшлекле кешеләр дөньясында ир-егетләр хакимлек итә. Бу даирәдә эшләүче ханымнарга үзләренең

нәрсәгә сәләтле булуларын гелраслап торырга туры килгәнлектән, хатын-кыз нәфисслеге кирәксезгә чыга торгандыр. Шулай итеп, гүзәл затлар акрынлап «йөк аты»на әверелә.

Тирә-юньдәгеләр сокланырлык нәфис образ тудыру талант һәм бераз вакыт сорый. Ә инде үз образыңны бер тапсаң, киләчәктә аны камилләштерергә һәм тулырак ачарга тырышасы гына кала.

Бүгенге сәхифәбезгә модель итеп радиомеханика колледжы директоры Лилия Яруллинаны чакырдык. Журнал укучыларыбызга ул февраль санының тышлыгыннан таныш.

Мода юнәлешләрен фаразлаучы осталарның һәрбер хатын-кызга киңәше бер: үзеңнең килеш-килбәтеңнән һич кенә дә кыенсынма! Гәрчә буй-сыныгызны мода индустриясе тудырган идеалдан бик ерак тора дип санасагыз да.

Затлы киемнәр бутигында эшләүче югары категорияле белгечләр хатын-кыз үзенең никадәр гүзәл икәнен танысын өчен тырыша лабаса.

Инде берничә дистә ел рәттән «90-60-90» үлчәменә туры килмәүче кызларыбыз, чамасыз зифаларга, ябыкларга гына төгәенләнгән мода үрнәкләренә карап, үзләрен берникадәр җайсызрак хис итә һәм дөньяның мода подиумнарында кәс-кәс йөрүче бу модельләрне күреп кызыга иделәр. Бу хәлгә башкачарак карарга тырышырга кирәк.

Әгәр дә ябыгу теләге көннән-көн көчәя икән, нәрсәнедер үзгәртә башлау үзегездән тора бит.
Көн дә көзгедән күреп ияләнгән буй-сыныгызны камилрәк итү өчен теләк һәм үҗәтлек кенә кирәк. Теләгегезне хәзер үк тормышка ашыра башлау өчен сезгә бернәрсә дә комачауларга тиеш түгел.

Гадәти генә бер очрак: хатын-кыз кибеттә үзенә кием сайлап йөри. Күзе матур күлмәккә яки җиңел тукымадан тегелгән затлы чалбарга төшсә дә, кибеттән буш кул белән чыгып китә ул ханым. Бер дә булмаса, кая кисәм дә уңайлы, дип, иркен бер пуловер сатып алырга мөмкин. Туктап, үз-үзегезгә сорау бирегез әле: үзенең килеш-килбәтеннән кыенсынучы, буй-сынын киң кием астына яшереп яшәүче хатын-кыз булырга теләр идегезме?

Беренче киңәшебез шул: иң матур, иң күркәм якларыгызны... тагын да күркәмрәк итегез.

Әгәр дә күкрәкләрегез тулы, матур икән, ачык изүле киемнәрдән курыкмагыз. Мода артыннан куучы теләсә кайсы француз хатын-кызы сезнең бу отышлы ягыгыз турында бары тик хыяллана гына ала бит. Әгәр дә буй-сыныгыз бәләкәй икән, шулай ук кимсенергә ашыкмагыз.

Икенче киңәшебез: җилкәгезне киерегез, аркагызны турайтыгыз. Гәүдәне төз тоту – үз-үзеңә ышану билгесе ул. Әгәр дә тирә-юньдәгеләр шундый ышаныч барлыгын күрә икән, көннәрдән бер көнне аңа үзегез дә ышана башларсыз.

Исегездән чыгармагыз, Сез – ХАТЫН-КЫЗ. Ир-егетләр сезнең арттан, борыла-борыла, сокланып карап калсын. Сез моңа лаек. Үзегезне яратыгыз. Нәфислекне күркәм чәч, матур итеп буялган иреннәр, матур күлмәк белән һәрдаим раслап торыгыз. Хисле һәм назлы, романтик һәм хыялый булыгыз. Экспериментлардан курыкмагыз.

Рәмзия КАШАПОВА

ЛЮКС
BOUTIQUE
ул. Калинина, д.37
(843) 264-51-61
Одежда только для Женщин!







РЕКЛАМА

Зөлфиянең эшләре белән журналыбызның февраль санында таныштырган идек инде. Бу юлы ул «Сөембикә» укучыларына бик матур беләзек ясарга тәкъдим итә. Артык катлаулы да түгел, шул ук вакытта бик матур да булган бу беләзекне ясау өчен бераз түземлек һәм өч сәгать вакыт кирәк.





Мастер-классны
Зөлфия СӘЛИМҖАНОВА
үткәрә.

БЕЛӘЗЕГЕМ, ЙӨЗЕГЕМ...







Кирәк:

• 30-35 бөртек эре сәйлән (диаметры 8-10 мм);
• 6 нчы номерлы бер кап сәйлән;
• 10 нчы номерлы бер кап шундый ук төстәге сәйлән;
• 3 м чамасы үтә күренмәле нечкә кыл (0,15 мм);
• беләзекләр өчен ясалган каптырма (лобстер, боҗра, пин һәм кыска чылбыр);
• 2 сәйлән энәсе.

Эш барышы:

■ Беләзек ике энә белән үрелә. 3 м озынлыктагы кыл кисеп алып, ике очын ике энәгә саплыйбыз. Аларның берсен уң энә, икенчесен сул энә дип атарбыз.

■ Уң энәгә дүрт «алты»лы, бер зур сәйлән һәм тагын бер «алты»лы сәйлән җыябыз. Барысы бергә алты сәйлән булды. Сул энәгә исә бер зур, бер «алты»лы һәм тагын бер зур сәйлән эләктерәбез.

■ Шушы соңгы эләктергән зур сәйлән аша уң энәне дә уздырабыз (ике энәне шушы сәйлән аша чалыштырабыз). Кылның ике очын ике якка тартып, сәйләннәрне тыгызлап кысабыз. Алар кылның нәкъ уртасында булырга тиешләр.






■ Һәр ике энәгә дә бер «алты»лы, бер зур һәм тагын бер «алты»лы сәйлән әләктерәбез. Уң энәгә өстәмә бер зур сәйлән алабыз. Шушы сәйлән аша сул энәне уздырып, кылның ике очын ике якка тартабыз.

■ Шул рәвешле беләзекне үзебезгә кирәкле озынлыкка җиткергәнче үрәбез. Төгәлләве болайрак: ике энәгә дә берәр «алты»лы, берәр зур һәм тагын берәр «алты»лы сәйлән әләктерәбез. Энәләрнең берсенә янә дүрт «алты»лы сәйлән җыябыз. Икенче энәне шушы дүрт сәйлән аша уздырып, сәйләннәрне ныгытып кысабыз.

■ Инде эшнең икенче этабына – беләзекне бизәү эшенә керешик. Бер энә аскы рәт, икенчесе өске рәт буйлап барачак. Ике рәттә дә эш тәртибе бер үк. Энәне кырый рәттәге бер зур һәм аннан соңгы ике «алты»лы сәйлән аша уздырып, тагын бер «алты»лы сәйлән алабыз. Сәйләннәр урыннарында нык «утырсын» өчен энәне кабаттан әлеге ике «алты»лы сәйлән аша атлатып, кылны ныгытып тарттырабыз.

■ Шул рәвешле, беләзекнең буеннан-буена «алты»лы сәйләннәр тезәбез. Төгәлләгәндә, энәне сәйләннәр аша йөртеп, кыл очын яшерәбез, төенләп, кылны кисеп алабыз.

■ Соңгы эш итеп беләзекнең каптырмасы тагыла. Ярты метр чамасы кылны урталай бөкләп, ике катлыйбыз һәм энәгә саплыйбыз. Беләзекнең иң очындагы дүрт «алты»лы сәйлән уртасына шушы кылны элмәкләп беркетәбез.

■ Энәгә ике «ун»лы сәйлән, лобстер һәм тагын ике «ун»лы сәйлән әләктереп, элмәкне беркеткән кылаша чорнап алабыз. Сәйләннәр нык «утырсын» өчен, энәне янәшәдәге ике сәйлән аша уздырып, кыл очын төенләп яшерәбез һәм кисеп алабыз.

■ Каптырманың икенче очы да нәкъ шулай беркетелә. Бөҗрәгә кыска гына чылбыр тагыла. Чылбыр очына, матурлык өчен, махсус кадак – кип ярдәмендә рондель элинә. Кипның рондельдән чыгып калган очы түгәрәк «карга борыны» белән бөҗрәгә бөгелә. Чылбырга ул шул бөҗрәсыннан тагыла.

■ Менә бит, тырышкач, булдырдык. Яңа беләзек котлы булсын!

Аһ, БУ НӘФИС КУЛЛАР!

Яз-җәй көннәрендә, кыска җиңле күлмәкләрдән йөргәндә, беләзек, йөзек ише, игътибарны җәлеп итәрдәй бизәнү әйберләре дә таксаң, кул тиресе «тел-теш тидермәслек» булырга тиеш. Кулларны тәрбияләү өчен берничә рецепт тәкъдим итәбез.

■ Тозлы кәбестә, әчегән сөт, эремчек суы кул тиресен яхшы йомшарта. Кулыгызны биш-ун минутка шуларның берсенә тыгып торыгыз да, җылы су һәм сабын белән юып, майлы крем тидерегез.
■ Кул тиресен тәртипкә китерү өчен бәрәңге пешкән су да – менә дигән.
■ Кул тиресен агартыйм дисәгез, әллә нәрсәләр эзләп ерак барасы юк. Түтәлдә генә үскән кузгалак суты да тирене бик яхшы агарта.
■ Яргаланган кул тиресен йомшарту өчен менә бу рецептны кулланып карарга була: 25 г миндаль мае, 1 йомырка сарысы, 1 лимон сутын бик яхшылап туглыйбыз. Кич белән, эшләр беткәч, шушы массаны кулга сылап, өстеннән чүпрәк перчатка киябез. 3-4 сәгатьтән соң юып төшереп, кулга тукландыргыч крем сылыйбыз.
■ Тукландыргыч кремны да өйдә ясарга мөмкин: 1 аш кашыгы теләсә нинди кипкән дару үләненә (ромашка, пәйгамбәр тырнагы, бака яфрагы) 1 стакан кайнап торган су агызып, бер сәгать төнәтәбез. Су «мунчасы»нда эретелгән 1 аш кашыгы балга 2 аш кашыгы үлән төнәтмәсе кушабыз. 50 г каз маена (башка төрле майлар да ярый) 1,5-2 аш кашыгы кастор мае һәм үлән төнәтмәсе салынган балны кушып, бик яхшылап туглыйбыз. Кремны суыткычта сакларга кирәк.
■ Менә бу рецептны да кулланып карарга була: ланолин кремын бер савытка сытып чыгарып, аш кашыгы алоэ суты һәм 2 аш кашыгы зәйтүн мае өстибез. Барысын бергә яхшылап туглагач, крем әзер.



ГҮЗӘЛ УРАЗОВАДАН ЭКЗОТИК СЫЙ

Оҗмаh сые булырдай бу ризыкны Гүзәл УРАЗОВА Таиландтан өйрәнеп кайткан. Ул гел шулай, кая барса да, ниндидер яңа рецепт өйрәнеп кайта икән. Пешергән ашларының тәмле генә түгел, файдалы булуын да кайгырта Гүзәл. Шунсыз булмый да, ире Илдар Хәкимов белән алар икесе дә сәхнә кешесе. Ә сәхнә гел дә матурлыкны, буй-сын зифалыгын таләп итә. Ул бүген безгә тәкъдим итә торган ризык та гәүдәгә артык авырлык өстәмәячәк, шуңа күрә шикләнмичә сез дә әзерләп сыйланыгыз.





Кирәк:

(ике кеше өчен:)
- 1 ананас;
- 200 г креветка;
- 1 стакан пешкән дөге;
- 1 уч кешью чикләвеге;
- ярты тавык түше;
- ярты стакан яшел борчак (туңдырылган);
- 1 баш суган;
- 2 аш кашыгы балык соусы;
- 2 аш кашыгы соя соусы;
- тәменчә тоз, борыч;
- 2 тырнак сарымсак;
- 1 аш кашыгы шикәр комы.

Эш барышы:








■ Тавык түшен һәм суганны ваклап турыйбыз, сарымсакны вак угычтан уабыз. Иң элек сарымсакны кыздырабыз, аннан соң тавык итен салабыз. Бераздан суган белән яшел борчакны өстибез.

■ Креветкаларны пешереп, чистартабыз һәм аларны да табадагы яшелчәләр янына кушабыз. Тәменчә тоз һәм шикәр комы өстибез. Борыч сибәбез. Таиландта ак борыч кулланалар, ә без, ак борыч таба алмагач, борычлар җыелмасы алдык.

■ Ананасны буйга урталай ярып, эчен алабыз. Кабыгын ташламыйбыз, ул кирәк булачак әле. Ананас йомшагын ваклап турап, аны да табага «озатабыз». Ананасның консервланганын да кулланырга ярый. Ул очракта шикәр комы кушарга кирәк түгел.

■ Озынча дөгене юып (дөгенең «Басматти» яки «Жасмин» дигәне яхшы була), кайнап торган тозлы суда пешереп алабыз. Әзер булгач, тишекле чүмечкә салып, суын саркытабыз. Берничә тапкыр салкын су белән юдырганнан соң, аны да табага салабыз. Чикләвекне, балык һәм соя соусларын да өстәп, сак кына болгатабыз.

■ Әзер ризыкны табынга ананас кабыгына салып чыгарабыз. Өстен креветкалар белән бизибез. Янына яшелчәләр һәм яшел аштәмләткечләр куярга була. Ашларыгыз тәмле булсын!

■ Гүзәл Уразова уздырган мастер-классның видеосын сайтыбыздан карарга мөмкин.

Бәйге

Мин Казанда шәфкать туташы булып эшлим. Эштән кайткач, тиз генә берәр тәмле әйбер пешереп, гаиләмне сыйларга яратам. Берьюлы берничә төрле ризык әзерлим. Менә бу тәбәгә дип пешергән тавыкның шулпасына да токмач салып, җәлт кенә аш өлгертергә була.

Кирәк:

200 г яшел суган;
3 йомырка;
150 г кибет каймагы;
1 стакан он;
150 г пешкән тавык түше;
70 г каты сыр;
1,5 чәй кашыгы камыр күперткеч;
тоз.

Эш барышы:

Тавык түшен пешереп суытабыз һәм яшел суган белән икесен ваклап турыйбыз. Йомыркаларны зуррак савытка сытып, миксер белән күпертәбез. Шуңа тоз, каймак, он, камыр күперткечне кушып, яхшылап туглыйбыз. Төерләре калмаслык итеп туглагач, тавык белән яшел суганны кушабыз.

Төбе майланган табага шушы массаны агызып, 180 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз. Өсте кызара башлагач, вак угычтан уылган сыр сибәбез. Кабат мичкә тыгып, сыр кызарганчы тотабыз.

Фәридә УСМАНОВА



Искәртәбез: бәйгегә тәкъдим ителгән ризыкларда «Пестречинка» ҖЧҖ продукциясе файдаланырга тиеш.

ГРУППА КОМПАНИЙ
МАДИН КЛИНИКА

Акции салона красоты «Мадина»

Устранение морщин диспортом – ~~140р.~~ **90 р.** (за ед.)
Биоревитализация – ~~10000р.~~ **5000 р.**
Пластика губ (Ювидерм) – ~~14000р.~~ **8000 р.**
Биорепарация – ~~7000р.~~ **3500 р.**
Мезотерапия – ~~1800р.~~ **1100 р.**
Аппаратная кавитация – ~~500р.~~ **250 р.** (за зону)
Программа «Интенсивное похудение» – ~~7500р.~~ **1900 р.**
Тредлифтинг мезонитями – ~~2000р.~~ **500 р.**



Пять причин, почему надо обращаться к нам:

- лицензированная медицинская косметология;
- гарантия качества;
- оптимальные цены;
- более 7000 довольных клиентов;
- опытные врачи-косметологи.

При покупке двух услуг массаж спины или кавитация двух зон в подарок!!!

Казань, ул. Астрономическая, 8 т.: 292-11-17; 8-917-880-11-17 promo madinclinica ru

НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



лицензия: №ЛО-16-01-003572

РЕКЛАМА

КИҢӘШ

КАШЫҢ КАРА...



Һәркемгә дә табигатьтән идеаль формалы каш бирелмәгән. Әмма бу бәла түгел — карандаш белән кыйгач каш ясап куйдың да... Әмма каш коррекцияләүнең дә үз серләре бар! Алар белән сайтыбызның «Белмәсәң бел» сәхифәсендә тулырак таныша аласыз. Әлегә киңәшебез шул: каш формасы белән төрле экспериментлар үткәрмәгез, бит формасына карап, һәр кешегә үзенә генә туры килгән каш коррекциясе сайлана:

- дуга сыман кашлар озынча түгәрәк йөзгә туры килә;
- озын, өскә таба югары күтәртелгән кашлар шакмак битле йөзгә килешә, дуга сыманнары да матур;
- җиңелчә күтәртелеп, очында бераз түгәрәкләнеп килгән кашлар түгәрәк йөзгә кулай;
- туры, борын арасыннан ераклашкан кашлар озынча йөзгә әйбәт.

Каш формасына мода була алмый, сезнең йөз төзелешенә, күз формасына һәм стилегезгә карап кына үзгәртелә ул. Кашлар йөзне ачып җибәрә. Кашларны карап тору бер дә катлаулы түгел, хәзер табигыйлеккә өстенлек бирелсә дә, кайчак аларның матурлыгын ассызыклап күрсәтү кирәк. Мәсәлән, блондинкаларга артык буялган кашлар һич килешми, чөнки алар картайта. Аларның кашы буялган яки чәч төсеннән берәр тонга караңгырак итеп сызылган булырга мөмкин. Кара чәчлеләргә җиңелрәк, ләкин анда да чаманы югалтмаска кирәк. Төсен төскә туры китереп яки чәч төсеннән бер тонга түбәнрәк буяу сайласаң яхшы.

Һәм тагын бер киңәш. Йөзне «ачар» өчен, бу бигрәк тә түбән кашларга карый, каш астына чамасын белеп кенә якты күләгәләр (тень) җибәрегез. Бар игътибарны күзгә юнәлтәсегез килсә, иреннәрне аерып күрсәтү кирәкми: алар табигый булып калсын. Тушь кулланыгыз. Шушы кечкенә генә штрих сезне чын хатын-кыз итәр. Шатлана белегез, ешрак елмаегыз, барысы да әйбәт булыр. Яратып, яратылып яшәгез!

Мадияр Хаҗиев картиналарында иң элек героиняларның кашлары күзгә ташлана. Бәйсез, ирекле, көчле, матур, нәфис, үзсүзле, яшь хатын-кызларның кашлары.

 **КУЧКАР.** Алдыгызда искитмәле мөмкинлекләр ачылыр, берсеннән-берсе кызыклырак тәкъдимнәр булыр. Әмма айның беренче яртысы кискен карарлар кабул итү өчен отышлы вакыт түгел. Яңа эшләр башлауны да кичектереп торыгыз. Зур әйберләр сатып алуга да кагыла бу.

 **ҮГЕЗБОЗАУ.** Катлаулы, хәтта бераз авыррак ай. Үзегезне канәгатьләндерерлек нәтиҗәгә ирешү өчен бик күп эшләргә туры килер. Айның беренче яртысы хәлиткеч эшләр белән узар. Чебеннән фил ясамаска, низагларга кермәскә тырышыгыз.

 **ИГЕЗӘКЛӘР.** Айның беренче яртысында түземлек таләп ителсә дә, икенче яртысында – язмыш сезнең яклы. Эшегездә уңышка ирешерсез, хезмәт баскычыннан югары күтәрелү ихтималы зур. Керемнәрегезнең дә артуы көтелә. Зур әйберләр сатып алсагыз, отарсыз.

 **КЫСЛА.** Бу айда яңа эшләр башламый тору хәерле. Эш алыштыру да уңышлы булмас. Сәламәтлегегезгә үтә дә игътибарлы булыгыз. Күңелсез хәлләргә юлыкмас өчен эшегездән, дусларыгыздан, туганнарыгыздан ераккарак китеп торыгыз, ялга барып кайтыгыз.

 **АРЫСЛАН.** Тормышыгызны яңа биттән башлау мөмкинлеге бар. Эшегезне, яшәгән урыныгызны алыштыру өчен – менә дигән вакыт. Белемегезне арттырырга тырышыгыз, ул сезгә киләчәктә зур файда китерәчәк. Финанс өлкәсендә күңелле сюрприз көтелә.

 **СӨМБЕЛӘ.** Мөстәкыйльлегегезне күрсәтергә форсат чыгар. Үз-үзегезгә ышансагыз, уңышка ирешерсез. Командировка яки корпоративлардан баш тартмагыз, киләчәктә үзегезгә ярдәм итәрдәй кешене нәкъ менә шушындый чараларда очратырсыз.

 **БИЗМӘН.** Хезмәт баскычы буйлап күтәрелү өчен менә дигән мөмкинлек барлыкка киләчәк. Һәр адымыгызны уйлап эш итегез. Яңа танышулар көтелә. Ай ахырында рәсми чаралардан тыелып торуыгыз яхшы.

 **ЧАЯН.** Уңышлы ай. Тырышлыгыгызны һичшиксез күрерләр һәм тиешенчә бәяләрләр. Эш кәгазьләре белән игътибарлы булыгыз һәм гайбәтләрдән сакланыгыз. Ай башында хәлиткеч карарлар кабул итми торыгыз.

 **УКЧЫ.** Тулысынча эчке сиземләвегезгә ышаныгыз, нәкъ менә шуның ярдәмендә күп кенә күңелсезлекләрдән котылып калырсыз. Яңа танышулардан баш тартмагыз, алар арасында бик тә кирәкле кеше булачак. Айның икенче яртысында сүзегезне уйлап сөйләшегез.

 **КӘҖӘМӨГЕЗ.** Башкалар чыгарган низагны көйләүче булуыгыз ихтимал. Янәшәдә иңгә-иң терәп эшләүчеләрнең чын йөзләре ачылыр. Ай ахырында зур эшләр кузгатмагыз.

 **СУКОЯР.** Бер урында таптану чоры башланыр, бу исә кәефегезне кырырга мөмкин. Юкка кайгырмагыз, аның каруы, башланган эшләрне төгәлләр өчен вакытыгыз җитәрлек. Өстәвенә, тырышлыгыгызны да күреп алырлар. Акчагызны исраф итүдән сакланыгыз.

 **БАЛЫК.** Уңышлы ай булачак. Хыялларның күбесе тормышка ашар. Өстәмә керем чыганагы да барлыкка килер. Эшләр гөрләп барачак, иң катлаулы эшләргә дә курыкмый алыныгыз. Айның икенче яртысында файдалы тәкъдим булыр. Кабул итсәгез – отарсыз.

МАЙда кабынган йолдызлар

Татарстан



Хәлимә Искәндәрова (19.05.1940) – **театр артисты.**
Ташкентта туа. Кечкенәдән артист булырга хыяллана. 1958 елда хыялы эзеннән барып, Пржевальск шәһәренең рус театрына урнаша. 1963 елда Казанга күченеп кайта. Фатыйма Ильская, Фуат Халитовлар аны бик җылы кабул итә. Татарчасы ипи-тозлык кына булган Хәлимәне тулай торакта Фирдәвес Әхтәмова белән бер бүлмәгә урнаштыралар. Татарча камил итеп сөйләшергә шуннан өйрәнә ул. 1971 елда читтән торып ГИТИСны тәмамлый. 1992 елдан – Татарстанның атказанган артисты. Башкарган рольләренең берничәсе: Диләрә («Карлыгач канат кага». Х. Вахит), Огудалова («Бирнәсез кыз». А. Островский), Майшәкәр («Һиҗрәт». Н. Исәнбәт), Сәхилә («Хуҗа Насретдин». Н. Исәнбәт), Розина («Фигароның өйләнүе». П. Бомарше). Байтак кына телефильмнарда уйный.

Россия



Светлана Светличная (15.05.1940) – **актриса. РСФСРның атказанган артисты.**
Әрмәнстанның Ленинакан шәһәрендә туа. Әти-әнисе кызларының киләчәген фәкать сәхнәдә генә күрә. Светлана, әнисенең теләгенә каршы тора алмый, 1958 елны ВГИКка укырга керә. 1963 елда аны тәмамлап, «Киноактер театр-студиясенә» эшкә урнаша. Кинода беренче тапкыр Михаил Каликның «Колыбельная» фильмында уйный. Иң истә калырлык рольләренең берсе – «Бриллиантовая рука» фильмындагы Анна Сергеевна роле. Советлар Союзында төшерелгән эротик төсмерле иң тәүге роль буларак та тарихка кереп калган ул. Ике тапкыр гаилә кора, әмма икесе дә уңышсыз тәмамлана. Ике улы бар.

Чит илләр



Присцилла Пресли (24.05.1945) – **актриса, продюсер.**
Американың Нью-Йорк шәһәрендә туа. Үз әтисе ул тууга вафат була. Присцилланы үги әтисе үстерә. Кызга 14 яшь тулганда аларның гаиләсе Германиягә күченеп килә һәм Присцилла булачак ире, җырчы Элвис Пресли белән таныша. 1967 елда алар өйләнешә, ә тагын бер елдан кызлары Лиза Мария туа. Әмма гаилә тормышы озакка бармый. Тиздән Элвис вафат була. Присцилла иренә багышланган тапшыруларда катнаша, фильмнарда уйный башлый. Аның иң уңышлы эшләре дип, «Пистолет», «Форд Ферлейн маҗаралары», «Хэйли Вагнер атлы йолдыз» фильмнарында уйнаган рольләрен атыйлар.





КЫЛКАЛӘМ ОЧЫНДА КЫЗЛАР

Бөтендөнья татар конгрессы һәм «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы узган елның сентябрендә «Гаиләдә һәм җәмгыятьтә татар хатын-кызының роле» дигән темага кылкаләмле иҗатчылар арасында конкурс игълан иткән иде. Менә быел, язның ямьле көннәрендә Дзержинский урамындагы 27 нче йортта, рәссам Әмир Мәҗитов музеенда конкурска килгән эшләрдән экспозиция ачылды.

Өч номинациядә игълан ителгән иҗат ярышына эшләр күпләп килгән. Әйтик, «Рәсем сәнгате» номинациясендә генә дә ике йөзләп рәсем алынган. Элеккеге СССРның төрле төбәкләреннән генә түгел, хәтта чит илләрдән дә килгән картиналар, милләтебезнең яшәү-таралу географиясен искәртеп тора. Кайда гына яшәсә дә, халыкның тамыры бер үк, ул тамырларда типкән җирсү, сагыну, юксыну уртак. Картиналарда нечкә хисләр чагылышы гына түгел, әхлаклы, матур халкың белән горурлану да күзгә бәрелеп тора.

География дигәннән, мәгълүмат тулылыгы өчен аны бераз күздән кичерсәң дә ярый торгандыр. Оренбургтан Фәүзия Вәлиева («Бәйрәм ыгы-зыгысы»), Финляндиядән Елена Габбасова («Ана бәхете»), Чиләбедән Роза Савинова («Котлы булсын җәүһәр туегыз»), Мәскәүдән Зарема Позднякова («Сөембикә» журналының нуры»), Эстониядән Бәдрелхәят Власенко («Чәй эчәбез»), Белоруссиядән Маргарита Сәйфугалимова («Беренче укытучым») дигән картиналарын юллаганнар.

Татарстан кызлары: Ютазыдан Гөлназ Гәрәева «Әни кочагы» дип исемләнгән, батик ысулы белән эшләнгән картинасы белән катнашкан. Баулыдан Айгөл Мәҗитова картиналарында көнкүреш тә, тарих та бар. Әйтик, өстенә дәү-дәү әбиләреннән мирас булып калган 130 еллык күлмәкне кигән «Фәридә туташ» янында озакка тукталасың. Чаллыдан Тәслия Мәҗитованың «Бәби мунчасы», Аксубайдан Әлфия Нурхәмәтованың «Нурлы җомга», Апастан Илсөяр Вәлиеваның «Кич утырып йон эрлим» кебек картиналарында халкыбызның матур йолалары майлы буяулар белән киндергә төшерелгән. Актаныштан Айрат Сәрвәров «Ак калфакның балкыган чагы» дигән картинасы белән «Ак калфак» оешмасы кызларының уртак образын тудырган.

Шулкадәр байлыктан иң яхшыларын сайлап алу җиңел булмагандыр. Шулай да урыннар билгеләнгән.

Графика осталыгы җәһәтеннән беренче урын Нияз Хаҗиәхмәтовка «Казан чибәре» дип исемләнгән, компьютер графикасы алымы белән ясалган эше өчен бирелгән. Икенче урын Светлана Ибраһимовага Айдар Хәлимнең «Безнең кызлар» дигән әсәренә иллюстрацияләр өчен тәгаенләнгән.


Рәсем сәнгате өлкәсендә җиңүче картиналар арасында рәссам Алсу Тимергалина (өченче урын, «Җиде кыз», «Каз өмәсе»), Александр Петров (беренче урын, «Бәби тапкан ана»), Сергей Скоморохов («41 нең арбалы хатыннары» спектакле өчен) эшләре бар. Рәсем-картиналарның һәркайсы аерым билгеләп үтүгә лаек.

Күргәзмәне үзләре барып карый алган кешеләр, һичшиксез, зур ләззәт алырлар.

Асия ГАЛИУЛЛИНА









«Асылташ». Таһир Ильясов.
«Котлы булсын җәүһәр туегыз». Роза Савинова.
«Җиде кыз». Алсу Тимергалина.
«Ана бәхете». Елена Габбасова.
«Казан чибәре». Нияз Хаҗиәхмәтов.
«Колмак җыйганда». Айгөл Мәҗитова.

Подписка өчен iPad һәм башка бүләкләр!



Акцияне «ТАТМЕДИА» АҖ оештыра.
Акция 2015 елның 15 апреленнән алып 30 июньгә кадәр дәвам итә.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222 09 84 (1261)

16+ Реклама

АҖ «ТАТМЕДИА» газеталарына, журналларына языдыгыз һәм бәйгедә катнашыгыз!

Бәйгедә катнашыр өчен өч һәм аннан да күбрәк басмага язылу кирәк. Акцмядә катнашучы басмаларның исемлеген www.tatmedia.ru сайтыннан карай аласыз.

«Бәйге» билгесе белән язылган басмаларыгызның квитанция күчермәләрен Казан ш., Декабристлар ур., 2 яки podpiska@tatmedia.ru адресына җибәрегез. Элемтәгә керү өчен телефоныгызны күрсәтегез!

Тулы мәгълүмат һәм бәйгенең кагыйдәләре – www.tatmedia.ru сайтында.

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Бүләкнең зурысы, кечкенәсе булмый, диләр. Шуңа күрә, бу яңалыкны бездән бүләк итеп кабул итегез!

«Татарстан почтасы» 14 майдан 23 майга кадәр «Абунәче декадасы» үткәрә. Бу вакыт эчендә 2015 елның икенче яртыеллыгы өчен республикада һәм урыннарда чыгучы кайбер басмаларга ташламалар белән язылып калырга була. Яраткан укучылары өчен ташлама тәкъдим итүчеләр арасында «Сөембикә» журналы да бар. (Ташламалар редакциягә килеп язылучыларга да кагыла. Тик бу очракта журналны үзегез килеп алырга тиеш булуыгызны онытмагыз).

Тамчыдан күл җыела – мөмкинлектән файдаланып калырга ашыгыгыз!